**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Галләмов Ф.Г.* Татар телендә, стилистик чара буларак, кире кабатлаулар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Сәгъдиева Ф.К.* Сүзләрнең мәгънә эчтәлеген өйрәнү мәсьәләсенә карата: «акча» лексик берәмлеге һәм «хезмәт хакы» төшенчәсе мисалында . . . . . . . . . . . . . . 14
*Габдрахманова В.А.* Түбән Новгород өлкәсе татар топонимнары: Сафаҗай (Красная Горка) атамасы этимологиясе . . . . . . . . . 18

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Ибраһимов М.И.* Хәзерге әдәбият белемендә милли үзтәңгәллек мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
*Миңнуллина Ф.Х.* Татар әдәбиятында трагедия жанры . . . . . . . 30
*Минһаҗева Л.И.* Роберт Миңнуллинның балалар өчен иҗаты: фольклордан профессиональ поэзиягә юл . . . . . . . . . . . . . . 35
*Хасавнех А.Ә.* Ризаэддин Фәхретдиновның «Мәшһүр хатыннар» исемле биобиблиографик хезмәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
*Абзалина Р.Ә.* Сәет Вахидинең Милли музейдагы мирасы . . . . . 55

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙГА – 140

*Закирҗанов Ә.М.* Гаяз Исхакый һәм XX йөз башы татар драматургиясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
*Зиннәтуллина Г.Ф.* Гаяз Исхакый әсәрләре теленең образлылыгы . 67
*Галләм Р.Г.* Гаяз Исхакый – Яуширмә авылының указлы мулласы *(Гаяз Исхакый биографиясе эзләреннән)* . . . . . . 75
*Таиров Н.И., Таиров И.Н.* Г. Исхакый Мәскәүдә мөселман студентлар белән: бер фоторәсем тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . 93

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Халык җырларының үзенчәлекле төре буларак этник музыкаль традициядә хушавазлар . . . . . . . . . . . 99
*Дәүләтшина Л.Х.* Апас төбәге сөйләшләрендә «җен» персонажына бәйле лексика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Мәрданова Д.З.* XIX гасырның соңгы чирегендә Идел буе мөселманнарының хокукый төшенчәләре тарихи семантикасына карата *(«иҗтиһад», «мөҗтәһид», «иҗмаг» терминнары хакында Ш. Мәрҗани һәм аның оппонентлары арасындагы бәхәс мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
*Сәлахова Э.К.* Бертуган Шәфигуллиннар һәм татар мәгарифе . . 127

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Зарипов Ф.Ш., Сафина Р.И.* Математика фәнен татар телендә укыту һәм телне саклау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
*Гиниятуллина Л.М., Шәкүрова М.М.* «Туган тел»не укытуның яңача эчтәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140

## СӘНГАТЬ

*Донина Л.Н.* Татарларның чүкеп ясалган бизәкләре технологиясе һәм орнаментациясендәге милли үзенчәлекләр турында . . . . . . 147
*Арсланова Ф.Т.* Илаһи моң иясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
*Салихова А.Р.* «Әкият» татар дәүләт курчак театры бүгенге этапта . 160

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Гыйниятуллина Ф.С.* Театр белгече Һәнүз Мәхмүтовның фәнни эшчәнлеге *(Һәнүз Мәхмүтовның тууына 85 ел)* . . . . . . . 165

## ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Исхакый Гаяз.* «Японларның да бераз ярдәменә ышанган идек...» *(көндәлек дәфтәреннән)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Рамазанова Д.Б.* Татар язма әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). I т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык . . . . . . . . . . . . 173
*Заһидуллин И.К., Фәйзрахманов И.Җ.* Кариле – Кара иле (Мөхәммәтшин Гарифҗан) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**


## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Галлямов Ф.Г.* Обратные повторы как стилистическое средство в татарском языке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Сагдеева Ф.К.* К вопросу изучения семантического содержания слов: на примере лексической единицы «акча» (деньги) и понятия «заработная плата» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
*Габдрахманова В.А.* Татарские топонимы Нижегородской области: этимология названия Сафаҗай (Красная Горка) . . . . . . 18

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Ибрагимов М.И.* Проблемы национальной самоидентичности в современном литературоведении . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
*Миннуллина Ф.Х.* Жанр трагедии в татарской литературе . . . . . . 30
*Мингазова Л.И.* Творчество Роберта Миннуллина для детей: от фольклора к профессинальной поэзии . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
*Хасавнех А.А.* Биобиблиографическое сочинение Ризаэддина Фахретдинова «Знаменитые женщины» («Мәшһүр хатыннар») . . 49
*Абзалина Р.А.* Коллекция Саида Вахиди в Национальном музее . . 55

## ГАЯЗУ ИСХАКИ – 140

*Закирзянов А.М.* Гаяз Исхаки и татарская драматургия начала XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
*Зиннатуллина Г.Ф.* Образность языка произведений Г. Исхаки . . . . 67
*Галлям Р.Г.* Гаяз Исхаки – указной мулла деревни Яуширма *(Из биографии Гаяза Исхаки)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
*Таиров Н.И., Таиров И.Н.* Г. Исхаки с мусульманскими студентами в Москве: история одной фотографии . . . . . . . . . 93

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х.* Хушаваз как особенная разновидность народных песен в этно-музыкальной традиции . . . . . . . . . . . 99
*Давлетшина Л.Х.* Лексика, связанная с персонажем «җен» в говорах Апастовского района . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Марданова Д.З.* К исторической семантике правовых понятий мусульман Поволжья в последней четверти XIX в. *(на примере полемики между Ш. Марджани и его оппонентами)* . 114
*Салахова Э.К.* Татарское просвещение и братья Шафигуллины . . 127

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Зарипов Ф.Ш., Сафина Р.И.* Преподавание математики на татарском языке и вопросы сохранения языка . . . . . . . . 134
*Гиниятуллина Л.М., Шакурова М.М.* Обновленное содержание преподавания родного языка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140

## ИСКУССТВО

*Донина Л.Н.* Об этноспецифических особенностях технологии и орнаментации татарских чеканных украшений . . . . . . . . . . 147
*Арсланова Ф.Т.* Обладательница неповторимого голоса . . . . . 153
*Салихова А.Р.* Татарский государственный театр кукол «Экият» на современном этапе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

## ПЕРСОНАЛИИ

*Гиниятуллина Ф.С.* Научная деятельность театроведа Ханува Махмутова *(К 85-летию со дня рождения Ханузa Махмутова)* . 165

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Исхаки Гаяз.* «Мы надеялись на помощь японцев...» *(из дневника писателя)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168

## НОВЫЕ КНИГИ

*Рамазанова Д.Б.* Татар язма әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). I т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык . . . . . . . . . . . . 173
*Загидуллин И.К., Файзрахманов И.Җ.* Кариле – Кара иле (Мөхәммәтшин Гарифҗан) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

***Ф.Г. Галләмов***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ, СТИЛИСТИК ЧАРА БУЛАРАК, КИРЕ КАБАТЛАУЛАР

В статье рассматривается функционирование обратных повторов в татарском языке, которые активно употребляются в фольклоре и в художественных произведениях древней татарской литературы. В настоящее время наблюдается тенденция увеличения частотности их употребления, особенно в современной поэзии. Автор выделяет стилистические функции этих конструкций и разрабатывает их классификацию на основе следующих критериев: изменение грамматических показателей и употребление различных средств связи между компонентами. В статье также анализируются синтаксические единицы, которые могут повторяться в обратном порядке: словосочетания, главные члены предложения, не связанные между собой члены предложения, а также компоненты сложных предложений.

**Ключевые слова:** повтор, обратный повтор, стилистика обратных повторов, хиазм, порядок слов, средства связи.

Татар телендә кабатлау юлы белән сүз формалары, яңа мәгънәле сүзләр, төрле ярдәмлекләр белән катлауландырылган берәмлекләр – бик күп грамматик мәгънәгә ия булган синтаксик фразеологизмнар ясала [Галлямов, с. 42–108]. Мондый грамматик һәм лексик берәмлекләрдән тыш, телебездә бик күп стилистик кабатлаулар да кулланыла. Стилистикада, әдәбият белемендә аларның эпифора, анафора, анэпифора, рефрен, хиазм һ.б. формалары билгеле [Әдәбият белеме сүзлеге, б. 178–180; Курбатов, б. 151; Сафиуллина, б. 85–86; Хаков, б. 130; Хатипов, б. 280]. Биредә башка стилистик кабатлауларга игътибар итмичә, бары тик кире тәртиптәгеләренә генә тукталу максаты куелды. Алар татар теленең төрле стильләрендә күптән кулланылып килсәләр дә, бу төр стилистик чараның барлыгы турында татар тел белемендә мәгълүмат юк. Борынгы татар әдәбиятына караган әсәрләргә күз салсаң, аларны Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә үк очратырга мөмкин: *Гәүһәр таш* ул, ләкин һәр *таш гәүһәр* булмас; Йә, Зөләйха, киңәш сүзем тыңла инде! Ачык аңла: *син – минеке, мин – синеке…;* Ул Мисырда падишаһлык син кылырсың, Зөләйханы никахлап ук син алырсың, *Ул – синеке, син аныкы* һәм булырсыз; Син – олуг хан, ул – ханбикә булыр инде.

Бу төр әйләнмәләр соңгы еллар поэзиясендә аеруча активлашу процессын кичерәләр. Әмма әлеге стилистик алымнарның берсе булган кире кабатлаулар, нишләптер, игътибар үзәгеннән читтә калып килделәр.

Кире кабатлауларның әдәбият белемендә һам стилистикада телгә алына торган хиазм күренеше белән дә күпмедер дәрәҗәдә уртаклыгы бар. Ләкин хиазмның

кабатлау юлы белән ясала алуы турында бер генә хезмәттә дә әйтелми: «Бер үк морфологик формалы һәм эчтәлек ягыннан үзара бәйләнешле янәшә җөмләләрнең (яки сүзтезмәләрнең) икенчесендә сүз тәртибенең киресенчә булуы *хиазм* дип атала» [Курбатов, б. 151]. Безнең тикшеренүләр бу синтаксик фигураларның өч төрле ясала алуын күрсәтә:

1) беренче җөмләдә туры тәртиптәге кисәкләр, икенчесендә охшаш функция башкаручы кисәкләр кире тәртиптә кулланылалар: *Иртәләрем аяз иде, Җиләс иде кичләрем* (Х. Туфан);

2) җөмлә кисәкләре кире тәртиптә кулланылалар, аларның берсе кабатлана: *Кибәр* ***иреннәр, Иреннәр*** *сусар* (С. Хәким;

3) җөмлә кисәкләренең икесе дә кире тәртиптә кабатлана:

Туган якта һәр ***тал җырлый,***
***Җырлый таллар*** үзенчә
(С. Хәким).

Туган якта ***һәр тал җырлый*** –
Үз-үзенә тын гына …
***Җырлый һәр тал***, җитә эңгер,
Тынмый алар, төн була
(С. Хәким).

Мисаллардан күренгәнчә, кабатлау юлы белән ясалган бу стилистик алымның тәэсир итү көче, әлбәттә, артыграк.

Хиазм күренеше үзара ияртүле бәйләнештә булган мөстәкыйль җөмлә кисәкләре арасында гына түгел, бәлки тиңдәш кисәк компонентлары кулланылышында да күзәтелә. Бу очракта алар кире тәртиптә кабатланалар һәм үзенчәлекле ялгау барлыкка китерәләр. Мәсәлән: Ул *зарлана да елый, елый да зарлана.* Кайбер кешеләрнең башка бернәрсәгә дә исләре китми, *ашыйлар да эчәләр, эчәләр дә ашыйлар* (Ә. Еники).

Кире кабатлаулар төшенчәләр арасында диалектик бәйләнешне белдерү өчен дә кулланылалар. Мәсәлән: *Хәбәрлек һәм модальлексез җөмлә* була алмаган кебек, *җөмләсез дә хәбәрлек һәм модальлек* була алмый. Хәбәрлек һәм модальлек тә үзара диалектик бәйләнештә торалар. *Хәбәрлектән башка модальлек, модальлектән башка хәбәрлек* була алмый (синтаксистан лекцияләр). *Синтагма* берничә *сүзтезмәдән* тора алган кебек үк, *сүзтезмә дә синтагмаларга* бүленә ала (М. Зәкиев).

Кире кабатлаулар саналып китүнең тәмамлануын белдерәләр:

Еллар гына талгын аккан,
Алыштырган
*Төннәр – көнне, көннәр – төнне*
(Ә. Мәхмүдов).

Бу конструкцияләрне компонентларында барлыкка килгән үзгәрешкә карап төркемләргә була. Татар телендә алар ике төрле юл белән төзеләләр:

а) сүзләр, сүз тәртибен генә үзгәртеп, бернинди үзгәрешсез кабатланалар:

*Көтә-көтә аргансыңдыр,*
*Аргансыңдыр көтә-көтә –*
Тик өмет өзмә генә.
*Мәхәббәттә дөрлә, әйдә,*
*Әйдә, дөрлә мәхәббәттә –*
Тик янып бетмә генә
(Г. Рәхим);

ә) сүз тәртибе дә үзгәрә, синтаксик вазифалары да, грамматик формалары да алышына:

Биеп-җырлап җанга килеп керде,
Күңелләргә инде моң нуры.
*Зиннурларның* җирдә *иң зуры* ул,
*Иң зурларның* – якын *Зиннуры!*
(Р. Вәлиев).

*Бәләкәйнең зуры* булганчы, *зурның бәләкәе* булу яхшы (әйтем).

Кире кабатлауларның бары тик беренчесе генә (а) хиазм күренеше итеп карала ала.

Бу төр әйләнмәләрнең, компонентлары арасындагы бәйләүче чараларга карап, түбәндәге төрләрен күрсәтергә мөмкин. Күпчелек очракта аларның компонентларын антоним сүзләр тәшкил итә. Шул ук вакытта үзара капма-каршы мөнәсәбәттә тормаган ике зат, предмет, күренеш тә чагыштырылырга мөмкин, шунлыктан алар арасында, бәйләүче чара буларак, каршылык интонациясе кулланыла:

*Мин – дөньяны, дөнья мине* куып,
Алҗытылган, хәтсез арылган
(Р. Вәлиев).

Каршылык мөнәсәбәте теркәгечләр белән дә белдерелә:

*Патшалар* да *шагыйрь* була,
***Тик*** *шагыйрь* булмый *патша*
(Г. Морат).

Кире кабатлауларның кисәкләре арасында санау интонациясе дә бәйләүче чара була:

Нигә таң көн саен *алсу гел,*
*гел алсу*?
Таңнарда нигә соң һәрвакыт
ямансу?
(Р. Вәлиев).

Санау интонациясе белән бергә җыючы теркәгечләр дә килә:

Сүндер утны, яшьлекнең шәт
Шигъри аслы шулдыр ул:
*Янганны сүндерә алу*
***Һәм*** *сүнгәнне яндыру*
(Р. Мингалим).

Бик сирәк очракларда гына кире кабатлауларда бүлүче теркәгечләр дә кулланыла: Салих абый харап сүзчән кеше булып чыкты, ***әллә*** *көлгәндә сөйли,* ***әллә*** *сөйләгәндә көлә,* аера торган түгел, барысы бергә (Р. Габделхакова).

Бу стилистик берәмлекләрдә ике сүзнең соңгысы беренче урынга чыга һәм бер үк сүз янәшә кабатлана. Бу аның тәэсир көчен арттыра, мәгънәне тагын да ныграк көчәйтә. Шул рәвешчә бик үзенчәлекле ялгау барлыкка килә, фразалар табигый тезелеп китәләр:

*Син тоймыйсың,* әйе,
*тоймыйсың син* –
Көзләр килә, аннан кыш була.
Салкын *җилләр,* әнә, *ятып елый,*
*Ятып елый җилләр* таш юлга
(Р. Вәлиев).

Инде шигъри сөйләмдә һәм халык авыз иҗатында кире тәртиптә килгән синтаксик берәмлекләрне карап китик. Биредә иң күп очракта сүзтезмә компонентлары, ягъни төгәлләүле мөнәсәбәттәге сүзләр, кире тәртиптә кулланылалар. Бу түбәндәге сүзтезмә төрләрендә күзәтелә:

1. Сыйфатлы исем сүзтезмәләрдә:

Мактанса да татар кешесе,
Гали җырчысын атар…
«Ул, – дияр, – безнең Карузо, –
*Татарский итальян,*
*Итальянский татар»*
(Р. Вәлиев).

*Ләззәтле газап,*
*Газаплы ләззәт* (Зөлфәт).

2. Фигыльле исем сүзтезмәләрдә:

Әрнеттең дә ничә кабат
Юаттың үзең азак.
*Газаптан торган шатлык* син,
*Шатлыктан торган газап*
(Р. Миңнуллин).

3. Сыйфатлы сыйфат сүзтезмәләрдә:

*Яманның яхшысы* булганчы,
*Яхшының яманы* бул (мәкаль).

4. Фигыльле фигыль сүзтезмәләрдә:

Сәхнәләргә чыккан чакта
Кояш балкый йөзендә.
Театрда *уйнап җырлый,*
*Җырлап уйный* Резедә
(Р. Вәлиев).

*Белгәнеңне сөйләмә, ни сөйләгәнеңне бел* (мәкаль).

*Ашар өчен яшәмә, яшәр өчен аша* (мәкаль).

5. Хәбәрлек сүзле фигыль сүзтезмәләрдә:

*Юктан барга, бардан юкка чыгу*
Серен Тәңре белә, билгеле
(М. Галиев).

*Юктан бар була*, *бардан юк була* (табышмак).

6. Кайбер сүзтезмәләр бик нык үзгәреп тә кабатланырга мөмкиннәр. Мәсәлән, түбәндәге мисалда исемле фигыль сүзтезмә фигыльле фигыль булып кабатланган:

Йөрәккә *ачкыч яратып булмый,*
аны *яратып кына ачып була*
(Ш. Галиев).

Моннан тыш, җөмләдә сүзтезмә тәшкил итмәгән, ягъни үзара бәйләнештә тормаган иярчен кисәкләр дә кире кабатлау барлыкка китерәләр.

Сөйләмдә тәмамлык булып килгән кисәкләр урыннарын алыштырып, шул ук тәмамлык функциясендә кабатланалар:

Аның гомере *шатлыклардан*
*кайгы,*
*Кайгылардан шатлык* эзләп үтте
(Р. Вәлиев).

Ия һәм тәмамлык булып килгән кисәкләр үзгәреп кабатланалар: *Син миңа, мин сиңа* (мәкаль). *Ул – миңа, мин аңа* кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырыштык (Г. Исәнгулова).

*Син миңа* кирәк*,*
*Мин сиңа* кирәк (җыр) –

бу җөмләдә хәбәр дә кабатлап кулланылган, шуның белән үзенчәлекле рифма барлыкка килгән, мәгънә көчәйтелгән.

Җөмләдә үзара сүзтезмә төземи торган тәмамлык һәм рәвеш хәле булган кисәкләр кире кабатлау барлыкка китергән:

*Сиңа минсез, миңа синсез*
яшәүләр юк (җыр).

Җөмләдә үзара сүзтезмә төземи торган ике урын хәле кире тәртиптә килә: Аның бөтен вакыты *шәһәрдән авылга, авылдан шәһәргә* йөреп уза иде (Ф. Хөсни).

Аерымланган хәл белән катлауландырылган җөмләдәге урын хәлләре шулай ук кире тәртиптә булалар: *Ерак* куйсаң, *якыннан* алырсың, *якын* куйсаң, *ерактан* алырсың (мәкаль).

Эндәш сүз белән җөмләнең хәбәре дә урыннарын алыштыра алалар:

*Җил, исмә! Исмә, җил,*
Каенга кагылма (Р. Гаташ).

Тезмә кушма җөмләләрнең фигыль хәбәрләре кире тәртиптә кулланылалар:

*Искерә дә* дөнья, *яңара ул,*
*Яңара да* тагын *искерә*
(Х. Туфан).

Җөмләнең баш кисәкләре дә үзара кире тәртиптә кабатлана алалар:

*«Сөйгәнең инде юлда, – дип, –*
*Юлда, – дип, – инде сөйгәнең»* –
Ул хәбәр сала аңа
(Г. Рәхим).

*Син сизмисең, әйе, сизмисең син…*
Син сизмисең – йолдыз атыла.
Җиргә карап, *күрми каласың син,*
*Син күрмисең* – күктә ай тула
(Р. Вәлиев).

Тәүге яры төшләрендә
Рәшә кебек югалды.
Сөяр иде, *яры юк* шул
Сөяр иде, *юк яры…*
(Г. Морат).

Тәүге ярын төштә күрсә,
Гел яхшыга юрады.
Сөяр иде, *яры юк* шул
Сөяр иде, *юк яры...*
(Г. Морат).

Баш кисәкләрдән торган җөмлә башта туры тәртиптә, аннан кире тәртиптә кабатланып та кулланыла. Ике тапкыр куллану мәгънәне бик нык көчәйтеп бирә:

*Ике күзе тәрәзәдә,*
*Ике күзе тәрәзәдә,*
*Тәрәзәдә ике күзе –*
Мине көтәдер инде.
*Йөрәгемдә ялкын гына*
*Ялкын гына йөрәгемдә –*
Янып бетәдер инде
(Г. Рәхим).

Мондый кабатлауларда зат алмашлыклары яисә күмәклек исемнәр белән белдерелгән ияләр ялгызлык исемнәр белән, бер күмәклек исем икенчесе белән алыштырып бирелергә мөмкин:

Язларны *ул* бездән алдан *күрә,*
*Күрә Тукай* еллар үтәли
(Р. Вәлиев).

Илаһи йорт – Тукай клубында
*Яшь кыз җырлый, җырлый*
*Вафирә* (Р. Вәлиев).

Ия дә, хәбәр дә грамматик күрсәткечләрен һәм синтаксик вазифаларын алыштырып кабатланалар:

*Күлләр диңгез булган, диңгезләр – күл,*
Буталганнар таулар, үзәннәр
(Р. Вәлиев).

Иделләре, Иделләре, Иделләре, күлләре,
*Син минеке, мин синеке* димәдек шул элгәре (җыр).

Газиз кешем!
Синең өчен даим
Мин Ходайдан шуны гозерлим:
*Гомерләрең булсын бәхетле, дим,*
*Бәхеткәең булсын гомерле*
(Ш. Маннапов).

*Гамьнең соңы – шатлык,*
*Шатлыкның соңы – гамь*
(Мәҗмугыл-хикәят).

Кире кабатлауларның тагын бер үзенчәлеге шунда: алар күп

очракта кушма җөмлә барлыкка китерәләр:

Син миңа
Дөньядан зуррак, –
Син – әти, син – әни, син – Нигез.
Син – җирдә яшәүнең мәгънәсе,
Мәңгегә *без – ул син, син – ул без*
(И. Ихсанова).

Түбәндәге мисалда беренче җөмләнең аергыч һәм тәмамлык кисәкләре урыннарын алыштыралар һәм тезмә кушма җөмлә барлыкка китерәләр: *Тайның* яхшысы *атка* иярер, *Атның* начары *тайга* иярер (мәкаль).

Гади җөмләнең иясе һәм тәмамлыгы булган кисәкләр, урыннарын алыштырып кабатланалар һәм тезмә кушма җөмлә төзиләр:

*Якутлар* табыладыр *вакыт белән*,
*Вакытлар* табылмыйдыр *якут белән* (Г. Кандалый).

Иярчен һәм баш җөмләдәге антоним сүзләр, шулай ук кире тәртиптә кулланылып, катлаулы кушма җөмлә хасил итәләр:

*Җитдиләр янына* барсаң,
*Шаяннар* җитми кебек;
*Шаяннар янына* барсаң,
*Җитдиләр* җитми кебек
(Р. Мингалим).

Җөмләнең баш кисәкләре белән нинди дә булса иярчен кисәк тә кире кабатлау барлыкка китерә, әмма ия белән хәбәр үзләренең башлангыч тәртибен саклыйлар:

*Тәрәзәдән кояш карый,*
*Кояш карый тәрәзәдән –*
Туп-туры карый аңа
(Г. Рәхим).

Иярченле кушма җөмләдә баш җөмләне тәшкил итүче сүзләр кире тәртиптә кулланылалар: Яланга чыксаң, анда *саескан да карга, карга да саескан* (Г. Ибраһимов).

Иярчен аныклагыч җөмләнең хәбәрен тәшкил иткән тиңдәш кисәкләр кире тәртиптә килә алалар: Кайбер кешеләрнең башка бернәрсәгә дә исләре китми, *ашыйлар да эчәләр, эчәләр дә ашыйлар* (Ә. Еники).

Үзара каршылык мөнәсәбәтендә торучы тезмә кушма җөмләләр, кире тәртиптә кулланылып, күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә барлыкка китерәләр:

*Мин качамын – ул куадыр,*
*ул куадыр – мин качам;*
Шулкадәрле кыр тыныч, һичбер
кеше юк ичмасам (Г. Тукай).

Шулай итеп, татар телендә сүзтезмә төземи торган, берберсе белән бәйләнештә тормаган сүзләрнең, шулай ук сүзтезмә компонентларының, ия һәм хәбәрләрнең, иярчен һәм баш җөмләдәге, тезмә кушма җөмлә төзегән гади җөмләдәге сүзләрнең һ.б.ның кире кабатлану очраклары була. Алар көчле стилистик алым булып санала, мәгънәне төрле яклап көчәйтү өчен кулланылалар, саналып китүнең тәгәлләнгән булуын белдерәләр, фикер йөртүнең логик эзлеклелеген тәэмин итәләр, төшенчәләр арасында диалектик бәйләнеш барлыкка китерәләр. Шул ук вакытта фразаларны үзара бәйләү вазифасын да башкаралар.

**Әдәбият**

Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 238 б.

*Галлямов Ф.Г.* Повторы в татарском языке. Казань: Школа, 2003. 144 с.

*Курбатов Х.Р.* Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. Казан: Мәгариф, 2002. 199 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар телендә сүз тәртибе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 154 б.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле (стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 304 б.

*Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Тулыландырылган икенче басма. Казан: Раннур, 2002. 352 б.

***Галләмов Филүс Гатип улы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*Алабуга институты профессоры*

УДК 811.512.145’373

***Ф.К. Сәгъдиева***

# СҮЗЛӘРНЕҢ МӘГЪНӘ ЭЧТӘЛЕГЕН ӨЙРӘНҮ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА: «АКЧА» ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕГЕ ҺӘМ «ХЕЗМӘТ ХАКЫ» ТӨШЕНЧӘСЕ МИСАЛЫНДА

В статье рассматривается содержание обыденного понятия *акча*, включающее в себя следующие признаки: «деньги», «деньги, полученные за работу в течение месяца». Обыденные понятия могут коррелировать, вступать в функциональные омонимические отношения с другими представлениями и научными понятиями. Представления о деньгах как о заработной плате связаны со сроками ее выплаты, размером, основным местом работы и др. В данном случае признак «за месяц» рассмотренного обыденного понятия является культурно маркированным. Научное понятие *заработная плата* является гиперонимом для понятий *сдельная заработная плата, повременная заработная плата.*

**Ключевые слова:** обыденное понятие, представление, научное понятие, концепт, деньги, пословицы и поговорки.

К. Ситарам һәм Р. Когделл тарафыннан Көнбатыш, Көнчыгыш, мөселман мәдәниятләре нигезендә төзелгән «Төрле мәдәниятләрдә рухи кыйммәтләрнең структурасы» таблицасында *акча* рухи кыйммәт буларак карала [Ситарам, 1992]. Көнбатыш вәкилләре иң мөһим кыйммәтләр арасында акчаны (байлыкны) дүртенче урынга куялар. Бу кыйммәт әлеге мәдәният вәкилләре аңында югары урынны били. Мөселман мәдәниятендә байлык икенче дәрәҗәле кыйммәтләр арасында өченче урында, ә Көнчыгыш мәдәниятендә өченче дәрәҗәле кыйммәтләр арасында икенче урында тора. *Хезмәт* компонентлы рус паремияләрен тикшергән Л.Б. Савенкова аларның 615 берәмлек тәшкил иткәнлеген һәм үзләренең саны буенча рухи кыйммәтләр системасында 15 нче урында торганлыгын әйтә. Ул биредә беренче урыннарны *акча* (1813 берәмлек), *гаилә* (1437 берәмлек), *файда* (1328) һ.б. компонентлы паремияләр били, дип яза [Савенкова, 2002].

Татар халкының беренчел дөнья картинасы күренеше буларак, *акча* сүзе үз эчтәлегендә *эш хакы* дигән сүзтезмәнең мәгънәсен чагылдыра. Хезмәт хакы буларак караганда, *акча* сүзенең беренче мәгънәсендә семантик үзгәреш күзәтелә. *Акча* сүзенең мәгънә эчтәлегендә *ай буена эшләнгән эш өчен алынган акча* дигән мәгънә урын ала. Билгеле булганча, кайбер урыннарда хезмәт хакы атна саен түләнә: әйтик, Америкада. Күзәтүләрдән күренгәнчә, *эш хакы* төшенчәсенең табигатен билгеле торган параметрлар булып эш урыны, акчаны бирү вакыты *(айлык, ай саен, атналык, атна саен),* аның күләме, төрләре һ.б. санала. Мәсәлән, хезмәт хакын төрләргә бүлгәндә, аны *төп хезмәт хакы;*

*вакыт исәбеннән түләнә торган эш хакы; эш башыннан түләнә торган эш хакы* дип карарга мөмкин. Эш хакын түләү формасы ягыннан килгәндә, *саф акча* (рус. *наличный расчет*); *түләнми торган расчет* (рус. *безналичный расчет*) кебек төрләре аерылып чыга. Татар телендәге *кара акча* сүзтезмәсенең мәгънә эчтәлеге рус телендә еш кулланыла торган образлы гыйбарәләрдән *черная зарплата, черный нал* фразеологик әйтелмәләрнең семантикасына туры килә.

Татар телендәге *хезмәт хакы, акчалата бүләкләү, акчалата түләү* дигән мәгънәләр рус теле аша кергән сүзләрнең мәгънә эчтәлегендә дә ята. Мәсәлән, әдәбият, сәнгать, журналистика һ.б. иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнүчеләргә хезмәтләре өчен бирелә торган акча *гонорар* сүзе, ә акыл хезмәте өчен түләнә торганы *стипендия* сүзе белән белдерелә: *...син һавадагы торнага ышанып, кесәңдәге актык тиеннәреңне бетергәнсең, гонорар алгач түләргә исәпләп, бурычка да батказсың* [Ибраһимов, т. 3, б. 214]; *Кем акчасына укыдың? – Стипендия алдым* [Ибраһимов, т. 4, б. 420].

Шуның белән бергә, хезмәт хакының күләме турында сөйләгәндә күбрәк *ставка* берәмлеге кулланыла. Татар телендә әлеге мәгънә үзенчәлеге *хак* сүзе чагылыш таба: *эш хакы, хезмәт хакы, түләү хакы.* Моннан тыш, ул *күп – аз, әйбәт – начар, югары – түбән* антонимнары белән дә белдерелә.

Концепт, лингвомәдәни категория буларак, үз эченә, беренчел дөнья картинасы күренешләрен генә түгел, фәнни дөнья картинасы берәмлекләрен дә туплый.

Фәнни төшенчә буларак *эш хакы,* беренчедән, *хезмәт кыйммәте (хакы)* төшенчәсенең гипонимы булып тора; ә инде *вакыт исәбеннән түләнә торган эш хакы* һәм *эш башыннан түләнә торган эш хакы* төшенчәләренә гипероним була.

Татар халкының акча белән бәйле карашлары төрле лексик берәмлекләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, *ризык, табыш, уңыш, яхшылык, бәхет, мал, дәүләт, яманлык, михнәт, бәя, бурыч* һ.б. Акча эшләү уңышлы дәрәҗәле, файдалы тормышта яшәргә мөмкинлек бирә. Акчалы кеше – хәлле кеше, таза, нык, мул тормышлы кеше булып күзаллана. Акчасызлык исә, киресенчә, хәлсезлек, ярлылык, мохтаҗлык билгесе.

Татар телендә *акча, мал туплау, байлыкка, бәхеткә ирешү* мәгънәсендә *дәүләт* сүзе актив кулланыла: *дәүләт йөзен күрсәткән, дәүләт башына кунган, дәүләтең артсын, дәүләтең белән картай, дәүләт кошы башыңа кунсын, дәүләт өстенә дәүләт яусын, дәүләтең ташысын, дәүләтең башыңнан ашсын* һ.б.

Мәгънә, референция һ.б. семиотик төшенчәләр рәтендә *акча* төп категорияләрнең берсе булып тора. Күп кенә башка универсаль мәдәни концептлар кебек вербаль яссылыкта ул төрле тел берәмлекләре ярдәмендә белдерелә.

Тормыш өчен акча гадел юл белән табылырга тиеш һәм бу татар телендә *хәләл* лексемасы белән белдерелә. Шәригать

кануннары буенча күкрәк көче куеп табылмаган акча хәрәм санала [Сәгъдиева, 2017, б. 20]. Биредә үрнәк итеп, ислам банкларының эшчәнлеген китерергә мөмкин. Әлеге финанс учреждениеләре бирелгән кредит өчен процентлар алмыйлар. Аларның хезмәтләре өчен түләү комиссия формасында тәэмин ителә. Көнбатыш һ.б. илләрдәге банклар кредит өчен процентка биреп торган акчадан килгән файда исәбенә яшиләр.

*Акча* – гомуми түләү эквиваленты буларак йөри торган махсус товар. Татар телендәге *товар* сүзе һәм *натуралата түләнә торган эш хакы* сүзтезмәләренең семантикаларында *акча* сүзенең дә мәгънәсе чагылыш таба. Мәгълүм булганча, XX гасырның 90 нчы елларында күп кенә оешмаларда, тере акча булмау сәбәпле, эшчеләргә хезмәт хакын үзләре җитештергән яки башка товар белән түләнде. Бүгенге көндә дә кайбер авыл хуҗалыгы предприятеләрендә эш хакы натуралата түләнә.

Кешенең акчага карата мөнәсәбәте төрле халыкларның афоризмнарында чагылыш таба: Мәсәлән: *Деньги – вещь очень важная. Особенно когда их нет* (Ремарк. Германия); *Имеющий деньги не может быть наказан* (Цицерон. Борынгы Рим). Күп кенә телләрдә Рим императоры Веспасиан исеме белән бәйле *деньги не пахнут* фразеологизмы еш кулланыла, татарчасы *акчаның исе юк*. Рус телендә әлеге мәгънәдә *на деньгах нет знаку* мәкале очрый. Акча кемнеке һәм нинди ысул белән табылганы билгеле түгел, дигән мәгънәне аңлата.

Эшләп акча табу идеясе белән бәйле фразеологик берәмлекләр татар һәм рус телләрендә бер үк мәгънәдә кулланыла: татар. *акча эшләү* – рус. *зарабатывать деньги, делать деньги;* татар. *акча көрәү* – рус. *грести лопатой деньги;* татар. *акча сугу* – рус. *чеканитъ деньги* һ.б. (Бу мәкаләдә фразеологик берәмлекләр дигән төшенчә киң мәгънәдә кулланыла.) Татар телендә мәгънә эчтәлекләрендә тере җан ияләренә хас булган функцияләрне чагылдыра торган фразеологик берәмлекләр дә кулланыла: *акча балалату, акча үрчетү*.

Татар телендәге *кесә* сүзе һәм аның рус телендәге *карман* эквиваленты фразеологик берәмлекләрдә образ буларак акчаның сан, күләм ягыннан азлыгын яки күплеген чагылдыра: татар. *кесә калынаю,* рус. *тугой карман;* татар. *кесә буш булу;* рус. *тощий карман* һ.б.

Акча белән бәйле мәкальәйтемнәрнең, фразеологик берәмлекләрнең күплеге аның татар халкы аңында беренче урында торганлыгын дәлилли. Әлеге паремияләрдә ике категорияне аерып чыгарырга мөмкин. Беренчесен гомуми бәяләмә характерындагы позитив, негатив, ике яклы аксиологик хөкемнәрне чагылдырган мәкальләр тәшкил итә. Икенчесенә үз эченә акчаның кыйммәтен билгеләүче хосусый бәяләмәләрне алган мәкальләр керә [Сагдеева, Гайнанова, 2017].

Хезмәт өчен түләү идеясе белән бәйле татар паремияләрендә төп лексемалар буларак *мал, исраф, исрафчан, саран, ярлы*

һ.б. күп кенә сүзләр кулланыла. Бу сүзләр «хезмәт куеп табылмаган акчаның кадере юк» дигән мәгънәне аңлаталар: *Үзем тапкан мал түгел, әтинеке жәл түгел.* Андый акча тиз арада исраф була. Исрафчыллык хәерчелеккә китерә: *Исрафчан бай ярлы булыр.* Ләкин артык саран булу да акчаны, малны сакламый: татар. *Саранның чыгымы исрафчыныкы белән бер;* рус. *Скупой богач бедней нищего. Вкупе богат и убог.* Шәригать буенча үз саранлыгыннан сакланган кешеләр уңышка ирешәчәк. Әмма намус белән үтәлгән эш матди байлык китерми: татар. *Эшләп кеше баемый. Эшләп кем баеган.*

Кеше ниндидер эш башкара, шуның өчен үз вакытында хезмәт хакы түләнүен көтә.

**Әдәбият**

*Ибраһимов Г.Г.* Әсәрләр. Сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Т. 3 / төзүчеләр: А.Ш. Шамов, Х.Я. Гобәйдуллин. 455 б.

*Ибраһимов Г.Г.* Әсәрләр . Сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Т. 4 / төзүче: А.Ш. Шамов. 463 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда / җыючы, төзүче, кереш сүз авторы Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Т. 1. 916 б.

*Савенкова Л.Б.* Русская паремиология: семантический и лингвокультурологический аспекты. Ростов н/Д: Изд-во Рост. ун-та, 2002. 239 с.

*Сагдеева Ф.К., Гайнанова Д.Р.* Татарский концепт как объект лингвокультурологического анализа. Казань: ИЯЛИ, 2017. 248 с.

*Сәгъдиева Ф.К.* Татар паремияләрендә рухи кыйммәтләрнең чагылышы // Фәнни Татарстан. 2017. № 4. Б. 19–21.

*Ситарам К., Когделл Г.* Основы межкультурной коммуникации // Человек. 1992. № 2. С. 51–64.

***Сәгъдиева Фәүзия Кәбир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 81.373.211

***В.А. Габдрахманова***

# ТҮБӘН НОВГОРОД ӨЛКӘСЕ ТАТАР ТОПОНИМНАРЫ:
## Сафаҗай (Красная Горка) атамасының килеп чыгышы

Статья посвящена изучению татарских топонимов Нижегородской области Российской Федерации в историко-этимологическом аспекте. В частности, рассматривается вопрос происхождения названия села Сафаҗай (Красная Горка), относительно которого существует несколько гипотез. Исследование актуально с точки зрения определения роли татарского фактора в истории края.

**Ключевые слова:** Нижегородская область, татарские названия, Красная Горка, топонимы, этнонимы, история.

Түбән Новгород өлкәсе – Россия Федерациясенең Европа өлешендә урнашкан субъекты. Мәйданы – 76,9 мең км$^2$. 1929 елда оештырыла. Үзәге – Түбән Новгород шәһәре. Халкы – 3260267 кеше (2016 ел), татарлар – 44103 кеше (2010). Татарлар, бергә тупланып, Балахна, Бор, Дзержинск, Кстово, Түбән Новгород шәһәрләрендә, Кызыл Октябрь (17 торак пунктта), Сергач (7), Спас (4), Пилнә (4), Княгинино (1), Первомайск (1), Сеченово (1) районнарында көн күрәләр. Алар, күпчелекне тәшкил итеп, 35 торак пунктта яшиләр.

Түбән Новогород өлкәсенең татарча топонимнары булган авыллар исемлеге

| **Авылның русча исеме** | **Авылның татарча исеме** |
|---|---|
| Актуково | Актук (Яңапар) |
| Анда | Анды |
| Андреевка | Мөтеравыл |
| Антяровка | Әнтәр |
| Бозлово | Бозлау |
| Большое Рыбушкино | Зур Рбишча |
| Грибаново | Грибан |
| Ендавищи | Яндавишча |
| Ишеево | Ишавыл |
| Кадомка | Кадом |
| Камкино | Камка |
| Карга | Карга |
| Ключищи | Суыксу |
| Красный Остров | Краснай, Кызыл Атау |
| Красная Горка | Сафаҗай |
| Кузьминка | Кызым |
| Медяна | Мәдәнә |
| Малое Рыбушкино | Кече Рбишча |
| Новый Мочалей | Яңа Мочали |
| Овечий Овраг | Куйсуы |
| Пошатово | Пашат |
| Парша | Тукай |
| Пица | Печә |
| Петряксы | Петрякс |
| Семёновка | Семочки |
| Салганы | Салган |
| Старый Мочалей | Иске Мочали |

| | |
|---|---|
| Татарское Маклаково | Татар Моклокасы |
| Трёхозёрки | Өчкүл |
| Урга | Ыргу |
| Уразовка | Уразавыл |
| Чембилей | Чүмбәли |
| Шубино | Шуба иле |
| Яново | Янау |
| Курмыш | Кормыш |
| Мамешево | Мәмәш иле |
| Можаров-Майдан | Мажар Мәйданы |
| Тальник | Таллык |
| Новое Камкино | Яңа Камка (Мәүләшә) |

Татар энциклопедиясендә бу төбәк турында шактый зур материал бирелә:

«Татарлар Түбән Новгород өлкәсе территориясен XIII–XV йөзләрдә үзләштерә башлый. Шул ук вакытта Сараклыч (хәзер Сарово) шәһәренә, Арзамас шәһәре янындагы татар авылларына нигез салына. XV–XVI йөзләрдә өлкәнең көньяк-көнчыгыш өлешендә (Пьяна һәм Сура елгалары буе) татарлар саны Мишәр, Кадом, Кормыш, Ядрин шәһәрләреннән һ.б. җирләрдән күченгән йомышлы татарлар исәбенә арта. Алар, таралып, рус, мордва, мари авылларына урнаша. 1612 елда Алатырь өязендә 13 йомышлы татар авылы, шулай ук Арзамас һәм Кормыш өязендә татар авыллары була...» [Татарская..., с. 422].

Түбән Новгород төбәге татарлары турында беренче мәгълүматлар XVIII йөздә күренә башлый. Бу еллар гади халык, бигрәк тә милләтләр өчен гаделсезлек, хәерчелек, чарасызлык чоры була, шунлыктан татарлар, туган якларын ташлап, чит җирләргә китәргә мәҗбүр ителә. Алар Санкт-Петербург, Баку, Башкортстан, Оренбург якларына юл тота.

Бу төбәккә Россия академиясе академигы П.С. Паллас, адъюнкт-профессоры И.И. Лепехин җитәкчелегендә фәнни экспедицияләр оештырыла. И.И. Лепехин төбәкнең 3 авылында – Татар Моклокасы, Мочали, Краснайда була һәм халыкның авыр хәленә, чукындырылганнар белән чукынмаганнар арасында килеп туган дошманлыкка игътибар итә [Лепехин, с. 93, 101–103].

Түбән Новгород тарихы, шул исәптән татарларның көнкүреше, гореф-гадәтләре, Арзамас татарлары тарихы язучы П.И. Мельников хезмәтләрендә урын таба [Мельников]. Язучы, җәмәгать эшлеклесе А.С. Гациский Сергач татарларының тормышын өйрәнә [Гациский, с. 41–42]. Этнограф П. Альбицкийның Кучкай Пожары авылы турында язмалары сакланган. Ул татар авыллары урамнарының, йортларының, ишек алларының үзенчәлегенә игътибар итә: йортларның күбесендә урам ягына – бер тәрәзә, ишек алдына ике тәрәзә карый. Халыкның күбесе (һәр гаиләдән 1–2 кеше) читкә китеп эшли. Кучкай Пожары һәм Камка авыллары халкы кымыз ясау һәм сату белән бөтен тирә-якта дан тоталар [Альбицкий].

Элек-электән авыл халкы зур шәһәрләргә барып йөргән. Бозлау, Татар Моклокасы, Ишавыл, Тукай авыллары халкы – Түбән

Новгород, Камка, Пашат авыллары – Иваново, Грибан, Суыксу авыллары – Донбасс, Мәдәнә авылы Мәскәү белән хезмәттәшлек итә.

Беренче мәдрәсә Куйсуы авылында барлыкка килә, соңрак Сафаҗай, Краснай, Ключищи авылларында да ачыла. О. Романов «День в мусульманской школе» мәкаләсендә (1915) Түбән Новгород өлкәсенең Сафаҗай авылындагы иң зур мәдрәсә турында яза. Актук (Яңапар дигән исеме дә бар) авылыннан чыккан һәм Финляндиядә яшәүче Х. Хәмидулла «Яңапар тарихы» китабында [Хәмидулла, б. 17], С. Хәмид «Ак юл» журналында шушы авыл тарихыннан бик кызыклы мәгълүматлар китерәләр. С. Хәмид «Ак юл» журналының 1973 елгы санында татар-мишәр сүзлеген бирә [Хәмид].

Бу төбәктә татарларның килеп чыгышы турында берничә версия бар. Этнограф Г.Н. Әхмәров XX йөз башында татар-мишәрләр яшәгән урыннарда экспедициядә булып, татар-мишәрләр – алар Азиядән чыккан нугай татарлары, дигән фикергә килә. Алар Идел буена XIII йөздә урнаша башлыйлар. Бу төбәккә алар XVII йөз башында 1612 елгы нугайлар һөҗүменнән соң килеп утыра, дип язып чыга ул [Ахмаров, с. 158–159].

Г.Н. Әхмәров Түбән Новгород өлкәсендәге татар топонимнарының килеп чыгышын шул авылларны нигезләүчеләр исеме белән бәйли. Мәсәлән: Камка авылының икенче исеме – *Чикеев Усад,* Петрякс – *Петров Пүчинкәсе*, Шуба иле – *Шубино* [Ахмаров]. Күп кенә авылларның русча исемнәре бу җирлекнең географик үзенчәлекләрен исәпкә алып бирелгән. Мәсәлән:, *Ендовище (*Яндавишча*), Ключище* (Суыксу), *Красный Яр* (Кызыл Яр), *Овечий Овраг* (Куйсуы), *Красный Остров* (Краснай), *Красная Горка* (Сафаҗай). Кайбер авыл исемнәрендә «авыл» сүзе урынына «ил» сүзе кулланыла. Мәсәлән, *Шуба иле, Мәмәш иле* [Ахмаров].

Түбән Новгород өлкәсендә иң зур авылларның берсе – Сафаҗай авылы (җирле халык «ц»лаштырып аны Сабацай дип йөртә). Ул Пилнә районында, Мәдәнә елгасы буенда, Сураның сул кушылдыгы янында урнашкан. Бүгенге көндә 1100 йорт бар, халкы – 2300 ләп кеше. 5 мәчет бар, мәчет каршында мәдрәсәләр эшли. Мәчеттәге язмаларга караганда, авыл 1451 елда төзелә. 1929 елдан – Кызыл Октябрь, 1944–1957 елларда – Петрякс, 1957 дән – Кызыл Октябрь, 1963 тән Пилнә районында.

Тарихчы галим М.Г. Госманов Түбән Новгород өлкәсенең күп кенә авылларында экспедициядә була. Иң зур авыллардан саналган Сафаҗайда тикшеренү эшләре алып бара. Бу сәфәрдән алган тәэсирләре белән «Заветная мечта Хусаина Фаизханова» (1980) әсәрендә уртаклаша. Авылның русча исеме Собачий Остров булганга, халык телендә Сабачай исеме белән дә билгеле. Соңгы елларда татар матбугатында һәм халык арасында Сафаҗай топонимы киң кулланыла. Авыл интеллигенциясе бу исемне XIX йөзнең икенче яртысында

янгыннан соң калган документка нигезләнеп кабул итә. Сафаҗайның атаклы мулласы Салих бине Сөләйман (1844 елда үлә) һәм Тухтар (1861 елда үлә) да шушы исем турында язып калдыралар [Госманов].

*Сафаҗай* сүзе – кушма сүз, ике тамыр сүздән тора: гарәп сүзе «*сафа*» – күңел рәхәтлеген, тынычлыгын, төрки «*җай*» сүзе тоткан урынның тәртипле икәнен белдерә. Ике сүз бергә кушылып, бу урынның тыныч, рәхәт, җайлы икәнлеген аңлата.

Авыл исеме турында икенче версия дә бар: беренче кешеләр ике елга – Кече Мәдәнә һәм Сабачайка елгалары арасындагы утрауга килеп утыра. Аларга берничә кыргый эт очрый, шуңа күрә алар авылны Собачий Остров дип атыйлар. Галимнәр бу фикер белән килешеп бетмиләр, чөнки беренче килеп утыручылар бер сүз русча белмәүче татарлар була. «Сабачай» топонимы татар сүзеннән алынган булырга тиеш. Ул ике тамырдан тора: *«саба»* һәм *«чай»*. *Саба* – киң таралган татар сүзе, ул татарларда кеше исемен *(Саба – морза Кучкайның әтисе),* төркиләрдә сыйфатны *(саба җиле),* Түбән Идел буеннан күченгән болгарларда кабилә исемен аңлата. Сабачай атамасының нигезендә «саба» тамыры – этноним, ул кабилә исемен белдерә. «Чай» сүзе борынгы төрки телдә елга төшенчәсен аңлата. Моңа мисал итеп кара елганы белдерүче «Карачай» этнонимын алырга мөмкин [Орлов, 1992].

Авылның Собачий Остров дигән рус исеменә кайтсак, тагын мондый версия дә бар: XIV йөзнең 2 нче яртысында Сура елгасы буена руслар килеп утыра һәм алар Сафаҗай авылы халкы белән аралаша башлый. Авылга Собачий Остров атамасын алар кушалар. Төрки кабиләләр хайваннарга табынган. Болгарларда ул – барс, бүре, нугайларда эт була [Орлов, 2001].

Түбән Новгород өлкәсенең татар топонимикасы күпмедер дәрәҗәдә өйрәнелгән, дияргә була. Ләкин бу фәнни эшләр формаль рәвештә генә бара, чөнки авыл атамалары татар тарихы һәм этимологиясе, төрки ономастика үзенчәлекләрен исәпкә алып түгел, ә рус этимологиясенә таянып аңлатыла. Киләчәктә галимнәребез Татарстаннан читтәге, шул исәптән Түбән Новгород өлкәсендәге татар авыллары атамаларын өйрәнүгә игътибарны көчәйтсеннәр иде.

**Әдәбият**

*Альбицкий П.А.* У мишарей. Этнографические наброски // Нижегородские губернские ведомости. 1890. № 31.

*Ахмаров Г.Н.* О языке и народности мишарей // Изв. ОАИЭ Т. 19. Вып. 2. Казань. 1903. С. 158–159.

*Гациский А.* Нижегородские татары – татары ли? // Нижегородские губернские ведомости. 1886. № 39. С. 41–42.

*Госманов М.Г.* Заветная мечта Хусаина Фаизханова. Татар. кн. изд-во. 1980. 223 с.

*Лепехин И.И.* Дневные записки путешествия по разным провинциям Российского государства. 1768–69 гг. СПб., 1771.

*Мельников П.И.* Полное собрание сочинений. Т. 12.

*Орлов А.М.* Мещера, мещеряки, мишари. Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. 97 с.

*Орлов А.М.* Нижегородские татары: этнические корни и исторические судьбы (очерки). Нижний Новгород, 205 с.

Татарская энциклопедия. Казань, ИТЭ, 2008.

Хәмид С. // Ак юл. 1973.

*Хәмидулла Х.* Яңапар тарихы. 1667–1919. Хельсинки. 1954.

***Габдрахманова Венера Абдулла кызы,***

*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты Энциклопедистика үзәгенең татар текстларын тәрҗемә итү бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.09

*М.И. Ибраһимов*

# ХӘЗЕРГЕ ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕНДӘ МИЛЛИ ҮЗТӘҢГӘЛЛЕК МӘСЬӘЛӘСЕ

В статье рассматривается проблематизация понятия «национальная идентичность литературы» в современном литературоведении. На основе анализа трудов русских философов и татарских интеллектуалов начала XX века в контексте современных концепций национальной идентичности определяются перспективы развития данной теории. Эти перспективы видятся в развитии идей множественности и различия языков, литератур, культур в рамках новой научной парадигмы – поссибилизма, методологической основой которого является не логоцентризм, а открытие потенциальных множественных возможностей культуры.

**Ключевые слова**: национальная идентичность, множественность литератур, национальные литературы, поссибилизм.

Соңгы елларда гуманитар фәннәрдә миллилек мәсьәләсенә игътибар үсү очраклы күренеш түгел. Ул заманның сәяси, социаль, этник проблемалары белән турыдан-туры бәйләнештә тора. Алар арасында Җир шарының төрле урыннарында һаман кабатланып торган халыкара бәрелешләр, дини каршылыклар, шул ук вакытта Көнбатышта тамырланган глобализация һәм мультикультурализм концепцияләренең кризисы беренче урында тора.

Әлбәттә, миллилек мәсьәләсе гуманитар фәннәр өчен яңа проблема түгел: һәр чорда төрле милләт галимнәре, философлары бу мәсьәләгә үзләренең күпсанлы хезмәтләрен багышлаган.

Озак еллар әдәбият белеме өлкәсендә «миллилек»нең синонимы буларак «милли үзенчәлек» (национальное своеобразие) термины кулланылды. 1990 еллардан башлап бу термин белән янәшә чит ил фәненнән кергән «тәңгәллек» («идентичность»; *ингл.* identity) термины файдаланыла, ләкин милли әдәбиятларны өйрәнгәндә бу термин актив кулланылса да, аның теоретик мәгънәсе әлегә ачылып бетмәгән. Рус әдәбияты белгече С.И. Кормилов, «милли үзтәңгәллек» («национальная идентичность») һәм «милли үзенчәлек» («национальное своеобразие») төшенчәләрен аерып, болай дип яза: «Национальное своеобразие литературы и ее национальная идентичность не одно и то же хотя бы потому, что своеобразие литературы зависит не только от национальных культурных процессов, начинает формироваться раньше, чем складываются нации. Например, в «Слове о полку Игореве» содержатся яркие черты национального своеобразия русской литературы, рассматриваемой как тысячелетняя, хотя появился этот памятник до возникновения не только русской нации, но

и великорусской народности, до разделения древнерусской народности на великорусскую, украинскую и белорусскую» [Кормилов, с. 8].

Я.Г. Сафиуллин «милли үзенчәлек» төшенчәсенең нигезен милли әдәбиятларны тигезләү стратегиясендә, аларны бер калыпка китерүдә күрә [Сафиуллин, 2010, с. 30].

2000 елда «Знамя» журналы «Национальная специфика литературы – анахронизм или неотъемлемое качество?» дигән тема буенча дискуссия уздыра. Фикер алышуда танылган галимнәр һәм тәнкыйтьчеләр дә катнаша.

Лев Аннинский фикере буенча, Умберто Эко, Милорад Павич кебек язучыларның әсәрләрендә миллилекне тою өчен, уку процессында аларны үз әдәбиятың һәм мәдәниятең контекстына кертү зарур: «…Разумеется, читая Умберто Эко или Милорада Павича, я могу вычленить то общее, что у них есть и что отходит на уровень “глобальности”, точно так же, как я могу уловить, где там итальянское, а где югославянское. Ну и что? А то, что по-настоящему я в этот опыт вникну не тогда, когда соотнесу его с теми или иными умопостигаемыми сущностями, а лишь тогда, когда переживу его – как свой. То есть когда он станет моим – русским опытом. Когда я введу его в контекст моей культуры» [Национальная…].

Ч. Айтматов, О. Сөләйманов, Ю. Рытхэу, И. Губерман, Д. Рубина кебек язучыларның миллилеге мәсьәләсен күтәреп («На пространстве русского языка, кроме русских, и киргиз Айтматов, и казах Сулейменов, чукча Рытхэу... Какую литературу они пишут: киргизскую? казахскую? чукотскую?.. Или ныне – в Израиле эмигранты из России пишут на русском языке: Игорь Губерман, Дина Рубина и много... Так что они пишут? Еврейскую литературу на русском языке?.. Или – общечеловеческую литературу на русском языке?»), андый, рус телендә иҗат иткән, ләкин үзләре рус булмаган (Ч. Айтматов – кыргыз, О. Сулейменов – казах, Ю. Рытхэу – чукча, И. Губерман һәм Д. Рубина Израильдә яшәүче язучылар) әдипләрнең иҗат үзенчәлеген галим Георгий Гачев Логос һәм Этнос диалогында күрә: «Ибо как личности, индивидуальные “я” прибегают к Слову-Логосу русскому как родному для них, естественному, хотя не скажешь про них, что “с молоком матери” в них вошло, ибо кровь и плоть в них нерусская...

В таких авторах – диалог Логоса и Этноса, и в силовом поле напряжений меж ними – и идет творчество, сюжеты, проблемы, оригинальность образуется – и неповторимый вклад в мировую литературу» [Национальная...].

М. Эпштейн, «әдәбият һәм тел» мәсьәләсен күтәреп, рус алфавитының киләчәктә латинлаштыруга дучар булачагын фаразлый: «Латинизация русского алфавита – перспектива хоть и пугающая, но вполне осязаемая уже к концу нашего нового века, по крайней мере, для нехудожественной словесности. Стандарты письменного общения, нормы внятности задаются

электронными средствами коммуникации, а кириллица мало того, что маленький островок в море электро-письмен, она еще сама раздробила себя на несколько кодировок, из-за чего многие русские переписываются на латинице. Этот период "новофеодальной" раздробленности вряд ли пройдет без тяжелых последствий для кириллицы: латиница ее начинает вытеснять даже среди русскоязычных» [Национальная…].

XXI гасыр башында куелган миллилек мәсьәләсенә бәйле сораулар әле дә үз әһәмиятен югалтмаганнар. К. Солтанов әдәбият белемендә (милли әдәбиятларны өйрәнү өлкәсендә) этник мәсьәләләргә игътибар артуның, уңай ягы белән беррәттән, тискәре ягын да билгели, чөнки, галимнең фикере буенча, әдәби анализда этник элементларны табу максаты кайбер вакытта эстетик критерийларны артка чигерә һәм әсәргә бәя бирүнең төп нигезенә әверелә: «Принцип этнической опознаваемости явно теснит на периферию анализа собственно эстетические критерии, соотносимые с полнотой и целостностью художественного текста» [Султанов, 2007, с. 6].

Г. Гачев белән Я. Сафиуллин фикерләре аваздаш: галим әдәбиятчылар арасында киң таралган «рус телле әдәбият» (русскоязычная литература) терминының эчтәлексез булуы турында язалар. Я. Сафиуллин ул терминның барлыкка килүен иҗтимагый һәм сәяси дискурста актив кулланылган «русскоязычное население», «русскоязычные школы», «русскоязычная пресса» кебек гыйбарәләрне (аларның кулланышы СССР таркалудан соң активлаша, чөнки рус телендә сөйләшкән меңнәрчә кешеләр яңа милли дәүләтләрдә «рус телле гражданнар» буларак идентификацияләнә башлыйлар) әдәбият өлкәсенә күчерү (экстраполяция) процессы белән бәйли [Сафиуллин, 2010, с. 29–30].

Я.Г. Сафиуллинның СССРдагы алфавит алышынуга караган фикерләре дә игътибарга лаек: 1920–1930 елларда милли телләрне башта латиницага, соңыннан – кириллицага мәҗбүри рәвештә күчерү мәдәни һәм әдәби күптөрлелек мөмкинлеген юкка чыгарды [Сафиуллин, 2017, с. 171–180].

Хәзерге әдәбият белгечләре әдәбиятта милли үзтәңгәлекне өйрәнү өчен төрле методлар тәкъдим итәләр. Күп очракларда ул ысул әдәби әсәрдә миллилекнең чагылышын табу белән чикләнә. Кайбер галимнәр миллилекнең чагылышын образлар һәм мотивлар системасында (милли образларда һәм мотивларда) күрәләр, кайберәүләр архетип төшенчәсен яңача кулланып, милли архетиплар турында язалар [Есаулов; Большакова, 1996, с. 3–12], күпсанлы хезмәтләрдә әдәби әсәрләрдәге милли концептлар тикшерелә [Зусман; Галиева, Нагуманова, с. 88–100]. М. Бахтин теориясенә нигезләнгән милли әдәбиятлар арасында диалогларны тикшерү методы да әдәбиятларның миллилеген ачыклауда зур мөмкинлекләрен күрсәтте [Аминева].

Күрсәтелгән методлар әдәбият белемендә һәм, гомумән,

гуманитар фәннәрдә инде күптән нәтиҗәле кулланыла. Шул ук вакытта аерым галимнәр фәндә яңа парадигма турында сүз йөртәләр.

«Проективный философский словарь» дип исемләнгән сүзлектә аның төзүчеләре һәм авторлары яңа парадигманы «поссибилизм» (*ингл*. possible – мөмкинчелек) дип билгелиләр. «Достойная современного философа задача, – дип яза Г.Л. Тульчинский, – не переделывать мир, а открывать его возможности, потенциировать бытие. Поэтому гуманитарий и интеллектуал наших дней не столько строит объяснения, наивно сводя все разнообразие к чему-то одному, какому-то первопринципу, не разрабатывает идеологии и программы преобразований, а, в первую очередь, открывает и умножает возможности бытия и его осмысления. Сегодняшний гуманитарий – потенциатор бытия, тот, кто открывает новые возможности культуры» [Тульчинский].

Әдәбият фәнендә (миллилекне өйрәнү өлкәсендә дә) күп еллар кулланылган «милли үзенчәлек» төшенчәсе андый мөмкинлекне тудыра аламы?

«Милли үзенчәлек» төшенчәсен Я.Г. Сафиуллин ясалма рәвештә «яши торган», уйдырма әдәбият булуы белән аңлата. Милли әдәбиятлар күп очракларда шул «идеаль» әдәбиятка мөнәсәбәттә тикшереләләр һәм, нәтиҗәдә, аларның үзенчәлекләре ачыклана.

Поссибилизм әлеге логикага каршы чыга, чөнки ул күптөрлелек (множественность) идеясенә нигезләнгән, ягъни әдәбиятлар өчен бер генә үсеш юлы мөмкин түгел: поссибилизм һәрбер милли әдәбиятның төрле үсеш мөмкинчелекләрен күздә тота.

Әйтергә кирәк: бу парадигмага инде XX йөз башында кайбер Европа, рус һәм татар галимнәре дә якын килгәннәр иде.

XX йөз башы татар галимнәре (Җ. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Г. Ибраһимов, Г. Шәрәф), миллият мәсьәләләрен тикшергәндә, һәр милләтнең үз милли идеясе булу һәм ул идея башка милли идеяләр белән диалогта, алар белән баетылып һәм, үз чиратында, аларны баетып кына яши ала дип фаразлаганнар. «Ләкин яхшы миллият, – дип яза Г. Гобәйдуллин, – һичбер вакытта бер фикер, бер идея, бер гомум мәдәният тудыру белән калмый, алар аны яңартып тора, яхшыларын чит миллиятләрдән ала» [Газиз, 1913, б. 397].

Моңа аваздаш фикер Җ. Вәлидинең «Милләт вә миллият» дип аталган хезмәтендә очрый: «Тәназыге бәка *(яшәү өчен көрәш)*, хәят вә истикъял *(бәйсезлек)* юлында дөньяның астын-өсткә китереп бетерүче, җимерүче, төзүче, очыручы, үрчетүче... әлхасыйльб *(бер сүз белән әйткәндә)*, бөтен силсиләи тарихияне *(тарихи вакыйгалар чылбырын)* ошбу булган шәкел *(форма)* вә тәртип үзрә төзәтүче вә сәйярымызның *(хәрәкәтебез)* өстенә хәзерге хәлендә тотучы гамәлләрне, куәтләрне эзләгәндә без миллият идеясенә бу эшләрдә иң күп галякадар *(бәйләнеш)* күрәмез» [Вәлиди, б. 42]. Галим инсаниятне алга барган бер

пароходка тиңләп, аның палубадагы иркен йөргән пассажирларын дөньядагы милләтләр белән чагыштырып, милләтләр палубадагы пассажирлар кебек үз юлы (идеяләре) белән яшәсәләр дә, аларның шул ук вакытта инсаният юлы белән дә баруын әйтә.

Әлеге идеяләр XX йөз башы кайбер рус философлары фикерләренә якын. Мәсәлән, Н. Бердяев, «рус идеясе» турында уйланып, һәрбер халыкның (кешенең) инсаниятkә үз милли идеясе аркылы гына якынаю мөмкинлеге турында яза: «Человек входит в человечество через национальную индивидуальность, как национальный человек, а не отвлеченный человек, как русский, француз, немец или англичанин. Человек не может перескочить через целую ступень бытия, от этого он обеднел бы и опустел бы. Национальный человек – больше, а не меньше, чем просто человек, в нем есть родовые черты человека вообще и еще есть черты индивидуально-национальные. Можно желать братства и единения русских, французов, англичан, немцев и всех народов земли, но нельзя желать, чтобы с лица земли исчезли выражения национальных ликов, национальных духовных типов и культур. Такая мечта о человеке и человечестве, отвлеченных от всего национального, есть жажда угашения целого мира ценностей и богатств» [Бердяев, с. 305].

Н. Трубецкой, гомумкешелек мәдәният идеясен инкяр итә, миллият идеясен яклап чыга: «Но общечеловеческая культура, одинаковая для всех народов, – невозможна. При пестром многообразии национальных характеров и психических типов такая «общечеловеческая культура» свелась бы либо к удовлетворению чисто материальных потребностей при полном игнорировании потребностей духовных либо навязала бы всем народам формы жизни, вытекающие из национального характера какой-нибудь одной этнографической особи» [Трубецкой, с. 111].

Димәк, инде XX йөз башында рус һәм татар интеллектуаллары миллиятне инсаниятнең күптөрлелек нигезе итеп таныйлар.

Әйтергә кирәк, татар зыялылары бу идеяләрне әле 1920 елларда да күтәргәннәр. Мәсәлән, 1926 елда Бакуда үткән Беренче тюркология корылтаенда Г. Ибраһимов җитәкләгән татар делегациясе һәрбер төрки халыкның мөстәкыйль рәвештә элифба мәсьәләсен хәл итү хокукын яклап чыга. Россиядә яшәгән төрки милләтләр өчен (һәм башка, төрки булмаган, милләтләр өчен дә) мондый позициянең прогрессив булуы шик тудырмый: аның нигезен төрки телләрнең, әдәбиятларның, мәдәниятләрнең күптөрлелеге, һәрбер телнең һәм әдәбиятның үз тарихы булуы, һәм шул ук вакытта телләр, әдәбиятлар арасында бәйләнешләрне тану тәшкил итә.

Корылтайга бәйле чыгышларында Г. Ибраһимов төрки телләр һәм әдәбиятлар арасындагы мөнәсәбәтләрне «әдәбимәдәни федерация» дип билгели: «Төрек телләренең һәрберенең аерым хасиятләре дә, һәммәгә

уртак хасиятләре дә бар. Шуңа карап телләр үзләренең эчке төзелешләрендә мохтар-автоном үсәләр, әмма гомуми нигезләре буенча бер-беренә бәйләналар. Без моны "әдәби-мәдәни федерация" дип атасак, ачык булачактыр. Бу нигездә барганда, телләр җирле халыкка бәйләнеп, массадан аерылмаячак, шуның белән бергә, югары менгән-үскән саен, якынлаша барачак» [Ибраһимов, 1987, б. 273].

Г. Ибраһимов фикере буенча, төрки халыкларның әлифба реформасына төрле мөнәсәбәтләре аларның тарихи үсеше белән бәйле. Галим татар теленең һәм әдәбиятының латинга күчүе татар мәдәниятенә зарар китерү дип яза: «Хәзер безнең типографияләребез, хәреф җыючыларыбыз, мәктәпләребез, укытучыларыбыз, язучыларыбыз, басылып тарала торган дәреслекләребез, йөз мең басыла торган әлифбабыз, көтепханәләребез, караңгы авыллардагы уку өйләребез – һәммәсе, һәммәсе шул төзәтелгән гарәп хәрефләре нигезендә матбугат һәм әдәбиятка корылганнар. Халкыбызның 30% ы шул хәреф белән укыргаязарга өйрәнгәнләр. Менә бу зур мәдәни хәрәкәт машинасы туктаусыз әйләнеп эшләп тора. Латинга күчү дигән сүз – бу машинаны туктатып, яңа нигездән яңадан-яңа юлларга күчереп утырту, үсеп торган мәдәни хәрәкәтнең барышын акырынайту дигән сүздер» [Ибраһимов, 1987, б. 283–284].

Шул ук вакытта, аның уйлавынча, башкорт, кыргыз, якут телләренә латинга күчу шундый ук зарарлы булмаска да мөмкин: «Әмма Башкортстанга, Якутстанга яки Кыргызстанга килсәк, без аларның латинны алабыз, дип бик җиңел генә карар бирүләренең сәбәбен яхшы аңлыйбыз. Башкорт әдәбиятының беренче адымлары Бабичтан башлана. Киңәеп китүенә әле ике генә ел. Шуңар күрә алар зур бер мәдәни хәрәкәтне бөтенләй яңа рельсләргә күчерү кебек мәсьүлият алдында түгелләр. Шулай ук... Кыргызстанда да ... әлифба да, матбугат та яңа туып килә, мәктәпне яңа ачалар, мөгаллимне яңа хәзерлиләр. Болар үзләре алдында туктаусыз эшләп торган машинаны сүтеп, яңа нигезгә кору мәшәкъкатен түгел, бәлки бөтенләй буш урынга яңа бина салу, шуңа нигез сайлау кебек бер эш алдында торалар» [Ибраһимов, 1987, б. 284].

Кызганыч, ләкин 1920 елларның икенче яртысыннан телләрне, әдәбиятларны һәм мәдәниятләрне тигезләү процессы күптөрлелек идеясен озак елларга юкка чыгарды. Хәзерге гуманитар фәннәрдә яңадан торгызылган бу идеянең киләчәген белү читен: тарихны, белгәнебезчә, күрәзәләү мөмкин түгел.

**Әдәбият**

*Аминева В.Р.* Типы диалогических отношений между национальными литературами (на материале произведений русских писателей второй половины XIX века и татарских прозаиков первой трети XX века). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2010. 476 с.

*Бердяев Н.* Судьба России // Бердяев Н. Русская идея: Основные проблемы русской мысли XIX века и начала XX века. Судьба России. М.: ЗАО «Сварог и К», 1997.

*Большакова А.Ю.* Типология и менталитет // Филологические науки. 1996. № 6. С. 3–12.

*Вәлиди Җ.* Милләт вә миллият // Җамал Вәлиди: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2010.

*Газиз Г.* Милләтне ничек аңлыйсыз? Мөкәддәмә // Аң. 1913. № 22. С. 395–398.

*Галиева А.М., Нагуманова Э.Ф.* Национальные концепто- и смыслосферы// Межкультурная коммуникация: филологический аспект: словарь-справочник. Казань: Отечество, 2012. С. 88–100.

*Есаулов И.А.* Пасхальность русской словесности. М.: Кругъ, 2004. 560 с.

*Зусман В.Г.* Диалог и концепт в литературе. Нижний Новгород: Деком, 2001. 168 с.

*Ибраһимов Г.* Тюркология съезды нәрсә бирде? // Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Т. 8: Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 271–276.

*Ибраһимов Г.* Тюркология съездында тикшерелеп үтелгән мәсьәләләр // Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Т. 8: Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 281–299.

*Кормилов С.И.* Своеобразие русской литературы и проблема ее националь-ной идентичности // Известия Южного федерального университета. Фило-логические науки. 2007. № 1–2. С. 8–21.

Национальная специфика литературы: анахронизм или неотъемлемое ка-чество // Знамя. 2000. № 9. [Электронный ресурс] // URL: http://znamlit.ru/publication.php?id=1233 (дата обращения: 18.03.2018).

*Сафиуллин Я.Г.* Идентичность литературная // Теория литературы: словарь для студентов. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2010. С. 29–30.

*Сафиуллин Я.* «Русская литература» и «Русскоязычная литература» – сино-нимы? [Электронный ресурс] // URL: http://kpfu.ru/staff_files/F1591431257/Fragment._2_.pdf (дата обращения: 18.03. 2018).

*Сафиуллин Я.Г.* Крутые повороты: арабица, латиница, кириллица // Ка-занский альманах. 2017. С. 171–180.

*Султанов К.* От дома к миру: этнонациональная идентичность и межкуль-турный диалог. М.: Наука, 2007.

*Султанов К.* К вопросу об «этнокультурном повороте» в изучении литера-тур народов России// STEPHANOS. 2015. № 2. С. 10–19.

*Трубецкой Н.* Об истинном и ложном национализме // Трубецкой Н. Наследие Чингисхана. М.: Аграф, 2000.

*Тульчинский Г.Л. Эпштейн М.Н.* Проективный философский словарь [Электронный ресурс]//URL: https://www.twirpx.com/file/459816. (дата обра-щения: 18.03.2018).

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 4.1.3 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Ибраһимов Марсель Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Ф.Х. Миңнуллина***

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ТРАГЕДИЯ ЖАНРЫ

В статье рассматриваются пути развития и современное состояние жанра трагедии в татарской драматургии. Выявлены причины и условия ее зарождения. Кроме того, подробно изучен процесс развития жанра трагедии с точки зрения поднимаемых в них тем и проблем. Если трагедии, основанные на религиозных сюжетах, мифах и легендах, были написаны на первом этапе, то во втором – преобладали произведения, отображающие исторических личностей и историю татарского народа.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, трагедия, герой, личность, пьеса, конфликт.

Сәхнә әсәрләре языла башлау, тарихи шартларга бәйле рәвештә, төрле халыкларда төрле чорларга туры килә. Татар драматургиясенең формалашуына XIX гасыр ахыры – XX йөз башындагы ил, халык тормышындагы тирән үзгәрешләр, татар интеллигенциясенең дөньяга карашы үзгәрү сәбәп була. Трагедия жанры исә XX йөз башында тигезлек һәм ирек мәсьәләләре кыю рәвештә күтәрелгән дәвердә языла. «*Трагедияләрдә гадәттә кешелекнең яшәеше, тарих хәрәкәте кебек дөньякүләм әһәмияте булган зур иҗтимагый-социаль, фәлсәфи мәсьәләләр куела»* [Әдәбият белеме сүзлеге, б. 186]. Мәгълүм ки, татар халкының тормышы, тарихы фаҗигаләр белән тулы. 1552 елда Явыз Иванның Казан ханлыгын яулап алуы – шуларның берсе. Г. Исхакыйның мөселман халыкларын, беренче чиратта татарларны көчләп чукындыру вакыйгалары тасвирланган «Зөләйха» (1912) трагедиясенең нигезендә нәкъ менә шул фаҗигаләр ята. Автор Зөләйханы гаиләсеннән аерып, рус кешесенә кияүгә бирүне һәм көчләп чукындыруны милләт тормышында зур фаҗига дип бәяли. Трагедияләр үзәгендә үткенәйтелгән тирән конфликтның булуы шарт. Фәтхи Бурнашның (1898–1942) «Зөләйха»дан соң язылган «Таһир – Зөһрә» шигъри трагедиясендә Таһирның хан хакимиятенә каршы күтәрелүенең һәм мәхәббәте өчен алып барган көрәшенең нигезендә трагик каршылык ята. Гуманистик идеяләр өчен көрәшүче герой, үлем алдында торганын белгәндә дә, ирек һәм дөреслек, мәхәббәте өчен көрәш алып бара. Беренче карашка, «Таһир – Зөһрә» әсәре 1917 елгы Октябрь инкыйлабын хуплап иҗат ителгән кебек. Икенче яктан, Ф. Бурнаш совет хөкүмәте алып барган сәясәт белән дә килешми. А. Әхмәдуллин язганча: *«Гөл патшалыгы күренеше – драматургның җирдәге тормышка каршы булган икенче төрле дөнья турындагы сагышлы хыяллары ул»* [Әхмәдуллин, 1988, б. 30]. 1917 елдан

соң татар әдәбиятында дини сюжетларга, мифларга, легендаларга мөрәҗәгать итү күзәтелә. Идеологик басым гаять көчле булуга карамастан, язучылар инкыйлаб идеяләре белән гомумкешелек идеалларын чагылдыралар. Мондый әсәрләр арасында Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе» (1921), К. Тинчуринның «Зар» (1923) әсәрләре аерым урын алып тора. Мәсәлән, «Җир уллары трагедиясе»сендә шәхес азатлыгы мәсьәләсе дини мифологик сюжет аша җиткерелә. Идея белән Кабил һәртөрле явызлыкка, шәхесне рухи яктан изүгә каршы көрәшкә күтәрелгән көчләр буларак сурәтләнә. Җир улларының иң зур фаҗигасе азатлык, ирек булмау белән билгеләнә.

Совет чорында трагедия жанры, Бөек Ватан сугышы, коллективлаштыру, репрессияләр кебек фаҗигале вакыйгалар булуга карамастан, читтәрәк кала. Бу жанр өлкәсендә Бөек Ватан сугышы елларында Н. Исәнбәт кенә илхалык язмышына бәйле тарихи вакыйгаларны, масштаблы каһарманнарны гәүдәләндерү юнәлешендә активлык күрсәтә. Борынгы Римда коллар күтәрелешенең фаҗигале күренешләрен сурәтләгән «Спартак» (1940), Алтын Урда чорының тарихи каһарманына багышланган «Идегәй» (1940), Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең фашист тоткынлыгындагы батырлыгын татар әдәбиятында беренче булып чагылдырган «Муса Җәлил» исемле трагедияләре (1956) шундыйлардан. Трагедияләрнең төп каһарманнары, гадәттә, көчле шәхес буларак ачыла. Н. Исәнбәт тә Мәрьямнең, Спартакның, Муса Җәлилнең кешелек идеаллары өчен борчылуын, газаплануын алга куя. «Муса Җәлил» трагедиясендә шагыйрь белән илбасарлар арасында барган фаҗигале бәрелеш Җәлилнең ватанчылык хисен, халкына, Туган иленә бирелгәнлеген күрсәтә. Шул рәвешле, сыйнфый көрәш идеясе сугыш елларында дошманга каршы нәфрәт белән алмашына. XX гасырның 60–80 нче елларында язылган И. Юзеевның «Соңгы сынау» (1968), Н. Фәттахның «Кол Гали» (1973) трагедияләрендә Кол Гали, Муса Җәлилләр эшчәнлегенә яңача бәя бирү көчәя. И. Юзеевның «Соңгы төн» трагедиясендә, бер яктан, шагыйрьнең фаҗигале язмышы тасвирланса, икенче яктан, М. Җәлилнең батырлыгын сурәтләп, заманында аның тапланган исемен аклау юнәлешендә тагын бер зур адым булып тора. Милли чынбарлыкка, үткәнгә, бүгенгегә игътибар үсү исә тема-проблематикага тәэсир итә. А. Гыйләҗев, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин кебек каләм ияләре драматургиядә яңа эзләнүләр юлына керәләр. Шартлы-мифологик, символик образлар ярдәмендә җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең кешегә йогынтысын күрсәтү көчәя.

Трагедия жанрында язылган бер төркем әсәрләрне милли тема берләштерә, аларда милләт язмышы, гореф-гадәтләрнең сакланышы, катнаш никахлар һ.б. проблемалар күтәрелә. Шулар белән янәшә совет тәртипләрен, системасын фаш итү, идеологиянең кешене шәхес буларак юк итүдәге роленә дә басым ясала.

Фаҗигалелек категориясен шәхес ялгызлыгында, чынбарлык белән трагик каршылыкта чагылуын, мәсәлән, А. Гыйләҗевнең «Өч аршин җир» трагедиясендә күрергә мөмкин. Ил күләмендә башланып киткән колхозлаштыру Мирвәли белән Шәмсегаян язмышына фаҗигале тәэсир итә. Трагедиянең төп герое Мирвәли шул вакытта трагик хата ясый: йортына ут төртеп, малларын агулап, авылдан чыгып кача. Драматургның төп максаты – совет чоры яклаган геройны түгел, ә үз җиреннән аерылган кешенең газап чигүен, фаҗигасен күрсәтү. Аның кылган гамәлләре дә авылдашларына карата түгел, ә урнашкан, халыкны коллык дәрәҗәсенә төшергән системага каршы юнәлдерелгән.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең тагын бер нәтиҗәсе – татар халкының тарихына, тарихи шәхесләренә мөрәҗәгать итү. Ю. Сафиуллинның Алтын Урда дәүләтенең таркалуын тасвирлаган «Идегәй», Р. Хәмиднең Казан ханлыгын, аның рус дәүләте тарафыннан яулап алыну вакыйгалары яңача бәяләнгән «Хан кызы», М. Маликованың «Сөембикә» трагедияләре шундый әсәрләр рәтенә керә. Мәсәлән, Ю. Сафиуллинның «Идегәй» трагедиясендә Туктамыш, Идегәй, Норадын фаҗигасе тулы бер дәүләтнең һәлакәте аркылы ачыла. Төп каһарманнарның үзләре алып барган сәясәтне генә дөрес санап, төрле юллар белән хакимият өчен көрәш алып баруы куәтле, гайрәтле зур илнең юкка чыгуына китерә. Ю. Сафиуллин, Н. Исәнбәттән аермалы буларак, Идегәйнең Аксак Тимер ягына чыгып, Туктамыш ханга каршы күтәрелүен «трагик хата» дип бәяли. А. Әхмәдуллин соңгы еллар драматургиясен анализлап, пьесаларда гаҗизлек мотивының киңәюен, еш кына явызлык-караңгылыкның изгелек-матурлыктан өстен чыгуын билгели [Әхмәдуллин, б. 9]. Бу елларда язылган күп кенә пьесаларда, яңа алым-формаларда чагылыш тапкан югалту, кайгы, өметсезлек, курку мотивлары аша «ялгыз кеше, югалган буын трагедиясе»н күрсәтү алга чыга. Яшәешнең камил булмавы, кешенең ялгызлыгы, көчсезлеге хакындагы фикерләр ята. Мисал итеп, Р. Хәмиднең «Актамырлар иле», З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы» трагедияләрен китерергә була. Милли һәм тарихи темалар белән беррәттән, 90 нчы еллар драматургиясендә сугыш темасы да яктыртыла. Ю. Сафиуллинның Чечен сугышы фаҗигасен чагылдырган «Йөзек һәм хәнҗәр» трагедиясе шундый әсәрләр рәтенә керә. Пьеса үзәгенә чечен авылларын җимерүдә катнашкан Линар белән Рәсим һәм аларга каршы йортҗирләрен, сөйгәннәрен югалткан чечен кызлары Хания белән Разия куела. Алар арасындагы конфликт Линарның үлеменә китерә. Аның трагик геройлары – илдәге сугыш сәясәте корбаннары. Җәмгыять кешене ялгызлыкка китерә, шәхес буларак юкка чыгара дигән фикер З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы» пьесасында урын ала. Бала чактан бергә уйнап үскән һәм үзара яратышкан Разим белән Фәнзиләне

тормышыбызда хөкем сөргән тискәре күренешләр үзенә тарта. Шәһәргә укырга киткән кызның күңеленә Илгиз-Шайтан оялый. Разим дә, Илгизә-Шайтан коткысына бирелеп, эчкечелек сазлыгына бата. Психологик киеренке халәттәге кыз чынбарлык белән хыял чигендә яши, ул ниндидер аңсызлык, саташулы хәлдә. Шул вакыйгаларга бәйле рәвештә, әсәргә ике дөнья – реаль һәм мифик дөнья килеп керә. Реаль тормышта – авыл яшәеше, Фәнзилә һәм Разим мөнәсәбәтләре, мифик тормышта Фәнзилә белән Разим күңеленә оялаган Шайтан урын ала. Шайтан котыртуына бирелеп, Разим белән Фәнзилә Шайтан куентыгы дип аталган җирдән сикерәләр. Елгадагы Шайтан куентыгы – тормышның кешеләрне үзенә тарта торган ямьсез яклары буларак кабул ителә. Гомумән, соңгы елларда шартлылыкка, символик образ-сурәтләргә, метафорик күренешләргә игътибар аеруча артты. Драматурглар ялгызлыкка дучар ителгән, якыннары белән уртак тел таба алмаган, яшәешкә үтеп кергән миһербансызлыклардан гаҗиз шәхесләрне әдәбият мәйданына чыгаралар. Р. Хәмиднең «Актамырлар иле» трагедиясе – яшәү һәм үлем фәлсәфәсе, яшь буынның киләчәге, милләт язмышы турында. Драматург тарафыннан әлеге фикерләр Мөштәри карт һәм аның гаиләсе, бердәнбер оныгының тәре тагып йөрүе кебек күренешләр аша бирелә. Татар зиратының ерып булмаслык ташландык хәлдә булуы, Гарриның Фәридәне ата-бабалар рухын саклап торучы иң изге урын – зиратта мәсхәрәләве яшь буында милли-әхлакый сыйфатларның юкка чыга баруын раслый. Ташландык татар авылында дуңгызлар үрчетүче Гәрәйнең кечкенә баласына сөт таба алмыйча, сабыйны ана дуңгызның аягы астына куюы, шул рәвешле баланың тапталып үлүе кебек абсурдлык элементлары аша драматург җәмгыятьнең әхлакый яктан таркалуын күрсәтә. Белүебезчә, трагик конфликт хәл ителмәслек характерга ия. Мөштәри карт көрәше дә хәл ителмәслек фаҗига төсен ала. Әсәрдә аның үзенә кабер казуы ялгызлыкның кешене чарасызлык чигенә җиткерүен күрсәтә. Карт бу хәлнең сәбәпләрен хакимияттән, сугышлардан күрә. Автор Тәңре, Хода кебек шартлы образлар аша Мөштәринең ялгышуын, үз нәселен бу фаҗигаләрдән саклап кала алмавын белдерә [Каюмова, б. 205]. Күренгәнчә, каралган трагедияләрдә герой фаҗигасен тудыручы сәбәпләр социаль җирлек, халык тормышындагы трагик вакыйгалар белән бәйле. Һәр чорның үзенә хас геройлары була. Совет чоры трагедияләрендә исә геройлар үзләре яшәгән җәмгыятьне ныгыту яисә илне дошманнан саклау өчен көрәшәләр. Үзләренең көчсез булуын, үлем алдында торуын белгәндә дә, социаль һәм милли тигезлек, ирек һәм дөреслек, Ватан азатлыгы өчен көчләрен кызганмыйлар. Зөләйха, Таһир-Зөһрәләр, Җәлил, Мәрьям кебек геройлар – билгеле бер тарихи шартлар нәтиҗәсендә туган трагик ситуация корбаннары. А. Саттарова билгеләгәнчә,

хәзерге татар драматургиясендә исә герой төрле яклап сурәтләнә. Алар маргинал, фаҗигале шәхес, маңкорт буларак тәкъдим ителәләр. Трагедияләрнең нигезендә, шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре, яшәү мәгънәсе турында уйланулар, тормышта үз-үзеңне табу мәсьәләләре, шәхси бәхетсезлек проблемалары ята. Кызганыч ки, соңгы елларда трагедия жанры үсеше сүлпәнәя бара. Бу – тамашачыларның күбрәк комедия, музыкаль драма жанрларын өстенрәк күрүе белән дә аңлатыла.

**Әдәбият**

Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 238 б.

*Әхмәдуллин А.* Күңелләрне уятыр: хәзерге татар драматургиясе: монография. Казан: Мәгариф, 2007. 223 б.

*Әхмәдуллин А.* Фәтхи Бурнаш: иҗаты һәм тормыш юлы турында очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 176 б.

*Каюмова Г.И.* Ризван Хәмид драматургиясендә заман һәм шәхес концепциясен бирүдә образ-символлар, сәнгатьчә табышлар // Актуальные проблемы отечественной и зарубежной истории, филологии (взгляд молодых ученых и аспирантов). Институт Татарской энциклопедии АН РТ. Казань, 2013. Вып. 2. С. 202–218.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Л.И. Минһаҗева*

# РОБЕРТ МИҢНУЛЛИННЫҢ БАЛАЛАР ӨЧЕН ИҖАТЫ: ФОЛЬКЛОРДАН ПРОФЕССИОНАЛЬ ПОЭЗИЯГӘ ЮЛ

Статья посвящена творчеству народного поэта Р. Миннуллина, который в этом году отмечает свое 70-летие. Его поэзия занимает особое место в современной татарской детской литературе, для нее характерны морально-этические, социально-философские поиски, интегрирующие ее в литературный дискурс, сформированный татарской творческой интеллигенцией второй половины прошлого века.

**Ключевые слова:** татарская литература, детская поэзия, фольклор, Роберт Миннуллин, стихи, талант, поэтическая школа.

Егерменче гасыр татар балалар әдәбиятының шигърият өлкәсендә ирешкән байтак уңышлары, мәгълүм ки, балалар фольклоры жанрларын шәхси иҗатта уңышлы файдалану нәтиҗәсендә булды. Нәкъ менә шул нигездә профессиональ балалар әдәбияты үз юлын, үз тавышын, үз темаларын, тасвирлау телен булдырды дип әйтергә нигез зур.

А. Твардовский үзенең бер язмасында, «Без балалар әдәбияты, балалар шигърияте дип әйткән өлкә безгә сабый чактан ук таныш. Шигъриятне без иң беренче әниләребезнең бишек җырларыннан ук ишетәбез», дип язды [Твардовский, с. 605]. Күренә ки, күренекле рус шагыйре балалар шигърияте, балалар әдәбияты дип фольклорны атый һәм аларны аерылгысыз бербөтен итеп дәлилли.

Димәк, алда әйтелгәннәрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин: үткән дәверләрдә үк бала тәрбияләү проблемасы, аны әхлаклы, тәрбияле итеп үстерү әти-әниләрнең, милләтнең һәм җәмгыятьнең игътибар үзәгендә булган. Балалар фольклоры һәм балалар әдәбияты – бер үк системаның ике өлеше, балаларга хас үзенчәлеккә ия сүз сәнгатенең төре.

Инде әлеге берлекне, хакыйкатьне тулаем аңлап иҗат итүче талантлы балалар шагыйре Роберт Миңнуллин иҗатына күчик. Аның балалар өчен поэзиясендә фольклор белән аваздашлык игътибарны аеруча җәлеп итә.

Мәгълүм, һәрбер тарихи чорда татар шагыйрьләре фольклорның әһәмиятен аңлап, аны нигез итеп иҗат иттеләр. Мисал өчен, бишек җырларын алыйк. Дәрдемәнднең «Бәллү», Г. Тукайның «Бишек җыруы», М. Җәлилнең «Бишек җыры», «Бишек янында», «Кызыма», Ә. Ерикәйнең «Йокла, балам», М. Мазуновның «Энесенә ул апа», Р. Вәлиевнең «Йокла, энем», А. Хәлимнең «Бишек җыры», Р. Вәлиеваның «Бишек җыры», Ф. Зыятдинованың «Бердәнберем син минем», Э. Шәрифуллинаның «Син минем нәнием» кебек шигырьләре фольклорга таянып иҗат итүнең иң матур үрнәкләре саналырга

хаклы. Әлеге исемлектә, һичшиксез, Р. Миңнуллин исемен атау да хакыйкатькә хилафлык булмас. «Вакытында йокларга ятмаган, йокларга яратмаган кайбер шаянрак малайларга махсус язылган бишек җыры» дип аталган шигырендә, халык авыз иҗаты үрнәкләреннән файдаланып, Р. Миңнуллин да төп хисфикерен миллилеккә юнәлтә. Халык иҗат иткән бишек җырларына, нигездә, традицион кошкорт, хайван образлары килеп керсә, биредә төп герой – бабай образы кулланылган:

Әлли-бәлли бәү,
Минем улым инде дәү!
Йом инде, йом күзеңне,
Тыңла инде сүземне!
Тыңламасаң, бабайлар
Алып китәр үзеңне!

«Әлли-бәлли бәү» авазларын кабатлау нәтиҗәсендә сүзҗөмләләр төзелә, алар бишек җырларында традицион кушымта – «уртак урыннар» – ономатоплардан һәм традицион мотивлардан тора. Беренче карашка гади генә күренгән бишек җырында фәлсәфи эчтәлек тә бар: Р. Миңнуллин шигырьнең һәр юлын, бүген ул тәрбияләгән баланың иртәгә җәмгыятьнең бер вәкиле булачагын аңлап яза, эшнәтиҗә бәйләнешен бирә («Тыңламасаң, бабайлар Алып китәр үзеңне!»), шигырьне халыкчан рух белән баета, җылылык өсти һәм болар барысы да бөтенлекне тәшкил итеп, бишек җырының уңышын билгели.

Гадәти бишек җырларыннан байтак дәрәҗәдә аерылып торган, «ДТ-75 тракторының улына җырлаган бишек җыры» шигырендә дә әти-әниләрнең шәхси хич-кичерешләренә, хыялларына, бала белән бәйле өметләренә зур урын бирелә. Мәгълүм ки, нигездә бишек җырлары олылар тарафыннан сабый бала өчен иҗат ителә һәм башкарыла (нәкъ шушы вакытта сабыйда «балалар сөйләменең башлангычы» һәм үзенчәлекле «аралашу чаралары» барлыкка килә), традицион бишек җырларында бары тик бер генә адресат бар, ул – бала. Р. Миңнуллин очрагында исә бишек җырының адресаты – ДТ-75 тракторының улы. Әсәр уенчыл характерда, шуңа күрә биредә укучы баланың уенга кушылып китү һәм фантазиясен үстерү мөмкинлеге зур. Сүз сәнгатенең иң башлангыч чорында бу алым аның өчен уен, мәтәлчек ату, кул болгау һәм чәбәкләү белән бер үк күренеш кебек. Биредә сүзләр мәгънәсенең асылын тапканчы ук бала авазлар, шигырькүренеш белән таныша:

Йокла, улым, матурым,
Ят, ял итсен моторың,
Бәләкәч тракторым!
Тыр-тыр-пытыр-тыр-тырым,
Пытыр-пытыр-тыр-тырым,
Йокла инде, күз нурым!
Тыр-р-р-р-р-р...
Тыр-р-р-р-р-р-р...

Күренә ки, беренчедән, биредә җансыз предмет – трактор җанландырылып бирелә һәм фикер юмор белән сугарыла. Җыр балалар тормышына якын процесста – уенчык белән уйнау барышында бала исеменнән җырлана, димәк, бала һәм уенчык, өлкәннәр һәм бала тормышы нык

кына якынайтылган. Җансыз предметның җансыз предметка мөрәҗәгате, бу очракта үзгә бер трансформация тибын тудыра. Шуның белән бергә, фольклордан килгәнчә, ономатоплар (аваз охшашлыклары) биредә үзгә бер функция үти, аерым юлларда «р», «к», «т», «м», «п» авазларының еш кабатлануы бишек җырларын тел көрмәкләндергечләргә якын итә, авазларга игътибарны юнәлтә һәм аны дөрес үзләштерү мөмкинлекләрен ача.

Бала тормышында авазларга мөнәсәбәт исә гаять әһәмиятле. Алдарак ассызыклап үтелгәнчә, сүзләрнең мәгънәсен һәм дөрес әйтелешен аңлаганчы, башлангычта әле сабый авазлар дөньясына килеп керә. Автор эмоциональ яктан авазларның әйтелешенә, авазларның яраклашуына, ритм таләбенә буйсынуына, ягъни, шигъри телнең нигезенә игътибарын юнәлтә. Бала өчен үсешнең башлангыч чорында ритм (шигырь) телне өйрәнү ысулы булып тора, бала иң гади булган сузык һәм тартык авазларны туры китереп куллана башлый. Башлап әйтелгән «ән-нә», «әт-тә», «мәм-мәм», «бү-бү» кебек сүзләр, күренә ки, авазлар симметриясенә нигезләнә. Димәк, сабыйның үзендә үк бик кечкенәдән «шигъри» башлангыч ята.

Инде расланганча, балаларның күңел дөньясын, холкын, психологиясен тәрбияләүдә уен формасындагы жанрларның әһәмияте бик зур. Аларның үзенчәлекле төзелешенә игътибар итеп, үз вакытында Р. Кукушкин да: «Бала багу такмакларының ике төп үзлеге күзгә ташлана, беренчедән, алардагы ритмның җиңеллеге һәм билгеле бер хәрәкәт формасына буйсындырылуы; икенчедән, эчтәлекләре белән дә – уйнау-шаяруга, баланың күңелен ачуга юнәлдерелгән булулары», – дип язган иде [Кукушкин, б. 9]. Ягъни, юаткычлар (кузгаткычлар) баланы физик яктан чыныктыру өчен, өлкәннәр тарафыннан төрле күнегүләр һәм хәрәкәтләр ясаткан-да кулланылса, мавыктыргычлар исә бала үсә төшкәч файдаланыла торган жанр. Бу җөмләдән, Р. Миңнуллинның гади юморга нигезләнгән «Күңелле тәнәфес» шигыре милли поэтикага һәм, фольклор кебек үк, зур тәрбияви көчкә ия:

Чылтырый кыңгырау
Дәрестән чыгарга.
Кыңгырау – тәнәфес
Яратучыларга!
Басыйк та бергәрәк,
Тән языйк бергәләп:
Бер, ике, өч...
Көчәйсен безнең көч!
Тик тормау – безнең эш.
Яшәсен күңелле
Тәнәфес!

Фантазиягә, образлы фикергә бай һәм шаян рухта язылган шигырьнең максаты баланы шат, көләч һәм сәламәт итеп тәрбияләүгә юнәлдерелгән, димәк, балалар фольклорына хас төп билгеләр әлеге шигырьнең дә үзәгенә куелган. Мәгълүм ки, балалар шигърияте өчен интонация – ул чынбарлык [Жинкин, с. 36], ягъни хис биредә беренчел вазифаны уйный һәм иҗат процессы күпмедер дәрәҗәдә шигырьне укучы

бала өчен «уен төзү»гә буйсындырыла [Путилова, с. 20].

Шуңа күрә балалар шигыренең әдәби эшләнеше тыныч, салмак һәм әкрен интонациядә була алмый. Ул, беренче чиратта, шатлык, куаныч, шаккату, кызыксыну кебек хис-кичерешләр уятуга йөз тотып языла. Мондый алым эндәшләр һәм сорау-җавап формасында язылган лирик әсәрләргә аеруча хас. Аларда сюжет сызыгы уйланылган, билгеле бер мәгълүмат җиткерү максаты белән язылуы – аның халык авыз иҗаты һәм балалар шигърияте кануннарын белүе белән бәйләнә.

Р. Миңнуллин әсәрләрендә фольклор элементлары төптән уйлап, уңышлы кулланыла. Ул еш кына халык иҗатын шаяртуга нигезләп үзгәртә һәм бу үзгәрешләр укучы өчен кызыклы булып чыга:

Яңгыр, яу, яңгыр, яу,
Иләкләп, чиләкләп,
Пәрәмәчләп, коймаклап.
Арышларның башагы
Ач булмасын, тук булсын,
Сыерларның сөтләре
Аз булмасын, күп булсын!
[Балалар фольклоры, б. 34]

Күренә ки, фольклор әсәрләре җанлы, ритмлы. Бу уңайдан, Р. Миңнуллиннан үрнәк итеп «Яңгыркаем, яу, яу!» шигырен китерергә мөмкин. Биредә ул фольклорның уенлы җырлары образын файдаланып, үз җырын тудыра. «Яңгыр» сүзен иркәләп, яратып «яңгыркаем» дип куллану, иҗатның башлангычыннан ук халык иҗатын үзенә өлге иткән шагыйрьнең кече күңелле мөгаллим булуын да ассызыклый кебек:

Яңгыркаем, яу, яу!
Әйбәт түгел яумау!
Кырлар шундый коры –
Яу шуларга туры!
Явасың бит бик сирәк,
Ә кырга яңгыр кирәк!
Әй лә, әй, болыт бабай,
Яңгырны яудыр тизрәк! –
Безгә ипекәй кирәк!

Әлеге шигырь, күренә ки, халык авыз иҗатыннан, эндәшләргә якын. Мондый такмакларның бик борынгыдан килүен «... аларның төбендә Җир, Су, Күк кебек көчләрнең кодрәтенә ышану ятканлыгын һәм, билгеле, игенчелек белән бәйле булуларын күрергә мөмкин» [Кукушкин, б. 13].

Н. Думавиның «Авыл балаларының яңгыр теләве», М. Җәлилнең «Тилгән», Х. Халиковның «Ятим тургай», Ә. Фәйзинең «Бал корты», Б. Рәхмәтнең «Яңгыр теле», Ш. Маннурның «Кояш, чык, чык, чык!», Ә. Бикчәнтәеваның «Бәтиләр», Ш. Галиевнең «Язгы әкият», Р. Миңнуллинның «Кайтыгыз, кошкайлар!», «Яңгыр җыры» , «Җил авырган бит әле», Р. Вәлиеваның «Яңгыр, яу!» кебек шигырьләре эндәшләрнең кызыклы, тапкыр, уенчыл сыйфатларын файдаланып иҗат ителгәннәр. Димәк, балалар поэзиясе формалашуыннан башлап бүгенге көнгә кадәр, әлеге жанр шулай ук, шагыйрьләрнең игътибарын җәлеп итеп килә.

Яшел җилләр,
Зәңгәр җилләр,
Гел исегез,
Тынмагыз!
Җырлагыз сез!
Без дә сезнең

Җырыгызны тыңларбыз!
Кушылып та җырларбыз!
(«Җиңел җилләр,
җитез җилләр...»).

Р. Миңнуллинның «Җиңел җилләр, җитез җилләр...» шигырендә дә, эндәшләргә хас бер үк сүзнең берничә тапкыр янәшә кабатлануы отышлы. Мондый алым нәниләргә әсәрнең эчтәлеген тиз аңларга, ятларга, яңа сүзләрне җиңелрәк үзләштерергә һәм зиһенне арттырырга ярдәм итә.

Эндәшләргә хас сыйфатлар сабыйларның төрле кошкортларга, бөҗәкләргә, җәнлекләргә мөрәҗәгатендә дә чагылыш таба. Мондый әсәрләр балаларга яңа төшенчә бирү ягыннан әһәмиятле. Чөнки аерым такмакларда теге яки бу җан иясенә хас сыйфатлар күрсәтелә, һәм бу – баланың акыл үсешенә, әлбәттә, тәэсир итми калмый:

И песнәгем, белеп торам,
Күреп торам – туңгансың.
Соң син бит безнең балконга
Җылы эзләп кунгансың.
Йоннарыңны кабарткансың,
Калтырыйсың – күр инде.
Җылыда җырлавы рәхәт –
Әйдә, безгә кер инде!
(«Песнәк белән сөйләшү»).

Мәгълүм ки, балаларның шигъри дөньясы ул – җанлы һәм җансыз табигать тасвиры (тавышы), әти-әни, туганнар яшәеше һәм балалар уены. Шунлыктан, мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен шигъриятә төрле «тавышлар» куллану гадәти хәл: җәнлекләр, хайваннар тавышын чыгару, кошлар чыркылдавын, бөҗәкләр безелдәвен, ата казның ысылдавын яки алар булып сөйләшүне тасвирлау һ.б. Балалар фольклорыннан иярмешләргә хас мондый шигырьләрдә теге яки бу җан иясенә хас тормышчан сыйфатлар күрсәтелә. Күп очракта алар сюжетка юнәлеш биреп кенә калмыйча, баланың акыл үсешенә дә тәэсир итә. Мисал өчен, Р. Миңнуллинның «Чебеннәр, черкиләр», «Акбай, Актүш, Актырнак», «Ата каз», «Тамчы, тамчы», «Һәркайсының үз моңы», «Мырык-мырык», «Чебиләр» шигырьләрен китерергә мөмкин:

Беззз-беззз килгән булалар,
Беззз-беззз көлгән булалар,
Безелдәгән булалар,
«Без! Без!» – дигән булалар.
Бар белгәннәре «Без! Без!
Безгә! Безне! Безме? Без!»
Мактанчыклар! Әйтерсең лә,
Без: «Без! Без!» – ди белмибез
(«Чебеннәр, черкиләр»).

«Чебеннәр, черкиләр» шигырен автор әлеге бөҗәкләр чыгарган авазларга нигезләнеп иҗат итә. Шаян рухта язылган лирик әсәр, бер яктан, «з» авазын артикуляцион яктан дөрес әйтергә өйрәтсә, икенче яктан, әсәрнең тәрбияви максаты да ачык.

«Чебиләр» шигырендәге гадәти күренеш-тасвирның да эстетик тәэсир итү көче зур:

Чи-чи килә чебиләр,
Чи-чи көлә чебиләр.
Чи-чи елый чебиләр,
Чи-чи җырлый чебиләр...
Алар бит «Чи-чи» дигән
Яңа җыр өйрәнәләр.

«Ч» авазының күп тапкырлар кабатлануы чебиләр черелдәвенә иярүне күрсәтә. Нәтиҗәдә, кыска

гына шигырьдә шагыйрь, матур формада, чебиләрнең тормышчан образын һәм тулы бер манзара тудыруга ирешә. Бер үк авазларны кабатлау шигырьнең музыкаль яңгырашын, аһәңен дә тәэмин итә. Шигырьнең төзеклеге һәм алдарак саналган сыйфатлар исә аны иярмешләргә, балалар фольклорына якынайта.

Чебиләр сүзенең күп тапкырлар кабатлануы, бу очракта «текстта парадигматик планның тәртибен барлыкка китерүче фактор» буларак та бәяләнә ала [Лотман, с. 39].

Кояш көлә,
Гел көлә!
Кояш көлгәч,
Көн көлә!
Көн көлгәчтен,
Гөл көлә!
Гөл көлгәчтен,
Кем көлә?
Гөл көлгәчтен,
Мин көләм!
Кояш көлә,
Мин көлгәч!
Шуңа да мин
Гел көләч!
(«Көләч шигырь»).

Әйтергә кирәк, бернинди әдәби текстта да кабатлауларның саны балалар шигъриятендәге кебек күп очрамый. Югарыда без фонетик, морфологик, синтаксик катламнардагы кабатлаулардан мисаллар карап киткән идек. Бу кабатлаулар лирик әсәрдә икенчел рольне үти. «Көләч шигырь»дә исә кабатлаулар, чылбыр такмазалардагы кебек, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә оеша һәм ритм хасил итүче механизм, ритмик-интонацион төзелеш хасил итүче кабатлаулар буларак күз алдына баса. Балалар шигъриятендә бер үк сүзне еш кабатлау поэзиянең кызыклы бер чарасына әверелә һәм гадәти тормыш-көнкүрешнең дә үзенчәлекле якларын ачып бирә. Мәсәлән, әлеге кыска гына шигырьдә «көлә» фигыле төрле формаларда унөч тапкыр кабатлана. Тамырдаш сүзләрне кабатлау – Р. Миңнуллин мөрәҗәгать итә торган алымнарың тагын берсе.

Балалар өчен шигырьләрне төзелеше ягыннан карасак, аерым кабатлауларның чиратлашуы – уен хасил итә:

Әти ипи
Үстерә,
Әни ипи
Пешерә.
Ә мин... мин ипи
Ашыйм.
Ә аннары
Ипине
Үзем үстерә башлыйм!
(«Игенчеләр гаиләсе»).

«Шигъри текстның уникальлеге (кабатланмавы) бары тик күпсанлы кабатлауларның кисешүе һәм чиратлашуы булганда гына мөмкин» [Лотман, с. 114]. Әлеге мисаллар Ю. Лотман фикеренең актуальлеген дәлилләп килә кебек.

Р. Миңнуллинның «Һәркайсының үз моңы» дип исемләнгән шигырендә дә табигать авазларын кабатлаулар иярмеш үзенчәлекләрен хәтерләтә:

Чут-чут, чут-чут, чут-чут итеп,
Чут итеп сайрый урман.
Безнең якның урманнары
Нәкъ шулай сайрый торган...

Бак-бак, бак-бак, бак-бак итеп
Сайрый белә сазлык та.
Му-му диеп җырлый абзар,
Беззз-безз дип – умарталык.
Кыт-кыт дип сайрый кетәклек...
Тыңлыйбыз хәйран калып.

Искиткеч минизоопарк – тулы бер картина күз алдына баса, лирик әсәр куңелле балалар уены, күпме шатлык чыганагы булып оешкан. Табигать тавышларын төрле вариацияләрдә куллану шагыйрьгә төп хисне – соклану, ярату, шатлык хисләрен тудырырга да ярдәм итә.

Шигырьнең тәэсир көче, эмоциональ бизәлеш аллитерация, кабатлаулар ярдәмендә дә көчәйтелә. Кошлар һәм хайваннарның тавышын белдергән ономатоплар, аваз ияртемнәре ярдәмендә исә бала кош-кортларны, бөҗәкләрне һәм, гомумән, дөньяны танып-белергә өйрәтә. Моңа өстәп, биредә баланың тирәлекне җанлы кабул итә белү сәләте дә үзәккә куелган. Мәгълүм ки, балалар табигатьне җанландырып, кешеләштереп күрү сәләтенә ия. Шуңа күрә сабыйлар тарафыннан ясалган рәсемнәрдә дә, еш кына, чынбарлык ничек бар шулай түгел, бәлки алар күзаллавынча, күп вакыт өлкәннәргә аңлашылып та бетмәгән формаларда тасвир ителә.

Р. Миңнуллин иҗатында хайваннарның төрле акустик характеристикаларын, тавыш символларын аңлатучы ономатоплар киң таралган. Мисал өчен, «Ата каз» шигыре:

Ата каз
Мине күрсә,
Янымда
Әгәр йөрсә:
– Тешлим сине,
Ыс-с-с! – ди. –
Тизрәк кереп
Пос-с-с! – ди.
Ә мин әйтәм:
– Посмыйм!
Мин бит синең
Дус-с-с! – дим.

Хайваннар һәм кош-корт тавышларына охшатып ясалган ономатоплар, гомумән, ономатопларның тавышлар рәте (системасы) шагыйрь иҗатында күптөрлелеге белән аерылып тора. Мондый шигъри тел табигатьне, әйләнә-тирәлекне сурәтләү һәм аларның характерларын күрсәтү өчен бик уңышлы.

Тамчы тамуны белдереп, кинәт була торган ономатоплар, шулай ук яшәешнең төрле якларын чагылдыра:

Тамчы, дисәң,
Тып та тып!
Булмый гына
Туктатып:
Тып та тып!
Тып та тып!
Булмый гына
Йоклатып:
Тып та тып!
Тып та тып!
(«Тамчы, таммачы!»).

Шигырьдә «тып та тып» ономатобы сюжет оештыручы башлангыч та булып тора. Мондый иярмешләр формальне эчтәлекле итүдә: образ тудыруда, уенчыл сюжет оештыруда һәм, ниһаять, эмоцияләр бирелешен тәэмин итүдә әһәмиятле:

Шыбыр-шыбыр
Шыбырдап,
Шыгыр-шыгыр

Шыгырдап
Сөйләшкән булыр идек,
Серләшкән булыр идек...
(«Тирәкләргә җил кирәк!»).

Балалар поэзиясенең тагын бер үзенчәлекле тавышны сурәтләү алымы – сүзләрне иҗекләргә бүлү, сүзләр белән уйнау. Р. Миңнуллин иҗатында да мондый алым, кушымчаларга бүлү поэтик сурәтнең берәмлеге булып, шигырьгә үзгә бер аһәң бирә, игътибарны тарта:

Иң яхшысы –
Күренмәү
Кро! ко!! дил!!!ның
Күзенә
(«Кро! ко!! дил!!!»).

яки,

Сыйланып
Туйгачтын,
Туйганын
Тойгачтын,
Җырлаган
Быт-был-дык: –
Тук бул-дык!
Тук бул-дык!
(«Бытбылдык»).

Текст эчендәге иҗекләргә бүленеш төрлечә бирелә. Беренче шигырьдә сүз белән уйнау бар. Икенчесендә исә, шигырьдә пауза һәм сызыкча белән иҗекне билгеләү һәм кабатлаулар лирик «мин» күзаллаган картинаны ассызыклый, иҗек ономатоплары – Быт-был-дык, Тук бул-дык – үзара бәйләнә, нәтиҗәдә Бытбылдык образы күзаллана. «Арбада барганда» шигырендә дә иҗекләргә бүлү сикәлтәле юлны күзалларга ярдәм итә:

Нин-$_{\text{ди}}$ юл $_{\text{бул}}$-ды $_{\text{соң}}$ бу?...
$^{\text{Сел}}$ке-$^{\text{тә}}$ дә сел-$_{\text{ке}}$-тә,
С$^{\text{и}}$ -кер-$^{\text{тә}}$ дә $^{\text{си-}}$кер-$^{\text{тә}}$
$^{\text{һоп}}$-һоп...
(«Арбада барганда»).

Гомумән, балалар шигърияте дөньясы ул – җанлы һәм җансыз табигать, төрле тавышлар дөньясы. Мондый лексек берәмлекләрдән, аларның үзгәрешеннән, кабатлануыннан, җанландырылуыннан тыш бу өлкәне күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

Р. Миңнуллин иҗатында иркен кулланылган тагын бер жанр – тел көрмәкләндергечләр.

Тел көрмәкләндергечләр жанры татар фольклорында да, башка күп халыклардагы кебек үк, билгеле бер функцияне башкара – сөйләүченең телен «бутый», гадәти сөйләмне үзгәртә, аны мәгънәви конструкциясенә каршы куя. Баланың артикуляциясен шомарта, чарлый, нәтиҗәдә туган телне дөрес үзләштерү мөмкинлеге туа. Мисал итеп, М. Шабаевның «Мич башында биш мәче», Р. Әхмәтҗанның «Көя күбәләге», Х. Халиковның «Төзәйткеч», «Каламы соң», «Остазның да остазы бар» шигырьләрен китерергә мөмкин. Мондый төр шигырьләр Р. Миңнуллин иҗатында да байтак. «Әкәмәт җанварлар», «Шираматан», «Арбада барганда», «Дер-дер куян», «Серле кара маҗаралары» һәм башкалар. «Армас-талмас Барлас» шигырендә тел күнекмәсе бер үк иҗекләрнең бер-бер артлы янәшә сүзләрдә кабатлануына корылган:

Бер дә ар<u>мас</u>-тал<u>мас</u>
Бар<u>лас</u>,
Еламыйча кал<u>мас</u>
Бар<u>лас</u>,
Сер дә биреп тор<u>мас</u>

Бар<u>лас</u>,
Елаганнан гына
Ар<u>мас</u>!

«Ш» авазын уйнату, мисал өчен, «Колын» шигырендә чагылыш таба, һәрбер юл, нигездә, тәмамланган, бербөтен:

Кечкенә, тик атландырмый:
Те<u>ш</u>ли,
ке<u>ш</u>ни,
тибе<u>ш</u>ә!
Аңа әле те<u>ш</u>лә<u>ш</u>сә дә,
Тибе<u>ш</u>сә дә киле<u>ш</u>ә!

Биредә «ш» авазының еш кабатлануы үзенә бертөрле яңгыраш тудыра, ритмның хәрәкәтчәнлеген һәм үзгәрүчәнлеген ассызыклый. Ритм һәм интонациянең үзгәрүе исә шигырьне җанландыра, ә бу бертөрлелекне һәм төссезлекне яратмаган балаларның игътибарын үзенә тарта. Гомумән, тизәйткечләр авазларны дөрес, ачык итеп әйтүне генә күздә тотмый, бәлки, мисаллардан күренгәнчә, телнең яңгырашына баланың игътибарын җәлеп итә, сүз ритмын ишетергә, туган телнең эстетик нигезен үзләштерергә мөмкинлекләр ача.

Р. Миңнуллин, еш кына, бала өчен әйтелеше авыр булган «р», «к», «ч», «п», «ш» кебек авазларга игътибар итә.

Карак, карак!
Кара, карак!
Кара карак
Караpак.
Кар ак,
Кара кар ак.
(«Палиндром»).

«К»лар тулган бакчага» шигыре дә балалар өчен кызык, чөнки ул уенчыл характерда һәм файдалы. Ул «к» авазына игътибарны юнәлтү белән бергә, бакчада үскән яшелчәләр белән дә таныштыра:

Бу бакчага ни булган?
Бакча «К» белән тулган.
Карлыган һәм кәбестә,
Кишер, карбыз һәм кабак.
Крыжовник һәм кукуруз,
Кыяр, кавын, кузгалак.

Күренә ки, Р. Миңнуллин балалар фольклоры жанрлары моделе нигезендә үзенчәлекле шигырьләр иҗат итә. Мотивы, төзелеше, эчтәлеге ягыннан исә аңа белем һәм тәрбия шигърияте якын. «Балалар язучысы... яхшы тәрбияче яисә укытучы буларак, нинди генә тыңлаусыз булмасын, сабыйны начар гадәтләреннән арындыра алуына ихлас ышана», – дип яза рус балалар әдәбияты белгече И. Мотяшов [Миңнуллин, б. 192].

Әлеге фикерне турыдан-туры Р. Миңнуллин шигырьләренә карата да кулланырга мөмкин.

Р. Миңнуллинның фольклорга нигезләнеп язылган лирик әсәрләренең тагын бер үзенчәлеге – шигырьләрнең сюжетка корылуы һәм, инде әйтеп үтелгәнчә, сүзләрнең кабатланып килүе. Әлеге сыйфатлар, шигырьнең ритмик яктан камиллеген һәм музыкальлеген тәэмин итү белән бергә, күз алдында картина тууга да сәбәпче була:

Бигрәк
Сөзгәк
Үгезегез!
Үгезегез –
Төп-төз
Мөгез!
Куркасызмы

Ул үгездән
Сез үзегез?
(«Үгез»);

яки,

Черкине
Чабак
Тоткан,
Чабакны
Чуртан
Йоткан.
Чиләккә
Чумган
Чуртан –
Тотар
Идем дә...
Куркам!
(«Черки, чабак, чуртан һәм чиләк»).

Алдарак билгеләп үтелгәнчә, бала сөйләшергә өйрәнгәндә бер үк яңгырашлы сүзләр аша телен чарлый. Бала сөйләме формалашуында бу этапның әһәмиятен аңлаган шагыйрь, әлеге үзенчәлекне бик иркен рәвештә иҗатында файдалана. «Сөзгәк капка» – фикерне дәлилләү өчен мисал була ала. *Мөгез – үгез, поши – ошый, элеп куйды – көлеп куйды, кабарынды – агарынды* һ.б. сүзләр бер үк яңгырашлы булу белән бергә, рифмалар шаян, көлкеле шигъри образ да тудыралар:

Күркәләр
Кабарынды,
Сарыклар
Агарынды.
Капкага үскән
Мөгез.
Капкабыз хәзер –
Үгез.
Үгез түгел лә –
Поши.
Бу поши миңа
Ошый.

Тел көрмәкләндергечләр жанрына якын торган «Сигез песи», «Өркетмәгез!», «Черки, чабак, чуртан һәм чиләк», «Көнгерә», «Ташбака», «Тилгән» кебек шигырьләрендә дә балалар фольклорына хас үзенчәлекләрне куллану шигырьгә үзгә бер аһәң өсти:

Яшиләр, ди,
Сигез песи,
Сигезе дә –
Симез песи,
Сигезе дә –
Игез песи,
Буйлары да
Тигез песи,
Сигез песи...
(«Сигез песи»).

Күренә ки, халыкның педагогик ихтыяҗлары нигезендә туган тизәйткечләр традициясе Р. Миңнуллин иҗатында да дәвам иттерелә. Ул аның формасы белән бергә мәгънәсен дә саклый һәм күпсүзлелектән котылу өчен, еш кына, телнең эчке мөмкинлекләренә мөрәҗәгать итә.

Шагыйрьнең балаларның сөйләм телен баету, камилләштерү өчен сүз уйнатуга корылган шигырьләре, шулай ук, игътибарга лаек: «Яздык», «Хәрефләр буталганда», «Кысла», «Черкиләр җыры», «Портта булган хәл», «Мөгезборын белән озынборын», «Мичкә ягылган мичкә», «Аяк тая тайгакта» һ.б.:

Тая
Аяк,
Кая
Таяк?
Таяк кулда,
Көчсез
Ул да!
Бозы

Шома,
Тая
Шуңа,
Шуа
Шуңа.
Аяк,
Шума! ...
Йөрим
Шуңа
Дүрт
Аякта
ТАЙГАКТА!

Мәгълүм, балалар шигърияттендә тәэсирлелек һәм экспрессивлык аллитерация ярдәмендә тормышка ашырыла. Аллитерацияләнгән аваз – сурәтләү авазы да була ала. Мисалга, Р. Миңнуллинның «Антилопа» шигырендә антилопаның күп тапкырлар, рифмалаштырылган төрле вариантларда кабатлануы (андыйлопа, алмыйлопа, таптыйлопа, атлыйлопа, сантыйлопа, ятмыйлопа) аллитерацияләүче «а» һәм «лопа» аваз-сүзләрдә авыр һәм тиз әйтелешле (тизәйткеч) формада антилопа образын күз алдына бастыра, балаларның образлы фикерләвен, фантазиясен үстерергә ярдәм итә:

Чаба гына
Антилопа...
Африкада –
Андыйлопа.
Үзен тыя
Алмыйлопа,
Болыннарны
Таптыйлопа
(«Антилопа»).

Балалар фольклорында сөйләм авазларының «яшерен теле» дип аталган бер төре бар. Бу хикмәтле юнәлеш турында үз вакытында Г. Виноградов язып калдырган. 1926 елда дөнья күргән хезмәт «Детские тайные языки» дип атала [Виноградов, с. 87]. Биредә Г. Виноградов яшерен телләрнең барлыкка килү сәбәпләрен аңлатып үтү белән генә чикләнеп калмый, аларга кыскача тасвирлама һәм классификация дә бирә. Аның фикеренчә, балаларның яшерен теле «олыларның гомумкулланылышта булган сүзләреннән барлыкка килә һәм алар үзләренә ясалма иҗекләр өстиләр». Р. Миңнуллинның әлеге «Антилопа» шигыре дә нәкъ менә шул «яшерен тел» чараларын күз алдына бастыра һәм алар балалар фантазиясе ярдәмендә тудырылган яңа сүзләр булып хәтердә кала. Яки:

Авылыбызда өй саен,
Менә шундый зоопарк.
Зоопарктан ким түгел
Безнең дә абзарпарк.
(«Безнең авыл зоопаркы»).

Балалар шигъриятенә фонетик-лексик үзгәрүләр хас. Аларның иң танылганы – паронимнар. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, тел көрмәкләндергечләр өчен дә шагыйрь нәкъ менә аларны нигез иткән. Тагын бер мисал:

Көрәк –
Терәк!
Көрәк
Кирәк!
Көрәк
Бигрәк
Безгә
Кирәк!
(«Көрәк») һ.б.

Мондый, поэтик сөйләмне фразаларга яки өлешләргә,

сүзләргә бүлү поэзиядә гадәти күренеш һәм ул парцелляция дип атала. Сүзләрнең аерым бер шигъри юл булып килүе зурлар әдәбиятында интонацияне, сәнгатьлелекне ассызыклауга хезмәт итсә, Р. Миңнуллинда, һәр сүзне яки мәгънәви кисәкне аерып әйтү шигырьнең репрезентатив көчен күрсәтә, сәнгатьлелектән тыш, һәр аерым бирелгән юл-сүз сурәтне, сыйфатны, эчтәлекне тирәнрәк ачуга ярдәм итә. Нәтиҗәдә, һәрбер лексик берәмлек – образ, чөнки еш кына бер юл – бер сүз, бер мәгънәле кисәк формасында тәкъдим ителә. Мондый «аерып күрсәтелгән сүзләр поэзиясе»нең (Р. Якобсон) нигезе исә фольклор жанрларына барып тоташа. В. Маяковскийның шигъри телен анализлаган Г. Винокур мондый күзаллауны һәм, еш кына, кинематографик образ тудыручы сүзләрне «изоляцияләнгән исемнәр» дип атый [Винокур, с. 78].

Р. Миңнуллин «Подъезддагы язулар» шигырендә фольклорның «күңел ачу» төренә караган үртәвечләр жанрын куллана:

Безнең йортның подъездына
Ни генә язылмаган,
Ничек кенә бозылмаган,
Ни генә сызылмаган
...Сүзләре нинди бит әле:
«Штирлиц»,
«Тарзан»,
«Фантомас».
«Булдылар монда кичә
Гөлнур + Халисә».
«Гөлназ + Мөхәммәт =
мәхәббәт».
И, Нургали, Нургали,
Башын, күзен боргалый.
... Аларның бабалары да,
Кереп дошман күзенә,
Исемнәрен язып кайткан
Рейхстагның үзенә!

Алымның максаты – балаларның кылган гамәленә сатира ярдәмендә җәза бирү. Бу максаттан автор, бик оста рәвештә, балалар фольклорыннан үртәвечләргә, халыкчан, гадәти тормышта бала тарафыннан яратып кулланылган сүзләргә мөрәҗәгать итеп, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга чакыра. Лирик әсәрдә үртәвечләрнең кулланылуы – жанрның бүгенге көндә дә яшәп килүенә дәлил булып тора. «Шунысы мөһим, бу, беренче карашка юмористик шигырьне көлке тудыру өчен язылган дип бәяләү дөрес булмас, чөнки әсәрнең нигезендә тирән мәгънә ята. Соңгы строфада бабаларыбызның сугышта ил өчен көрәшүләре, Рейхстагта, җиңүче буларак, үз исемнәрен язулары һәм балаларның «батырлыгы» – йорт подъездын пычратып, төрле сүзләр язулары капма-каршы куела, нәтиҗәдә, ачы көлү, борчылу хисләре шигырьнең үзәген тәшкил итә» [Мингазова, с. 95].

Шулай итеп, образ тудыру һәм фикер җиткерү өчен шагыйрь тарафыннан балалар фольклорындагы төрле шигъри бизәкләр, алымнар файдаланыла. Автор реальлекне саклаган хәлдә, уен-шартлылык ярдәмендә җанлы сурәт формалаштыруга ирешә, шартлылык-фантазия чынбарлык белән үрелә. Халык авыз иҗатының мондый кызыклы, тапкыр, уенчыл сыйфатларын файдалану исә шагыйрь иҗатын югары баскычка күтәрә.

Әдәби иҗат үрнәкләрен һәм фольклор текстларын чагыштырып карау, бәяләү шагыйрьнең халыктан килгән образлар һәм сюжетларны ни дәрәҗәдә үзенчә сүрәтләвен күрергә мөмкинлек бирә. Фольклор текстларында билгеле бер рухны чагылдыру алгы планга чыга, авторның балалар өчен язылган лирик әсәрләрендә дә бар нәрсә дә аңлаешлы, ачык, бала кабул итә алырлык. Фольклор образларын шәхси иҗатта куллану Р. Миңнуллинга конкретлык, предметны тулы сурәтләп бирү мөмкинлеген ача, фикер тыңлаучыга төгәл җиткерелә.

Халык иҗатыннан сакланып калган образ, мотив һәм текстларны ул заман таләпләренә туры китереп, нәниләргә яраклаштырып эшкәртә. Заманча фикер йөртү, аерым вакыйгаларны яңа күзлектән чыгып бәяли белү исә халыкчанлык белән аваздашлыкка китерә.

Р. Миңнуллинның милли фольклорга игътибарының тагын бер төп сәбәбе – аның озын гомерле булуы, гадилеге, эстетик яктан югары баскычта торуы белән аңлатыла. Нәкъ менә шуңа күрә андагы поэтик детальне, образлар системасын, балалар психологиясен һәм яшь үзенчәлекләрен өйрәнүгә булган омтылыш һичкайчан үзенең актуальлеген югалтмый. Автор халык авыз иҗатына һәм классик әдәбиятка таянып, уңай традицияләрне өйрәнеп, үз иҗат үсеше өчен ышанычлы җирлек булдыра.

Шулай итеп, Р. Миңнуллинның иҗаты үзенең тамырлары белән фольклорның поэтик традицияләренә барып тоташа. Шигырьләрендә ул халык авыз иҗатының күпсанлы жанрларын оста кулланып, татар балалар әдәбиятына яңа сулыш өрә. Фольклорның уңышлы тәэсире нәтиҗәсендә аның иҗатында төрле жанрлар формалаша, алар яңа форма, эчтәлек белән баый, балаларны киңкырлы итеп тәрбияләү өчен кирәкле үзенчәлекләргә ия була.

Р. Миңнуллин шигырьләрендәге әдәби система балалар фольклоры нигезен, балалар психологиясен һәм балалар шигыренең кануннарын белү җирлегендә формалаша. Халыкның рухи байлыгын лирик әсәрләрендә иркен файдаланып, шигырьләрен ритмлы, төгәл сүрәтләү чараларына көйләп, ул укучыларын милләтнең кадерле кыйммәтләренә, халыкның рухи байлыгына якынайта. Мәгълүм ли, аерым тикшеренүләр күрсәткәнчә, балалар поэзиясе үзе үк балалар фольклорыннан, борынгы мифлардан, ышану, гореф-гадәтләрдән үсеп чыккан өлкә.

**Әдәбият**

Балалар фольклоры / төз. Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 488 б.

*Виноградов Г.С.* Детские тайные языки // Сибирская живая старина. 1926. Вып. 6. С. 87–112.

*Винокур Г.О.* Маяковский – новатор стиха. М.: КомКнига, 2009. 152 с.

*Жинкин Н.И.* Механизм регулирования сегментарных и просодических композиций языка и речи // Poetics. Poetyka. Поэтика. Warshawa, 1961.

*Кукушкин Р.* Шигъри бишек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 112 б.

*Лотман Ю.М.* Анализ поэтического текста. Структура стиха: пособие для студентов. Л.: Просвещение, 1972. 272 с.

*Мингазова Л.* Предпосылки возникновения и роль фольклора в формировании и развитии татарской детской письменной литературы // Вестник Челябинского государственного педагогического университета. 2011. № 2. С. 95–102.

*Миңнуллин Р.М.* Әсәрләр: җиде томда. Т. 4: Балалар өчен кечкенә әкиятләр, irекле тәрҗемәләр, төрле язмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 528 б.

*Путилова Е.О.* Поэзия 1920–1930-х годов детям. М., СПб., 1997. Т. 2. 248 с.

*Твардовский А.Т.* О поэзии Маршака. Собр. соч.: в 8 т. / под редакцией В.М. Жирмунского, И.С. Маршака и др. М.: Худ. литература, 1970. Т. 5. 703 с.

***Минһаҗева Ләйлә Ихсан кызы,***

*филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты татар әдәбияты кафедрасы профессоры*

УДК 821.51

***А.Ә. Хасавнех***

# РИЗАЭДДИН ФӘХРЕТДИНОВНЫҢ «МӘШҺҮР ХАТЫННАР» ИСЕМЛЕ БИОБИБЛИОГРАФИК ХЕЗМӘТЕ

В статье дается обзорный анализ объемному биобиблиографическому сочинению Р. Фахретдинова «Знаменитые женщины» («Мәшһүр хатыннар», 1903), включившему в себя биографии более 700 самых известных в мусульманском мире женщин. Больший интерес для нас представляют татарки, прославившие себя в разных сферах общественно-политической жизни: государственном правлении, образовании, науке, религии, меценатстве и др. Изучение проблемы женской эмансипации на территории Волго-Уральского региона находится еще в зачаточном состоянии. И, к сожалению, даже в существующих единичных публикациях и исследованиях на эту тему присутствуют наслоения стереотипного подхода, когда топорными методами пытались отделить «светлое» от «темного», «передовое» от «отсталого». В данном исследовании впервые предпринята попытка адекватного освещения данной проблематики.

**Ключевые слова:** Р. Фахретдинов, библиографическое сочинение, эмансипация женщин, жизнеописания известных женщин, мусульманский мир.

XIX гасырның икенче яртысында мөселман зыялылары ислам җәмгыятенең дөньядан артта калуы, торгынлык күренешләре кебек проблемаларны күтәрә башлыйлар, кризистан чыгу юллары хакында актив сөйләшүләр алып баралар. XIX йөздә мөселманнарның Европа цивилизациясе, Көнбатыш кыйммәтләре белән якыннанрак һәм киңрәк танышa алулары аларга мөселман дөньясын Европаның алдынгы казанышлары белән чагыштырып карау мөмкинлеген ача. Бу чорда тел дә үзгәрешсез кала алмый, ирексездән Европа институтлары символлары, образлары, практикасы үзләштерелә. Мәгариф системасында реформа, аны Көнбатыш моделендә кору, журналистика, матбугат, сәнгать, театр, шулар белән бергә хатын-кыз эмансипациясе мәсьәләләренең кискен төс алуы һ.б. күзәтелә.

Идел–Урал регионы да мөселман дөньясыннан читтә яши алмый әлбәттә. Биредә дә ислам Якын Көнчыгыш, Төркия һәм Урта Азиянең тыгыз йогынтысы белән үсә, шуңа күрә реформаторлык процесслары татарларга да турыдан-туры кагыла. Татарларның күпчелеге кризистан чыгу, иң беренче чиратта, мәгарифне Европа моделендә үзгәртеп кору, мөселманнарның кайбер хокукый нигезләрен яңадан карау аша тормышка ашырылырга тиеш дип ышаналар; сәяси һәм социаль проблемалар турында җанлы сөйләшүләр алып барыла. Мөселман-реформачылар алып барган бәхәсләр кысасында яңа җәмгыятьтә хатын-кызның урыны һәм

роле, аларга ирек һәм хокукны киңрәк бирү зарурияте иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсенә әверелә.

Идел–Урал регионы әлеге үзгәрешләр процессына билгеле бер дәрәҗәдә әзерлекле була дип ышанып әйтергә мөмкин. XVIII–XIX гасырларда татар хатын-кызлары арасындагы грамоталылык дәрәҗәсе үзе генә дә зур тәэсир көченә ия була. Ишан, мулла, мөдәррисләрнең хатыннары, кызлары, апа-сеңелләре укымышлы хатын-кызлар булалар. Алар белемне, нигездә, гаиләдә үз аталарыннан һәм агаларыннан алганнар. Бу хатын-кызлар – Көнчыгыш телләрен, каллиграфиясен мөкәммәл белүчеләр. Аларның Татарстан китапханәләрендә һәм кульязма фондларында сакланган күпсанлы хатлары шуны дәлилли.

Мөгаллим, әдип, матбагачы, тарихчы, мәгърифәтче, дин белгече, «...искиткеч зур талант һәм хезмәт сөючән, киң эрудицияле, энциклопедик белемгә ия кеше» [Фахретдинов, 1903, с. 451] Р. Фәхретдинов (1859–1936) – татар галимнәре арасында беренчеләрдән булып хатын-кызлар хокукын мәгърифәтче позициясеннән торып яклауга басучы. Шул ук вакытта ул бу юлның җиңел булмаячагын да яхшы аңлаган, чөнки җәмгыятьнең хатын-кыз мәсьәләсенә һәм, тулаем алганда, хатын-кызга мөнәсәбәтен үзгәртергә омтылуының традицион татар яшәешендәге тирән тамырлы стереотиплар каршылыгына очраячагын алдан ук күргән.

Бу җәһәттән Р. Фәхретдиновның «Мәшһүр хатыннар» дигән биографик хезмәте – гарәп язулы, иске татар телле уникаль, тиңдәше булмаган документ.

Әлеге күләмле хезмәт шушы көнгә кадәр махсус өйрәнелмәгән, бары тик хатын-кыз мәсьәләсенә яисә Идел–Урал регионында хатын-кыз эмансипациясенә багышланган кайбер мәкаләләр, монографияләр [Воробьева, 2005 – Өмет йолдызлары: XIX йөз..., 1998] генә бу сорауга кыскача кагылып уза. Гендерлык мәсьәләләрен күтәргән тикшеренүләр юнәлешендә беренче кыюсыз адымнар безнең ватандашлар тарафыннан ясала [Суковатая, 2002; Шайдуллина, 1978]. Боларда хатын-кыз феминизмы мифология һәм дин өйрәнү сферасында карала.

Татар мифологиясе һәм фольклоры өлкәсендә специальләшкән Ф.И. Урманчеев публикацияләрен аерым әйтеп узарга кирәк, галим уздырган тикшеренүләрдә хатын-кыз мәсьәләсенә ныклы игътибар бирелә.

А.А. Кәримова Идел–Урал регионының иң алдынгы фикер ияләреннән берсе Гаяз Исхакыйның (1878–1954) әдәби әсәрләрен төп өйрәнү объекты итеп алган монографиясендә [Каримова, 2003] хатын-кызларның кимсетелгән хәле проблемасын бөтен тулылыгы белән күтәрә.

Хатын-кыз эмансипациясе, гаиләдә һәм җәмгыятьтә хатын-кызның урыны һәм роле кебек мәсьәләләрне күтәрү Идел–Урал территориясендә әле тиешле югарылыкта булмый. Кызганычка, бу темага басылып чыккан аз санлы мәкаләләр дә мәсьәләгә стереотип якын килүдән уза

алмый, аларда совет чорына хас «якты» тамгасы салынганны «караңгылык»тан, «алдынгы» тамгалыны «артталык»тан аеру методы өстенлек алган. Совет шаблоннарын кулланып, авторлар үз хезмәтләрендә «прогрессив фикерләүче»ләрне (җәдидчеләрне) «караңгы», «артта калганнар»га (кадимчеләргә) каршы кую тенденциясен алга сөрделәр. Чынлыкта исә кадимчеләр арасында да бик тирән белемле, укымышлы, прогрессив фикерләүче, алдынгы карашлы эшлеклеләр җитәрлек булып, алар татар мәдәниятен һәм фәнен үстерүгә күп өлеш керттеләр.

Кадимчеләрне кызлар өчен гимназия (мәдрәсә) ачуга каршы булганннар дип әйтү дә зур ялгыш булыр иде. Киресенчә, аларның үз хатыннарына, апасеңелләренә, кызларына яхшы белем бирергә тырышулары безгә мәгълүм. Шул ук вакытта алар татар җәмгыятенең иҗтимагыйсоциаль тормышында булган төрле сферадагы, шул исәптән мәгарифтәге реформаларны, үзгәртеп коруларны яклап чыгалар. XIX йөзнең икенче яртысында җәдидчеләр белән кадимчеләр арасында мөселман җәмгыяте мәсьәләләре көн кадагына куела башлый. Артталык, кризис һ.б. хакында җитди бәхәсләр барганда һәр ике як килеп туган вазгыятьтән чыгу юлын үзенчә күрә. Җәдидчеләр һәм кадимчеләр темасы әле тулысынча өйрәнелмәгән. Ислам дөньясында хатынкызның роле һәм урыны темасын тикшеренүгә алынган белгеч өчен иң әүвәл әлеге искергән стереотиплардан арыну мөһим.

Ислам дөньясында хатын-кыз проблематикасына Көнбатыш галимнәре аеруча зур әһәмият биргән. Хатын-кыз мәсьәләсен бөтендөнья масштабында өйрәнгән В. Брайсон һәм А.В. Швейгер-Лерхенфельд [Брайсон, 2001] тарафыннан, мәсәлән, бик җитди тикшеренүләр уздырылган. Монда Көнбатыш авторларының [Abu-Lughod, Lila, 1998 – Roded, 1994] хезмәтләрен аерым ассызыклау кирәк. Бу тикшеренүләрдә авторлар ислам дөньясында хатын-кызның роле мәсьәләсен тәфсилләп өйрәнәләр, хатын-кыз эмансипациясе темасының барлык аспектларын күзаллап фикер йөртәләр. Көнбатыш галимнәре хезмәтләре арасында нәкъ менә ислам биографик коллекциясен өйрәнүгә багышланган монографияләр дә бар, әйтик, Рус Родед хезмәте [Roded, 1994] шушы төркемгә карый.

Р. Фәхретдиновның «Мәшһүр хатыннар» хезмәте 1903 елда Оренбург шәһәрендә Кәримовлар типографиясендә басылып чыга. Күләме 448 биттән гыйбарәт әлеге китап үз эченә түбәндәге бүлекләрне ала: автор тарафыннан язылган «Ихтар» (Кереш сүз), гарәп әлифбасы тәртибендә төзелгән, ислам дөньясында мәшһүр хатын-кызлар турында биографик мәгълүмат бирә торган төп өлеш, «Хәтем» (Йомгак) һәм «Фихрист» (Исем күрсәткече). 34 нче биттә китапның электкеге иясе, указлы мулланың «С.Ш. Невметуллин» дип язылган түгәрәк мөһере сугылган. Хезмәттә Идел һәм Урал буе территориясендә генә түгел, Себер, Урта Азия, Ерак һәм Якын

Көнчыгыш илләре, мөселман Испаниясен дә кертеп, дөньяның төрле почмакларында яшәгән һәм иҗат иткән 700 дән артык данлыклы хатын-кыз турында телгә алынган. Вакыт аралыгы турында сүз алып барсак, Р. Фәхретдиновның «Мәшһүр хатыннар» китабына кешелекнең анабыз Хәүвадан (библ. – Ева) алып, автор замандашларына кадәрге чордагы гүзәл затлары кертелгән. Шулай итеп, хезмәтнең хронологиясе, бик борынгы чорлардан алып, XX гасыр башына кадәрге вакытны колачлый.

«Мәшһүр хатыннар»ны шартлы рәвештә берничә тематик блокка аерырга мөмкин булыр иде. Әйтик, «Борынгы дәүләтләрдә идарәче хатын-кызлар», «Гассанид, Сасанид Омейяд, Айюбид һ.б. кебек төрле династия падишаһларының аналары, кызлары, хатыннары», «Мөхәммәд с.г.в. тирәсендәге хатын-кызлар, аның фикердәшсәхабәләре», «Пәйгамбәребезнең анасы һәм хатыннары», «Мөхәддисәләр (хәдис тапшыручы хатын-кызлар)», «Шәех ролен башкарган хатын-кызлар һәм исламда изге хатыннар (әүлияләр)», «Фәкихәләр (мөселман хокук белгечләре)», «Көнчыгышның православ идарәче хатын-кызлары», «Идел–Урал төбәгендә меценат хатын-кызлар», «Ислам дөньясы язучы һәм шагыйрәләре», «Вәгыйзәләр (вәгазь укучылар) һәм хатыйбәләр (сүз остасы-хатыннар)», «Мөдәррисәләр (кызлар гимназияләрендә кызларга дәрес бирүчеләр)», «Табибәләр», «Язу һөнәрендә маһирәләр (каллиграфлар)».

Җыентыкта шулай ук Болгар, Сарай, Казан мөслимәләре; баһадир хатыннар, хаҗ кылучылар («хаҗ идүчеләр»), күп балалы аналар һ.б. хатын-кызлар тормышын яктыртуга да әһәмият бирелгән. Шунысы игътибарга лаек: Р. Фәхретдинов хезмәтендә иң күп урынны пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. якыннарыннан булган хатын-кызларның тәрҗемәи хәлләрен яктырту алып тора. Бу очраклы түгел, чөнки, мәгълүм булганча, элекке чор ислам җәмгыятендә яшәгән хатын-кызлар күренекле иҗтимагый дәрәҗә тотканнар, ирләр арасында да зур абруйлы булганнар. Мисал итеп Мөхәммәд с.г.в. хатыннарыннан мәшһүр сәүдәгәр һәм иренең таянычы Хәдичәне, хәдисләр белгече буларак танылу алган һәм төрле сәяси төркемнәр көрәшендә роле зур Гайшәне телгә алып узу да җитәр. Аларның тормышын тасвирлау бөтен ислам дөньясында миллионлаган хатын-кызны илһамландырган. Нәкъ менә шундый тасвирлар үрнәгендә «Мәшһүр хатыннар» авторы Р. Фәхретдинов татар җәмгыятен реформаларга этәрүгә, хатын-кызларга ирләр белән тигез хокук бирүгә һәм тулы белемле итүгә омтылган.

Болардан тыш, китапка Клеопатра, Шәмсунның (библ. – Самсон) сөеклесе Дәлилә, Ибраһим пәйгамбәрнең (библ. – Авраам) хатыны Сара, Мәрьям (библ. – Мария), Әминә (Мөхәммәд с.г.в.-нең анасы), Рабига әл-Гадавийа, Сөембикә (Казан ханлыгы идарәчесе) һ.б. исемнәр һәркемгә мәгълүм шәхесләр һәм, алар белән бергә, бик үк билгеле

булмаган хатын-кызларның да исемнәре кертелгән. Шулай итеп, Р. Фәхретдиновның әлеге хезмәте билгеле шәхесләр турында моңа кадәр белгәннәрне өр-яңа мәгълүматлар белән баетса, бик үк билгеле булмаган исемнәрне бирүе белән исә өр-яңа исемнәр белән танышырга мөмкинлек тудыра. Әйтик, язмада аз билгеле һәм бөтенләй билгесез хатын-кызларның күпчелеге Идел буе һәм Урал территориясендә яшәгән, алар хәйриячелек белән шөгыльләнгән, мәчет, мәктәпләр төзеткән, китапханәләргә нигез салган һ.б.

Р. Фәхретдиновның «Мәшһүр хатыннар» китабы белән әлегә бик аз затлар гына таныш. Әмма бу хезмәтнең басылып чыгуы үз вакытында татар дөньясында гына түгел, бөтен төрки дөнья зыялылары арасында шаушу тудырган, чын борылыш буларак кабул ителгән. Алга таба хатын-кыз эмансипациясе мәсьәләсенә бик күп мәгърифәтчеләр, язучылар мөрәҗәгать иткән. 1913 елдан Казанда татар телендә хатын-кызларның беренче журналы «Сөембикә» чыга башлый. 1905–1907 елгы инкыйлабтан соң татар хатын-кызлары вакытлы матбугат, иҗтимагый-дәүләт эшләренә актив тартылалар, Казанда берничә мәртәбә хатын-кызлар корылтае уза һ.б.

Үзенең хезмәтен төзегәндә Р. Фәхретдинов түбәндәге чыганакларга мөрәҗәгать иткән: Әбү әл-Фәраҗ Габдерахман әл-Җәүзинең «Әхкәмен нисаэ»; Касыйм Әмин әл-Мисриның «Тәхрирел маръат»; Ибне әл-Җәүзинең «Гаҗәибен нисаэ»; Мохибулла Әхмәд бине Габдулла әт-Тәбариның «Мәнакыйб өммел мөэминин Гайшә» һ.б. (барлыгы 43 фәнни хезмәт). Автор шулай ук Көнбатыш галимнәренең гарәп теленә тәрҗемәдәге хезмәтләрен дә файдаланган, А. Шопенгауэрның «Кәлимә эннисаэ» һәм Аристотельның «Әл-Мәръа»сы шундыйлардан.

Р. Фәхретдиновның тарих, география, Көнчыгыш һәм төрки дөнья әдәбиятлары, тәрҗемәләр, табигый фәннәр, фәлсәфә, тел белемен дә кертеп, төрле чыганакларның һәм хезмәтләрнең киң спектрын кулланган булуы «Мәшһүр хатыннар» китабының энциклопедик характердагы гаять җитди һәм күпкырлы хезмәт икәнен күрсәтә.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, түбәндәгечә нәтиҗә ясарга мөмкин: Р. Фәхретдиновның кешелекнең гүзәл яртысын тәшкил итүчеләр – хатын-кызларга багышланган бу хезмәте мәшһүр мөслимәләрнең тәрҗемәи хәлләре хакында белемнәрне шактый кызыклы детальләр белән баета, шулай ук бик күп яңа исемнәр ача, тарихның күтәрелми калган катламнарыннан яңа сәхифәләрне торгыза.

**Әдәбият**

*Брайсон В.* Политическая теория феминизма / пер. с англ. О. Липовской и Т. Липовской. М.: Идея-Пресс, 2001.

*Воробьева М.В.* Гендерный подход в религиоведении: попытка междисциплинарного дискурса // Научно-теоретический журнал «Религиоведение». 2005. № 3. С. 119–123.

Женщина и ислам: сб. ст. / под ред. А.К. Бустанова. М.: Дизарт Тим, 2017. 72 с.

*Каримова А.А.* Идейно-эстетическая эволюция проблемы феминизма в творчестве Гаяза Исхаки (1897–1954) (на татарском языке). Казань: Изд-во Татарского гуманитарного ин-та, 2003.

*Махмутова А.Х.* «Риза кази писал про женщин знаменитых…» // Источники и исследования по истории татарского народа: материалы к учебным курсам в честь юбилея академика АН РТ М.А. Усманова. Казань, 2006. С. 449–458.

Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / төз.-авт. А.Х. Мәхмүтова. Казан: Җыен, 2012. 560 б. («Шәхесләребез» сериясеннән).

*Муслихова Ч.Х.* Движение за эмансипацию женщин в татарском обществе (конец XIX – начало XX века) // Вестник Челябинского государственного университета. 2011. № 34 (249). История. Вып. 48. С. 35–39.

Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре / төзүчесе, кереш сүз һәм искәрмәләр авторы М. Гайнуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998.

*Сахих аль-Бухари* [Свод хадисов имама ал-Бухари]. Ч. 5, стр. 2227, № 5626.

*Суковатая В.А.* Женщина в религиозной истории и феминистской теологии / Женщина в истории: возможность быть увиденными: сборник научных статей. Вып. 2. Минск, 2002.

*Урманчеев Ф.И.* Борынгы шәрекътә хатын-кызларга табыну (мифология мәгълүматлары буенча) // Инсани фәннәр: эзләнү һәм табышлар. Казан: Фикер, 2004. Б. 3–8.

*Фахретдинов Р.* Мәшһүр хатыннар. Оренбург: Кәримов матбагасы, 1903.

*Шайдуллина Л.И.* Арабская женщина и современность (Эволюция ислама и женский вопрос). М.: Наука. Главная ред. вост. лит-ры, 1978.

*Швейгер-Лерхенфельд А.Ф.* Женщина, ее жизнь, нравы и общественное положение у всех народов земного шара / пер. с нем. М.И. Мерцаловой. М.: Кураре-Н, 1998.

*Abu-Lughod, Lila,* ed. Remaking Women: Feminism and Modernity in the Middle East. Princeton: Princeton University Press, 1998.

*Bayes, Jane,* and *Nayereh Tohidi,* eds. Globalization, Gender, and Religion: The Politics of Women’s Rights in Catholic and Muslim Contexts. New York: Palgrave, 2001.

*Cooke, Miriam.* Women Claim Islam: Creating Islamic Feminism through Literature. London: Routledge, 2001.

*Haddad, Yvonne Yazbeck,* and *John L. Esposito,* eds. Islam, Gender and Social Change. New York: Oxford University Press, 1998.

*Joseph, Suad,* and *Afsaneh Najmabadi,* eds. Encyclopedia of Women and Islamic Cultures. Leiden: Brill, 2003.

*Moghissi, Haideh.* Feminism and Islamic Fundamentalism: The Limits of Postmodern Analysis. London: Zed Books, 1999.

*Roded, Ruth.* Women in Islamic Biographical Collections: From Ibn Sa′d to Who’s Who. Boulder, CO: Lynne Reinner, 1994.

***Алсу Әхмәдулла кызы Хасавнех,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 801.82

***Р.А. Абзалина***

## СӘЕТ ВАХИДИНЕҢ МИЛЛИ МУЗЕЙДАГЫ МИРАСЫ

В статье описывается коллекция историка и археографа Саида Вахиди (1887–1938), которая хранится в Национальном музее Республики Татарстан.

**Ключевые слова:** Вахиди Саид, история, Национальный музей Республики Татарстан, ярлык хана Сахиб Гирея, ярлык хана Токтамыша.

Татарстан Республикасы Милли музеенда Сәет Вахидинең үзе тарафыннан бирелгән өч ярлык саклана: аларның берсе – 1523 елда Сәхибгәрәй ханга бирелгән ярлыкның төп нөсхәсе, икесе – Алтын Урда ханы Туктамыш (XIV гасыр) белән Кырым ханы Сәгадәтгәрәй (XVI гасыр) ярлыкларының күчермәсе.

1936 елның 30 мартында төзелгән актта алар музейга 1925 елның 11 февралендә үк тапшырылган дип язылган. Иске кенәгәләр буенча 1936 елда Сәхипгәрәй хан ярлыгы 9562, Сәгадәтгәрәй ханныкы – 21850, Туктамыш хан ярлыгы 21851 номерлары белән теркәлгән.

Бүгенче кенәгәләрдә исә Сәхибгәрәй хан ярлыгы 5757, Сәгадәтгәрәй ханныкы – 5755, Туктамыш хан ярлыгы 5756 номеры белән йөри. Соңгы икесенеке – күчермәләр. Чынлыкта исә алар нөсхә документны хәтерләтә, әмма бик нык тузганнар һәм берничә кисәккә ертылганнар. Аларның алга таба сакланышын тәэмин итү максатыннан музейда түбәндәге пунктлар билгеләнде:

«6 – Все вышеназванные научные ценности, подаренные С.Г. Вахидовым Музей обязуется обеспечить полной сохранностью, для чего они закрепляются на постоянно за Музеем под личную ответственность его Директора, но под строгим наблюдением, как самого музея, так и дарителя С.Г. Вахидова. Изложенные в договоре условия хранения даримых ценностей должны быть выполнены без промедления.

7 – Музей не имеет права, подаренные С.Г. Вахидовым рукописи и документы продавать, отправлять в другие города, передавать каким-либо учреждениям, или сдавать в архив, а также обменивать на другие экспонаты без письменного разрешения С.Г. Вахидова. Равным образом Музей не имеет права без разрешения С.Г. Вахидова предоставлять подаренные рукописи и документы кому бы то ни было для изучения на руки на дом, опубликования в печати, или фотографирования. Даритель же С.Г. Вахидов оставляет за собой полное право пользования этими рукописями и документами на предмет изучения их и на дом».

Моннан тыш, С.Г. Вахиди үзенең автобиографиясендә аларны милли тарихи хәзинә итеп саклау өчен ничә еллар буе эзләве, аннан соң шул документларга

нигезләп татар тарихын (аеруча Казан ханлыгы чорын) язуы хакында тәфсилләп терки.

Тикшеренүләр тәҗрибәсеннән мәгълүм булганча, татар халкы тарихы буенча күпме документларның тулысынча югалганын, аларны эзләү өчен күпме вакыт, күпме акча сарыф ителүен эзтабар галим һәм бер Алла үзе генә белә.

Туктамыш хан белән Сәгадәтгәрәй хан ярлыкларының кайдан алынуы һәрчак зур кызыксыну уятты. Моны ачыкларга 1851 елда Казан университеты басмаханәсендә дөнья күргән «Тарханные ярлыки хана Тохтамыша, Тимур Кутлуга и примечаниями И. Березина» китабы ярдәмгә килде.

И. Березин язуынча, аны Одессадагы Тарих һәм Борынгылык җәмгыяте әзерләгән, монда алар Борзенков тарафыннан төп нөсхә зурлыгында эшләнгән литографик рәсемнең копиясеннән файдаланганнар, Тышкы эшләр министрлыгының беренче тәрҗемәчесе Ярцев текстны гарәп хәрефләреннән татарчага транскрипцияләгән, басмада кыскача кереш һәм кайбер искәрмәләр дә бирелгән.

В. Григорьевның Алтын Урда ханнары һәм рус дин башлыклары ярлыкларның дөреслеге турында 1842 елда Мәскәү Университеты типографиясендә басылган тарихи-филологик тикшеренүләре китабында Туктамыш хан ярлыгы хакында мондый юллар бар: «Прилагаемый здесь снимок во всех отношениях сходен с подлинником, хранящимся в Московском главном Архиве Министерства иностранных дел».

С.Г. Вахиди үзенең автобиографиясендә болар хакында тәфсилләп болай яза: «В 1925 году организовал Отдел Восточных Рукописей при Центральном музее ТССР в Казани, путем пожертвования через Акадцентр Татнаркомпросса коллекций документов, рукописей, родословного древа татарских ханов, на разных восточных языках, а также единственного документа XVI века – ярлыка Сахиб Гирея хана, который мной был найден, научно обработан и опубликован. <…> С 1 ноября 1926 года по 1 сентября 1930 года работал научным работником Центрального музея Татреспублики в качестве зав. отделом Восточных рукописей и документов. С 11 августа 1930 года по 1 сентября 1931 года работал научным работником в Научно-исследовательском институте Татреспублики по изучению и описанию восточных рукописей и документов. <…>

В 1925 году в июне месяце я был командирован Центральным Музеем ТССР в Спасский кантон по вопросу учета и охраны памятников старины, искусства и природы, где я составлял на местах список городищ, старых кладбищ и записывал надписи надгробных камней в следующих татарских деревнях Спасского кантона: в д. Таш-Бильги, в д. Иски-Ражаб и селе Матвеевке и др.

В этом же году 1925 – в июле мес. я был командирован Академическим Центром ТНКП для производства изучения и собирания материалов по истории края

и татарской народности, преимущественно на территории Татарской республики, где занимался собиранием устных и письменных материалов татарского народа, а также занимался исследованием надписей на надгробных камнях на старых кладбищах в деревнях: Эзмя, Зуриханах, Больших Ушмах, Акчишме и на кладбище около Кременчугского Городища в Мамадышском кантоне.

В 1925 году я пожертвовал через Академический Центр ТНКП двести десять восточных рукописей на тюркско-татарском и персидском и других восточных языках, в числе которых находится ярлык Сахиб-Гирея хана и родословное дерево Тюркско-татарских ханов, и других очень ценных исторических материалов для изучения татарской истории.

Академический Центр ТНКП принял мое пожертвование как ценный научный подарок, представлявший из себя очень ценный научный материал для изучения края и татарской истории и как признание моих трудов в области изучения края и тюркско-татарской истории и собирания важнейших научных материалов в этом направлении выразил мне официальную благодарность с подписями Наркома Ш. Ахмадиева и председателя Акадцентра известного ученого Г. Ибрагимова, секретаря З. Норкина от 10 февраля 1925 года за №5557.

На основании постановления Академического Центра Татнаркомпроса от 11 февраля 25 г. за №12 мне была объявлена официальная благодарность через татарскую газету “Кзыл Татарстан” от 15 февраля 1925 года за № 37 (1207), а в “Красной Татарии” от 13 февраля 1925 года за № 32 (2112) была помещена статья о моем пожертвовании под заглавием «Ценное пожертвование в Музей Татреспублики».

Дәүләт архивы материалларына нигезләп, Музей китапханәсе хезмәткәре Каргалова Татьяна Анатольевна «Казан» журналында (2015 ел, № 3, 43–47 битләр) Музей китапханәсен туплау турында мәкалә бастыра. Анда ул китапханәдәге басмаларга элеккеге педагогик китапханә, элекке Казан Духовный академиясе китапханәсендәге археология һәм сәнгатькә караган, Казан университеты китапханәсенең сәнгать һәм борынгылык музее, Кафедраль Собордагы иске басма китапларның да кушылуы, китаплар санының 15 мең томга җитүе хакында яза.

1925 елда музейда көнчыгыш кульязмалар бүлеге оеша. Аның нигезен Сәет Вахидинең музейга бүләк иткән 200 дән артык китабы тәшкил итә, алар арасында Сәхибгәрәй ханның әйтеп үтелгән ярлыгы да бар.

1929 ел ахырыннан китапханәдә давыллы чор башлана. 1930 елда аны һәм музейның үзен дә Татар фәнни-тикшеренү икътисади институтына кушалар, аннан институтның китапханә фонды Татарстанның Фәнни китапханәсе составына кертелә һәм 1932 елдан Казан университеты китапханәсенә кушыла. Элеккеге музей китапханәсендәге күп кенә китаплар һәм документлар әнә

шулай университет китапханәсе фондында калалар.

Шулай итеп, безнең музей фондында Сәет Вахиди мөһере сугылган китаплардан, 1997 елның 8 сентябрендә «Сәүдә йорты» («Гостиный двор») комиссион әйберләр кибетеннән өч йөз мең сумга сатып алынган китаптан тыш, берсе дә калмый. Ул китап – Гали Кодури хәзинәләреннән Ибне Шәех әл-Хурани әл-Хәмави әл-Хәнәфинең мөселман хокук белеме буенча трактаты (Мисырның әл-Әзһәр составына кергән «Җәүһәрия» мәдрәсәсендә күчереп алынган). Китапның күчермәсе XVII гасыр һәм 1750 еллар аралыгында гарәпчә «нәсх» стилендә кара һәм кызыл каралар белән язылган. Букча рәвешендә күн белән төпләнгән, саклау өчен өстеннән сатин тукыма белән тышланган. Барлыгы 169 биттән тора, сакланышы чагыштырмача яхшы, Алгы форзацта түбәндәге номерлар бирелгән: № 126 – кара тушь, № 152 – яшел карандаш белән язылган. Китапның үлчәме – 21×16,5 см. Алда – титул битендә, тагын ике бит өстәп, эчтәлек бирелгән. XIX гасыр урталарында реставрацияләнгән (ягъни яңадан күчереп язылган. Моны Раиф Мәрданов билгеләде).

2009 елда Музей фондына Сәет Вахидиның тагын бер экспонаты өстәлде. Ул – Николай Иосифович Воробьев документлары арасындагы «Выписка из протокола заседания президиума Академического центра Наркомпроса ТАССР от 11 июня 1926 г.». Утырыш күчермәсеннән аңлашылганча, анда сүз тарихи-этнографик тикшеренүләр алып бару өчен Кама аръягына сәфәр оештырылуы һәм Туган якны өйрәнү өлешеннән командировка өчен 250 сум акча бүлеп бирүе хакындагы мәсьәлә каралган була.

Әгәр дә 1927 елда итнең килограммы 42 тиен торганын истә тотсак, күптән түгел генә оешкан Татарстан Автономияле республикасының мәдәни мирасны саклауга тоткан чыгымнарын күзаллау кыен түгел. Документ музейда КП 36509/14 номеры белән саклана.

***Абзалина Рәмзия Әсрар кызы,***
*Татарстан Республикасы Милли музее өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.14

*Ә.М. Закирҗанов*

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ҺӘМ XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ

Статья посвящена рассмотрению драматических произведений Гаяза Исхаки в контексте развития татарской сценической литературы начала XX века. Особое внимание уделяется выявлению социокультурных, общественных условий развития драматургии начала XX века. Выявляя основные этапы творчества писателя, исследуются его поиски в области тематики и жанрового своеобразия, конфликта и национального образа, художественных средств.

**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, татарская драматургия, эпоха, возрождение, национальная особенность, жанр, конфликт, образы.

Татар халкының мәдәнияте, аеруча әдәбияты тарихында XX йөз башы гаять әһәмиятле урын алып тора. Бу елларда бер төркем әдипләр иҗат мәйданына килеп, гаять бай рухи мирас калдыра. Милли-мәдәни Яңарыш зур бер дулкын булып, яшәешнең бөтен өлкәләренә үтеп керә. Әлеге дәвер алып килгән зур табыш-яңалыклар тулы бер гасыр татар әдәбиятын сугарып тора, күпсанлы традицияләргә нигез сала. XX йөз башы татар тормышына гаять зур йогынты ясап, «яңа заман татар Ренессанс әдәбиятының нигез ташларын салучы» [Ганиева, 1998, б. 63] һәм халыкның милли-азатлык көрәше лидерларыннан берсе – Гаяз Исхакый. Матур әдәбиятның проза, драмтургия өлкәләрендә, шулай ук публицистика һәм әдәби тәнкыйтьтә киң танылып, ул үз вакытында замандашлары Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Й. Акчура, Г. Кәрам һ.б. тарафыннан бик югары бәяләнә.

Әдипнең бай һәм киңкырлы иҗатында драматургия үзгә урын алып тора. Бердән, ул сәхнә әдәбиятының театр белән бәйлелеген яхшы аңлап, шуның белән киң җәмәгатьчелеккә фикерләрен тизрәк җиткерергә тели; икенчедән, үз чорының социаль типларын тудырып, сәхнәдә аларның образын күрсәтү, еш кына, тамашачы буларак үзләреннән үзләрен көлдерү мөмкинлеге бирә; өченчедән, прозада әйтеп бетерә алмаган уй-фикерләрен, идеяләрен диалог-монологларда чагылдыру юлын таба; дүртенчедән, татар театрының үсеше өчен яхшы репертуар кирәклеген аңлап, әсәрләре белән театр сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. Бу уңайдан, алгарак китеп, бер фактны искәртеп үтик. 1916 елны «Сүз» газетасында басылган «Татарча театр вә концерт» язмасында язучы үзенең татар театрына 10 ел хезмәт итеп тә, бер тиен гонорар алмавын билгеләп үтә [Исхакый, 2008, б. 189].

Г. Исхакый Октябрь вакыйгаларына кадәр 9 пьеса яза һәм

алар эчтәлеге, күтәрелгән проблемалары, сәнгати эшләнешләре буенча әдипнең иҗади үсеше, эзләнүләре белән туры килә. Әдәбият фәнендә әлеге иҗатның чорларга бүленеше башлап Г. Сәгъди тарафыннан аталып [Сәгъди, 2008, б. 69], Р. Ганиева исә аны фәнни концепциягә сала һәм түбәндәгечә билгели: 1) мәгърифәтчелек чоры (1897–1904); 2) «таң»чылык чоры (1905–1911); 3) милләтчелек чоры (1912–1918); мөһаҗирлек чоры (1919–1954) [Ганиева, 1998, б. 64].

XX йөз башында татар драматургиясе формалашу, аякка басу чорын кичерә, яңа жанрларга байый, чынбарлыкка нисбәтле җитди мәсьәләләргә игътибар итеп, аларны чагылдыруда яңадан-яңа алым-чаралар эзли. Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» (1900) һәм «Ике гашыйк» (1903) пьесалары сәхнәгә җитди яңалык алып килә. Бу төрдә беренче үрнәкләр итеп, Г. Ильяси, Ф. Халиди әсәрләрен әйтергә була, әмма алар жанр ягыннан шактый йомшак пьесалар. Драматургия әсәрләре язарга алынган яшь авторлар өчен өлге булырлык, жанр таләпләренә туры килгән, сәхнә закончалыкларына нигезләнеп язылган хезмәтләрдән Г. Камалның «Бәхетсез егет»ен, Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш»ын санарга кирәк. Г. Исхакый, чынбарлыкның ул чорда күп бәхәсләр уяткан күпхатынлылык проблемасына мөрәҗәгать итеп, мәгърифәтчелек реализмы кысаларында язылган пьеса тәкъдим итә. Шуны да билгеләп үтик, ул сәхнәгә куелган беренче пьеса 1905 елның 21 апрелендә Уфа җәмәгатьчелегенә тәкъдим ителә. Искелек-яңалык конфликтына нигезләнгән сюжетта автор Коръәннән килә торган әхлакый фикерләрне яклый. Аның берсе – начарлыкка да яхшылык белән җавап бирү, икенчесе – изгелекнең, яхшылыкның нәтиҗәсе – бәхет. Әлеге карашлар, беренче чиратта, Әсма образында, аның эш-гамәлләрендә чагыла. Әсәрдә авторның карашлары Риза образы аша белдерелә. Яшь егет халыкны гыйлемле итү теләге белән яши, китапханә ачарга җыена. Шул рәвешле, халыкчылык идеяләре дә урын ала. Пьесаны буеннан-буена сабырлык мотивы иңләп үтә. «Ике гашыйк»та (1903) Г. Исхакый беренче пьесадагы мәсьәләләрне үстерә барып, алгы планга никах иреген, ир кеше һәм хатын-кыз хокукын яклауны чыгара. Автор чынбарлыкка якын торып, этнографик детальләр, ашау-эчү, кием-салым һ.б. аша чорны күз алдына бастыра. Геройлар язмышында йөрәк һәм акылга нисбәтле сыйфатлар зур роль уйный, социаль шартлар йогынтысы арта бару да игътибардан читтә калмый. Гомумән, хис-кичерешкә, геройның эчке дөньясын тулырак ачуга, күз яшен агызуга нигезләнгән сентименталь пьеса мәйданга чыга.

Башлап проза һәм драма әсәрләре белән чирканчык алган Г. Исхакыйның дөньяга карашы, тормыш каршылыкларын аңлавы җитди үзгәреш кичерүнең чагылышы буларак, «Ике

йөз елдан соң инкыйраз» (1904) антиутопиясе языла. Р. Ганиева билгеләгәнчә, ул – «XX гасыр башы татар әдәбиятының төп үсеш юлларын билгеләүче программ әсәр» [Ганиева, 1998, б. 67]. Моңа кадәр мәгърифәтчелек реализмы принципларын үзләштергән әдип, бу әсәрендә мәгърифәтчелек романтизмының әдәби-эстетик байлыгына да теләп мөрәҗәгать итә.

Беренче рус инкыйлабы, шуның нәтиҗәсендә яулап алынган демократик хокукларга бәйле татарча газета-журналлар чыга башлау, театр барлыкка килү, җәдит мәдрәсәләренең артуы, татарларның актив рәвештә социаль һәм милли хокукларны яклауга тартылуы – болар барысы да сәхнә әдәбияты өлкәсендә эшләүчеләргә көчле йогынты ясый. Аның төп нәтиҗәсе, әдипләрнең заман проблемаларын алгы планга чыгарып, һәртөр искелек-артталыкны фаш итүендә, фанатик дин әһелләрен усал тәнкыйтьләүдә, гаилә-никах мәсьәләләрен яңарыш белән бәйләп бирүдә, социаль һәм сыйнфый көрәш сорауларына мөрәҗәгать итүдә чагыла. Татар драматургиясе формалашу һәм аякка басу дәверенең икенче этабында (1906–1911 елларда) тәнкыйди реализм иҗат методы мәйдан яулый, әкренләп, хәл-күренешләрне җәмгыятьнең яшәеш нигезләре, андагы шарт-сәбәпләр белән бәйләп ачкан, чор типларының гыйбрәтле образларын тудырган әсәрләр языла башлый.

Иҗатының «“таң”чылык чоры» дип аталган елларында Г. Исхакый «Таң йолдызы», «Тавыш», «Таң мәҗмугасы» кебек газета-журналлар чыгара, тулы бер цикл проза әсәрләре яза, сәхнә әдәбиятын гыйбрәтле пьесалары белән баета, аңа яңа тематика, яңа сулыш алып килә. Әдип үзен революцион көрәшкә багышлый, әсәрләрендә, публицистик язмаларында социаль һәм сыйнфый тигезлек мәсьәләләрен кыю күтәреп, «Тартышуда гына табарсың син үз бәхетеңне!» дигән девиз белән чыгыш ясый. Исхакый бу чор татар драматургиясен яңа тема-мотивлар, сәнгати эзләнүләр, яңа жанр һәм жанр формалары белән генә баетып калмый, бәлки яңа башлангычларга да нигез сала. «Алдым-бирдем» драмасы – тәнкыйди реализм принципларына нигезләнеп язылган беренче татарча пьеса. Автор хатын-кыз азатлыгы, гаилә кору, никах иреге кебек проблемаларны шул чор татар җәмгыятендә хөкем сөргән патриархаль күренешләрне кире кагу, шәхес иреген яклау өчен тартышу юлына чыгучы геройлар аша ача. Галия һәм Ибраһимның эшгамәлләрендә әлеге мәсьәләләр бәхәсләшү, карашлар төрлелеге, фактик мисаллар ярдәмендә бәяләнә һәм укучы-тамашачыны да нәтиҗә ясауга китерә. Әлеге мәсьәләләр башка драматурглар иҗатында да сурәтләнеп, җитди яңгыраш ала. Мисал өчен, С. Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» (1907) драмасында шәхес ирегенә, хатын-кыз азатлыгына бәйле бәхәсләр милли яңарыш мәсьәләләре белән үрелеп китә.

Г. Исхакыйның «Тартышу» (1908, 1917 елда басыла) драмасы тарихи-революцион эчтәлеге белән җәлеп итә. Г. Коләхмәтовның «Яшь гомер»ендә сөйләү, фикер алышу рәвешендә яңгыраган сыйнфый көрәш идеясе әлеге әсәрдә төрле партияләр көрәшенең гамәлдә чагылышы булып тора. Драмада «тартышу» күптөрле мәгънәләрдә килеп, аеруча киң яңгыраш алганнары түбәндәгеләр: 1) патша самодержавиесе белән тартышу; 2) искелек-яңалык тартышуы; 3) аталар һәм балалар тартышуы; 4) ирек өчен тартышу; 5) партияләр арасындагы тартышу; 6) ике сыйныф арасындагы тартышу; 7) геройның эчке дөньясындагы тартышу һ. б. Драмада шул чор җәмгыятендә урын алган төрле бәхәсләр, яшәештәге күренешләр киң урын алып, авторның аларга мөнәсәбәте дә чагыла. Шуларның берсе – «татар» һәм рус революцияләре. Бөтен Россияне кузгаткан халык күтәрелеше, самодержавиегә каршы көрәш белән бәйле рус революциясенә татарларның да бер өлеше кушылып китә. Төрле партияләргә кергән яшьләрнең листовка-прокламацияләр таратуы, халык вәкилләре каршында чыгыш ясаулары, агитация-үгетләүләр – шуның бер чагылышы. Үзләрен социаль тигезлек кебек якты идеалларга багышлаган яшьләр, төрлечә эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә идән асты тормышына дучар булсалар да, сайлаган юлларыннан чигенмиләр. А. Әхмәдуллин язганча, андый геройлар рухи өлгергән, үзләрен корбан итәргә дә әзер, хәтта билгеле бер дәрәҗәдә аскетлар итеп сурәтләнә [Ахмадуллин, 2003, с. 415]. «Татар» революциясе исә драмада татар җәмгыяте эчендә барган көрәшне аңлата. Бу, беренче чиратта, европача киенү, рус телен һәм рус теле аша Европа илләре казанышларын өйрәнү, һөнәр үзләштерү хокукы һәм гаиләдәге иске гадәтләрдән арыну өчен төрле буыннар, төрле социаль катлаулар арасында барган тартыш. Шунысы игътибарга лаек, Г. Исхакыйның әлеге әсәре шул заман әдипләренә зур йогынты ясый һәм драматургиядә көрәш-тартыш рухы белән сугарылган пьесалар мәйданга чыга. Мисал өчен: Ф. Әмирханның «Яшьләр»е (1909), «Тигезсезләр»е (1913), К. Тинчуринның «Беренче чәчәкләр»е (1914) һ.б.

Мәгърифәтчелектән килгән әдәби-эстетик карашларны үстерә барып, Г. Исхакый үз иҗатында халыкчылык идеяләренә дә киң урын бирә. Халык арасына китеп, аңа аң-белем таратуны, яңарышка өндәүне аңлаткан әлеге күренеш «Тартышу» пьесасында да чагылып китә. Ә инде «Мөгаллим» (1907) драмасында ул үзәк мәсьәлә буларак урын ала. Төп герой – мөгаллим Салих милләткә хезмәт итү идеалы белән яшәсә дә, максатына ирешә алмавы өчен рухи газап кичереп яши. Ул авыл халкын әдәпәхлакка, белем-мәгърифәткә тартып, аларны авыр тормыштан коткарырга тели. Автор Салихның уй-фикерләрен, эшгамәлләрен авыл крестьяннарының каршылыклы тормышы белән үреп бара. Моңа төрле социаль катлаулар арасындагы

каршылык-бәхәсләр килеп кушыла. Ә инде гаилә кору, балалар туу белән Салих күңелендәге каршылык тагы да арта. Ул, Р. Ганиева билгеләп үткәнчә, «өйләнү, гаиләле булу ир кешенең җәмгыять эшчәнлегенә аяк чала дигән толстойчылык карашлары»на [Ганиева, 1998, б. 67] барып тоташа. Салих, яшәвенең мәгънәсе, иң зур теләк-хыялы халкына хезмәт итүдә, дигән фикергә килә. Нәтиҗәдә бертөрле генә бәяләнми торган адым ясый – хатынын, балаларын калдырып китә. Гаилә «тышавы»ннан арынып, үзен тулысынча халкына хезмәт итүгә багышлый.

Г. Исхакыйның «Җәмгыять» (1909) һәм «Кыямәт» (1909) комедияләре искелек-артталыкны фаш итү пафосы белән сугарылган. Әдип «Җәмгыять»тә һәртөр наданнардан, бушкуыклардан, үзләрен җирнең кендеге дип санап та берни эшли белмәүче икейөзлеләрдән ачы итеп көлә. Мохтаж-ятимнәргә ярдәм итәргә тиешле хәйрия җәмгыяте оештырырырга йөреп тә, сүзләре һәм эш-гамәлләре кеше тикшерүдән, мактанышудан узмаган кара йөзләрне автор татар җәмгыятенең эчке хәленә нисбәтле сурәтли. Комедия геройлары (арада Муса мирза аерылып тора) зур булмаган штрихлар белән генә бирелсә дә, драматург үз чорының социаль йөзен, тулы образын тудыра. Шул рәвешле, әдәп-әхлак, дини мәсьәләләр белән үрелгән хәлдә чынбарлыкның җитди социаль-иҗтимагый проблемалары калкып чыга, аларга җавап эзләнә. «Кыямәт» сатирик комедиясе – халыкчан, карнавал рәвешендәге көлүгә йөз тоткан пьеса. Автор «алтын язулы күкәй»не образ-символ дәрәҗәсенә күтәреп, яңалык дошманнарының ялган битлеген салдыра һәм чын йөзләрен ача. Г. Исхакыйның әлеге комедияләре, Г. Камалның «Бүләк өчен» (1909), «Банкрот» (1911), И. Богдановның «Помада мәсьәләсе» (1908), С. Рәмиевнең «Низамлы мәдрәсә» (1908) кебек пьесалары белән бергә, бу еллар татар драматургиясендәге сатирик юнәлешне баетып, үстереп җибәрүгә зур өлеш кертә һәм ул җитди үзенчәлек буларак тулы бер тенденция төсен ала.

Г. Исхакыйның милләт язмышы өчен көрәше аны күптөрле кыенлыклар, төрмә-зиндан газаплары кичерүгә дучар итә. Ул Россиянең дистәләгән шәһәртөбәкләрендә яшәргә мәҗбүр була, байтак вакыт Төркиядә яшәп ала. Үз чоры татар җәмгыятенең төрле якларын ачу белән бергә, әдип халкыбызның фаҗигале үткәне, аның тарихында канлы яра булып торган көчләп чукындыру вакыйгаларына да мөрәҗәгать итә. Россиянең милли-колониаль сәясәтен фаш итү максатында «Зөләйха» пьесасын яза. 1907 елда Чистай төрмәсендә языла башлаган әсәр югалтулар, яңадан башлаулар, күчереп язулар аша бары 1912 елда тәмамлана һәм 1917 елда гына сәхнәдә куела. Г. Исхакый «Зөләйха» пьесасы белән татар драматургиясендә яңа бер юнәлешне башлый. Әсәр сәхнә әдәбиятында беренче трагедия буларак та үзенчәлекле [Zakirzyanov, 2014, s. 347].

Пьесаның әлеге жанр таләпләренә ни дәрәҗәдә туры килүе турында бәхәсләр дә бар. Шулай да үзенең фаҗигале эчтәлеге, гаять кискен һәм чишелмәслек конфликты, барыннан да бигрәк иманын саклау юлында меңтөрле авырлыкны җиңеп чыккан һәм шул юлда үзен корбан иткән төп герое белән ул трагедия дип бәяләнергә тиеш. Зөләйха образы дини-милли символ дәрәҗәсенә күтәреп сурәтләнә, милләт анасы буларак тәкъдим ителә. Әсәрдә аның гаять бай, матур эчке дөньясы, теләк-омтылышлары, балаларына, якыннарына якын мөнәсәбәте һәм дин дошманнарына каршы торуы романтик сурәтләрдә, шул ук вакытта бөтен кырыслыгы, фаҗигасе белән ачыла. Вакыйга-күренешләрнең тормышка якынайтылуы аның тәэсир көчен арттыра, укучы-тамашачыны катарсиска-чистарынуга алып килә. Пьесада Корьән тәгълиматы, дини мифологиядән алынган риваятьләр, пәйгамбәрләр тарихына караган мәгълүматлар, шартлы образлар мөселман һәм христиан динендәге кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре белән кушылып китә, катлаулы синтез тәшкил итә. XX гасыр ахырында җәмгыятьтә идеологик чикләүләр беткәннән соң, Исхакыйның «Зөләйха»сы яңадан әйләнеп кайта һәм әлеге исем, яңа мифологик төсмерләр белән баеп, динебез, милләтебез, иманыбыз сагында тора.

«Зөләйха»да күтәрелгән фаҗига тәмамланган вакытта Г. Исхакыйның дөньяга карашы, иҗтимагый һәм милли омтылышлары җитди үзгәреш кичерә. «Таң»чылык чорында революцион көрәш, сыйнфый дошманлык идеяләре белән яшәгән әдип татар халкын бер милләт, бердәм милләт итеп күрү фикеренә килә. Шул рәвешле, иҗатында татар халкының төрле социаль катламнарын берләштерү, аның үткәнендәге казанышларын һәм фаҗигаләрен гәүдәләндерү, бүгенгесен кайгыртып җитди эшгамәлләр кылу, киләчәге турында борчылулы фаразлар кылу кебек карашларын үз эченә алган «милләтчелек» чоры башлана. Әдипнең әлеге дәвердә язылган пьесалары йогынтысында һәм башка каләмдәшләренең җитди эзләнүләре нәтиҗәсендә, татар драматургиясендә җитди борылыш ясала. Сәхнә әдәбияты, сан һәм сыйфат үзгәрешләре кичереп, чынбарлык күренешләрен романтизм юнәлешенә хас алым-чараларда чагылдыруга килә. Бу исә драматургиядә хисчәнлекне, геройның рухи дөньясын киңрәк, тулырак ачуны, еш кына купшы сурәтләргә мөрәҗәгать итүне үстерә. Нәкъ менә романтик юнәлештәге әсәрләрдә милләт язмышына караган мәсьәләләрнең киң чагылыш табуын Й. Нигъмәтуллина «идеяләр романтизмы» дип атый [Нигматуллина, 1997, с. 137]. Әдипләрнең Шәрык белән бергә Гаребнең әдәби-эстетик казанышларын үзләштерүләре нәтиҗәсендә төрле алымнар синтезына нигезләнгән әсәрләре языла. Әлеге һәм башка сыйфатлар Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» (1913), Ф. Борнашның «Язмыш» (1914), М. Фәйзинең «Кызганыч» (1913), «Галиябану»

(1916), Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1915), К. Тинчуринның «Назлы кияү» (1916), «Соңгы сәлам» (1917) һ. б. пьесаларда чагылыш таба [Миңнуллина, 2017, б. 60].

Әнә шундый шартларда Г. Исхакыйның «Мөгаллимә» (1913) драмасы дөнья күрә. Бу чорда язылган иң яхшы пьесаларның берсендә хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе, халыкчылык идеяләре белән кушылып, җитди иҗтимагый яңгыраш ала. Җ. Вәлиди язганча, «аның бу әсәрендә без народниклыкның яңарак бер шәкелен, романтизм буявына буялган хәлен күрәмез» [Вәлиди, 2001, б. 211]. Автор укытучы Фатыйманың гүзәл образын тудырып, эш-гамәлләренә, теләк-омтылышларына бәйле, бөтен әдәбият өчен яңа булган сорауны куя һәм җавап эзли: кеше кайсын сайларга тиеш – шәхси бәхетнеме, әллә милләткә хезмәт итүнеме? «Мөгаллим» пьесасында урын алган мәсьәлә яңа яссылыкта куела һәм хатын-кызның җәмгыятьтәге, гаиләдәге, ирләр тормышындагы урыны турында җитди бәхәсләргә китерә, «җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итә-итә, яңа тип геройлары белән әдәбиятны, сәхнәне баетып, тарихи процесска кушылып китә» [Мәхмүтов, 1991, б. 650]. Әлеге пьеса белән Г. Исхакый татар дөньясының төрле катлауларына бер булып, бердәм булып милләт мәнфәгатенә хезмәт итү кирәклеге турында аваз сала. Үз вакытында зур кызыксыну тудырган, күп бәхәсләргә китергән әсәр бүген дә заманча яңгырый.

Шулай итеп, Г. Исхакыйның 1917 елгы революцияләргә кадәр язылган драма әсәрләренә зур булмаган күзәтү дә әдипнең татар сәхнә әдәбиятын формалаштыру, аякка бастыруда мөһим, хәтта хәлиткеч роль уйнавын күрсәтә. Ул драматургиябезне яңа тема-мотивлар белән баета, җитди мәсьәләләрне алгы планга чыгарып, күпсанлы укучы-тамашачыларны үз артыннан ияртә, яңа жанрларга, сәнгати чара-алымнарга нигез сала. XX йөз башы драматурглары, аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ы белән бергә, без югарыда искә алган күпсанлы пьесаларындагы табыш-яңалыкларга да даими мөрәҗәгать итә, иярә, бәхәскә керә һәм яңа тормыш материалында аларны үстерә, баета һәм алдагы чор сәхнә әдәбиятына китереп ялгый.

**Әдәбият**

*Ахмадуллин А.Г.* Драматургия // История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX в.). Казань: Фикер, 2003. С. 406–428.

*Вәлидов Җ.* «Мөгаллимә (Гаяз Исхакый әсәре)» // Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Т. 8. Б. 209–218.

*Ганиева Р.К.* Исхакый иҗаты // Мирас. 1998. № 5. Б. 63–78.

*Исхакый Г.* Татарча театр вә концерт // Әсәрләр: 15 томда. 7 том: Публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Т. 7. Б. 186–189.

*Мәхмүтов Һ., Гайнанова Л.* Зарыгып көткән мирас // Зindан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре / төзүчесе, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче

Л. Гайнанова; кереш һәм ахыр сүз авторлары Н. Нуруллин, Һ. Мәхмүтов, Л. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 636–660.

*Миннуллина Ф.Х.* Трагедия личности в драматургии К. Тинчурина // Фәнни Татарстан. 2017. № 3. С. 60–64.

*Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.

*Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы // Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык / төзүчеләр Д. Заһидуллина, Ч. Гыйләҗева. Казан: Җыен, 2008. Б. 52–190.

*Zakirzyanov A.M.* Problems of transformation of the genre of tragedy // Life Science Journal. 2014. T. 11. № 7. S. 346–351.

***Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире*

УДК 821.512.145

***Г.Ф. Зиннәтуллина***

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕ ТЕЛЕНЕҢ ОБРАЗЛЫЛЫГЫ

В данной статье рассматриваются художественно-выразительные средства языка произведений выдающегося татарского писателя, публициста и общественного деятеля конца XIX – начала XX века Гаяза Исхаки. Язык художественных произведений писателя выражает его мысли и чувства в выразительной форме, при помощи образного мышления, представляющего собой сложное отражение фактов, явлений действительности в виде чувственных представлений, ассоциативно связанных друг с другом. Стилистические особенности художественных произведений Г. Исхаки исследуются как образец национального татарского литературного языка начала XX века.

**Ключевые слова:** образность, стилистически-экспрессивные средства, абстрактность, логические эпитеты, метафорические эпитеты.

Әдәби әсәрләрнең теле образлы һәм мавыктыргыч була. Шуның белән ул укучыны үзенә җәлеп итә, аңа көчле тәэсир ясый.

Образлылык телдәге күптөрле үзенчәлекләрне һәм сурәтләү алымнарын куллану нәтиҗәсендә туа. Тел чаралары аша сурәт барлыкка китерү катлаулы мәсьәләләрнең берсе ул. Матур әдәбият әсәрләрендә барлык сүзләр дә сурәтле була алмый. Әмма аларның һәрберсе, сөйләмдә башка сүзләр белән бергә кушылып, образлылык тудыруга ярдәм итә. Кайбер әсәрләрдә кешегә эстетик тәэсир итү, анда тирән эчке тойгылар уяту гаять югары була. Бер төркем әсәрләрдә исә, публицистик сөйләм үзенчәлекләре өстенлек ала. Бу аерымлыклар жанр төрлелеге һәм язучының үзенә хас язу алымнары белән эш итүгә бәйләнгән, дип билгеләп үтә В.Х. Хаков [Хаков, б. 188].

Гаяз Исхакый әсәрләрендә образлы тел-сурәтләү чаралары күзгә ачык бәрелеп тормый. Бу – әдипнең язу стиле белән бәйләнгән. Кайсы гына әсәрен алып карасак та, язучының хикәя, повестьларында публицистик сөйләм үзенчәлекләре зур урын ала. Профессор В.Х. Хаковның югарыда әйтелгән фикере Г. Исхакый әсәрләренең теле белән дә раслана [Губайдуллина, с. 153].

Аерым язучының образлы телен, стилистик-экспрессив чараларын тикшергәндә, билгеле, аларны әсәрнең идея-эчтәлегенә бәйләп карыйсың. Һәр әсәрнең үзәгендә төрле характердагы персонажлар тора. Алар төрле тел-сурәтләү чаралары аша сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсенә күтәрелсәләр, төрле поэтик бизәкләр ярдәмендә үзләренә хас характер белән индивидуальләшәләр.

Һәр әдәби әсәр нинди дә булса аерым бер чорны чагылдыра.

Язучының тел материалы да шул чорга, анда яшәүче кешеләрнең характерына җайлаштырылып кулланыла. Башлангыч иҗатында ул әле күбрәк әзер метафораларны куллана, тел хәзинәсе белән эш итә. Иҗат итү процессында язучының дөньяга карашы, әйләнә-тирәне танып белүе, тел материалы белән эш итү осталыгы киңәя. Шулай итеп, ул туган телне яңа чаралар белән баетуга зур өлеш кертә.

Г. Исхакый беренче әсәрләрендә үк үзен геройларының эчке дөньясын, холык-фигылен, характер үзенчәлекләрен, тышкы портретын оста сурәтләүче язучы икәнлеген күрсәтә. Бу, әлбәттә, тел материалы нигезендә тормышка ашырыла. Моңа әдипнең һәр геройның характер үзенчәлеген белеп кулланган метафоралары ярдәмгә килә. Мәсәлән, «Бай углы» әсәрендә нечкә күңелле, тормыш һәм матурлыкны сөючән, хисле Бәдрияне сурәтләгән метафорага игътибар итик: «...су буйларында, урманлыкларда үскән, матур һавада тәрбия кылынган бер *чәчәк* иде» [Исхакый, 1988, б. 137]. «Солдат» хикәясендә сөйгәне Садыйкның солдатка каралу хәбәре белән борчылган, кайгырган Гайнигҗамалның эчке кичерешләрен Г. Исхакый түбәндәгечә бирә: «Гайниҗамал урынында утырып тора алмый башлады. Ул үзенең аналарыннан яшерер өчен, үзенең дус кызына кич утырырга китте. Анда да *йөрәгенә урын таба алмады*» [шунда ук, б. 338].

Алдагы мисалда автор *таш йөрәк түгел* метафорасы аша Кәримәгә хас характерлы сыйфатларны ачып бирә, аның каты бәгырьле түгеллеге, нечкә күңелле кеше икәне күренә: «Камәр башын алдына алып туктатырга тырышса да, Камәрнең һәрбер хәсрәте яңадан ачылганга, атасы өчен, Габделәхәт өчен, анасы китүе өчен аерым-аерым еглый иде. Кәримә дә *таш йөрәк түгел*, ул да еглый!» [Исхакый, 1988, б. 61].

Метафораны төзү өчен хистойгы, эмоциональлек кенә җитми, аң-акыл да кирәк. Мәсәлән, язучының «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясе мәгърифәтчелек рухында язылган, анда белем алырга өндәү, үгет-нәсыйхәт бирү, белемле булу нәтиҗәсендә бәхеткә ирешү, наданлыктан котылу турында сүз бара. Бу идея метафорик образ ярдәмендә аңлатыла: «*Шул наданлык караңгылыгыннан коткарырга тырыш,* ди Хәлимгә әнисе» [Исхакый, 1988, б. 3]. Биредә татар милләтенең наданлыгы төн караңгылыгына охшатыла. Әмма бу метафорик конструкциядә чагыштыру объекты яшерелә. Объект һәм субъект янәшә куелмый, мәгънәләр кисешә, берләшә. Минемчә, әсәрнең идея-эчтәлеген гомумфонда чагылдыручы бу метафораның мәгънәсе аң-акыл һәм хис-тойгы белән үлчәнә.

Автор персонажларның эчке кичерешләрен, хәл-әхвәлен, тормыш-көнкүрешен, социаль хәлләрен сурәтләгәндә герой яшәгән мохиттәге гомумкулланылыштa йөргән сүзләр ярдәмендә метафора ясый һәм шулар аша аларның эчке халәтләрен сурәтли: *«Хәлимне Казанның зур мәдрәсәсе бик салкын кабул*

*итте»* [Исхакый, 1995, № 9, б. 30]; «*Җәйге тормыш аны* (Хәлимне. – *Г.З.*) *тагы изде*» [Исхакый, 1995, № 10, б. 34]; «*Кырмыска оясы кеби кеше кайный торган Печән базары анларны* (шәкертләрне. – *Г.З.*) *чакыра, анларны эченә алыр өчен, эченә алып кайнатып, үз казанында эретеп, «казанлы» итәр өчен тырыша кеби тоелды»* [Исхакый, 1995, № 9, б. 27].

Г. Исхакый табигать күренешләрен, тирә-юньне сурәтләгәндә дә метафоралар куллана. Мәсәлән, «Очрашу, яки Гөлгыйзар» хикәясендә: «Парахут бик матур йердән бара иде, бер як урман, икенче як бик киң сахра иде. Кояш түбән төшә башлаганга, *көн эссесе кайткан* иде. Парахут өсте тып-тын иде. Арттагы чак-чак иткән акчарлак тавышлары гына парахуттагы тынычлыкны бетерә иде. Сахра ягында бер көтү яткан иде. Аннан бер-ике чакрымда гына бер мөселман авылының яшелгә буялган манарасы күренеп тора иде. Бу манара акыртын гына төшкән кояш нуры берлән ялтырап гаҗәп бер күренештә иде. Манара очындагы *гөмбәзе* ялт-йолт итеп *күз нурын ала* иде. Бу авылга караган саен карыйсы килә, караган саен *күңел рәхәтләнә иде»* [Исхакый, 1988, б. 81]; «Йомшак *кояш йылысы* аны *үпте, кочты, сөйде»* [Исхакый, 1995, № 5–6, б. 33].

Метафора, күчерелмә мәгънәдә булганлыктан, билгеле, абстрактлылыкка тарта. *Кайгы төсе* [Исхакый, 1988, б. 339], *йөрәк яну* [шунда ук, б. 61], *күз нуры* [шунда ук, б. 81] кебек метафораларда да бу көчле. Кайгының да төсе юк, йөрәк тә янмый. Ләкин аларның эчтәлеге аңлаешлы. Чөнки аларны халык үзе уйлап чыгарган. Әлеге мисаллардан күренгәнчә, Г. Исхакыйның метафоралары да халык сөйләменә нигезләнгән.

Тел галиме С.Ш. Поварисовның «Мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү» хезмәтендә күрсәтелгән бүленешкә нигезләнеп, Г. Исхакыйның сәнгатьле прозасында күзәтелгән метафораларны объектив чынбарлыктагы тормыш-көнкүреш, социаль-сәяси төшенчәләрне, геройларның эчке кичерешләрен белдерү һәм башка үзенчәлекләр буенча түбәндәгечә классификацияләргә мөмкин [Поварисов, б. 62]:

1) социаль-сәяси хәлләр белән эчтәлекләнгән метафоралар. Бер үк предмет, төп мәгънәсеннән тыш, бик күп төшенчәләрне эченә алырга мөмкин. Мәсәлән, *авыл юлы* – туры мәгънәдә, *милләт юлы* дисәк, бу – күчерелмә мәгънәдә, ул билгеле бер социаль төшенчәне эченә ала. Мондый эчтәлектәге метафоралар Г. Исхакыйның публицистик характердарак язылган «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Зиндан» әсәрләрендә күбрәк чагылыш таба. Мәсәлән: *граждан каны* [Исхакый, 1988, б. 277 ]; *золым исе* [шунда ук]; *бюрократия золымы* [шунда ук] һ.б.;

2) революцион көрәш белән эчтәлекләнгән метафоралар Г. Исхакыйның турыдан-туры революция темасына багышланган «Габдулла» хикәясендә күзәтелә: *революция юлы; революциягә корбан кылды* [шунда ук, б. 272];

3) тормыш-көнкүреш хәлләре белән эчтәлекләнгән метафоралар: *базар халкы* [Исхакый, 1988, б. 56]; *тормыш изде, тормыш тупасланды, тормыш дорфаланды, тормыш ялангач калды* [Исхакый, 1994–1996] һ.б.;

4) табигать күренешләрен образлы тасвирлаган метафоралар: *кояш нуры* [Исхакый, 1988, б. 81]; *кояш йылысы үпте, кочты, сөйде* [Исхакый, 1994–1996] һ.б.;

5) эчке хисләрне тасвирлаучы метафоралар: *шатлыгым тамагыма сыймый* [Исхакый, 1988, б. 37]; *рәхмәт күзләре* [шунда ук, б. 43]; *күңеленә рәхмәт салды* [шунда ук, б. 43]; *кара бәхет* [шунда ук, б. 51]; *йөрәк яну, исәнлек күзе* [шунда ук, б. 61]; *таш еглар; сәфаләт күзе* [шунда ук, б. 69]; *шатлык хисе, өметсезлек хисе, кайгы төсе* [шунда ук, б. 339]; *күз яшен буу* [шунда ук, б. 341]; *уен мәйданга чыгару* [шунда ук, б. 346]; *баш вату* [шунда ук, б. 347]; *күңел күзе; рухани азык* [Исхакый, 1994–1996] һ.б.;

6) абстракт мәгънәле метафоралар: *күз очы* [Исхакый, 1988, б. 73]; *күз нуры* [шунда ук, б. 81]; *сәгадәт юлы* [шунда ук, б. 103]; *начарлакның нигезе* [шунда ук, б. 347]; *яхшылыкның башы* [шунда ук, б. 347] һ.б.;

7) дини эчтәлекле метафоралар: *дин сакчысы* [шунда ук, б. 32]; *дин юлы* [шунда ук, б. 37]; *гыйлем юлы* [шунда ук, б. 31]; *гыйлем казаны* [шунда ук, б. 32];

8) эш яки хәлнең процессы: *кулсыз калдыру, тел тиерү, кулдан киту* [шунда ук, б. 32]; *эш салмау* [шунда ук, б. 33]; *эшнең төбе* [шунда ук, б. 53]; *сүз төбе* [шунда ук, б. 86] һ.б.

Г. Исхакый әсәрләренең теле эпитетларга да бик бай. Автор аларны персонажларның портретын һәм табигать күренешләрен сурәтләгәндә мул файдалана. Әлеге образлы сыйфатлауларның гади һәм катлаулы формалары бар. Эпитетлар, нинди генә булмасыннар, образ тудыруга, вакыйгаларны, күренешләрне җанлы итеп сурәтләүгә, персонажларны индивидуальләштерүгә ярдәм итәләр. Мәсәлән, «Очрашу, яки Гөлгыйзар» хикәясендә: «Ул: “Менә ирләрнең сөйли белмәүләре дә шуннан булырга кирәк. Безнең халык бер дә сөйли белми бит, үз эшеннән бераз сөйли дә тик утыра. Менә сезнең (ул миңа һаман “сез” дия иде) белән кайчаннан бирле сөйлимез, сүз һаман бетми, анлар берлән кая болай сөйләргә? Йә сүзе бетә, бетми икән, начар сүзгә бора, *ләгънәт суккан бер халык* инде”, – диде» [Исхакый, 1988, б. 52]. XX йөз башында татар милләтенә хас булган тискәре сыйфатларны, татар халкының наданлыгын, аларда сөйләм культурасының түбән дәрәҗәдә булуын Г. Исхакый «*ләгънәт суккан халык*» гыйбарәсе аша әйтеп бирә.

Һәр эпитет предметның сыйфатын бер үзенчәлек буенча ачыклый. Мәсәлән: *татлы яшь, ят кеше* [шунда ук, б. 52]. Әлбәттә, яшь татлы, баллы булмый. *Татлы* сүзе бу очракта «сөенечтән елау, сөенеч яше» дигән мәгънәне аңлата. Шуның белән язучы образлылыкка ирешә.

Әдип предметның үзенчәлеген төрле яклап ачыклау өчен, эпитетларны бер-бер артлы, тиңдәш кисәкләр формасында да кулланырга мөмкин. Мәсәлән, «Солдат» хикәясендә Садыйк портреты: «*Ул хәзер авылдагы кыш көне азбар көри торган, җәй буе кырда эшли торган, эшләү берлә ашаудан бүтәнне белми торган, үзенең авылы берлә күрше шәһәрне генә күрә торган, өстеннән һәрвакыт тирес берлә тир исе чыга торган мужик егете түгел иде. Ул хәзер әллә ничә шәһәр күргән, әллә ничә шәһәр күргән кешеләрне күргән солдат Садыйк Әхмәдич иде*» [Исхакый, 1908].

Шушы кечкенә генә бер өзек эчендә күпме эпитет! Һәм ул эпитетлар кечкенә генә караңгы татар авылыннан чыккан тар фикерле Садыйкның характерлы үзенчәлекләрен ачыклауга, алга таба аның күпне күргән, дөньяга үзенең билгеле бер карашы булган Садыйк Әхмәдич булып өлгереп җитүен күрсәтүгә ярдәм итә.

Югарыда күрсәтелгән үзенчәлекләре буенча Г. Исхакый әсәрләрендә кулланылган эпитетларны өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин.

1. Ялгызак эпитетлар: *кәефсез вакытлар, рәхәтсез хәлләр, файдалы гыйлемнәр, шатлыклы гомерләр* («Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер»); *ят кеше, татлы яшь, чибәррәк җир, алсу йөз, кайнар сулыш, көләч йөз, ачык чырай, чибәр теш, яхшы җир, йомшак күңел, нурлы йөз, Казанский Камәр, кадерле сәгать, татлы минут, гүзәл йөз, сатлык кыз, данлыклы вакыт* («Кәләпүшче кыз»); *сәгадәтле минутлар, бетмәс-төкәнмәс сүз, гали эш* («Очрашу, яки Гөлгыйзар»); *татлы тел, әдәпсез сүз, ятыш кыз, төпсез хәбәр* («Бай угълы»); *асыл табыш, суык кан* («Башкорт бәхете»); *йомшак кояш, шәфкатьсез ягъмур* («Мулла бабай»); *кайнар яшь, кайнар кул* («Солдат») һ.б.

2. Тиңдәш кисәкләр формасында килгән эпитетлар: *моңлы, кызарган күренеш* («Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер»); *кадерле, бәһасез яшьлек заманнары; күңелендә туган, төенләнеп торган хиссиятләр; җыйнак кына, сак кына, ашамы-эчеме яхшы гына тереклек итә торган кеше; хәсрәтле, кайгылы кыланышлар; исерек, сасы, җайсыз кешеләр* («Кәләпүшче кыз»); *яшь, бозылмаган димаг; үткен, җазибәле күзләр* («Очрашу, яки Гөлгыйзар»); *моңлы, кайгылы тавышлар* («Бай угълы») һ.б.

3. Җәенке эпитетлар: *көлемсерәп торган кояш* («Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер); *тау кадәр хәсрәт*; *бетмәс-төкәнмәс дәртләр* («Кәләпүшче кыз»); *чибәр генә киенгән мөселман хатыннары; авыздан авызга өзми сөйли торган халык* («Очрашу, яки Гөлгыйзар»); *күңелгә тулмаслык эшләр; мәктәп бусагасына аяк басмаган, китап битенә күз ташламаган, дин белмәгән, дөнья күрмәгән бала; намаздан бушанмый торган, кулыннан тәсбихыны төшерми торган карчык* («Бай угълы»); *иренне яра торган*

*эссе җил; арканы кыздыра торган шәфкатьсез кояш; шатлык уйный торган күз* («Мулла бабай») һ.б.

Г. Исхакый портретларны биргәндә, образларны сурәтләгәндә эпитетларны аеруча еш куллана. Мәсәлән, «Бай угълы» хикәясендәге тегермәнче кызы Бәдрия образы. Ул – акыллы, эш сөючән, тәрбияле, әдәпле, инсафлы, тәүфыйклы, намуслы кыз. Бәдрия эчке дөньясы белән генә түгел, тышкы күренеше белән дә матур, соклангыч кеше итеп бирелә: «*Тегермәнче кызы безнең Фатыйх байларга бик ятыш кыз иде. Атасы-анасы тәрбиясендә генә үскән, сабак укып, эшкә өйрәнеп кенә гомерене үткәргән, әллә нинди назлылыкларга өйрәнмәгән, атасыннан башка ир заты күрмәгән бер кыз, Кәрим өчен җан бирер дәрәҗәгә йетеп, ничек булса да аны шул эштән коткарырга тырышачак иде. Төсе-башы да: зәңгәр күзле, алсу йөзле, кара чәчле, булдыгы шикелле татлы сүзле, йомшак күңелле, гакыллы, әдәпле, инсафлы бер кыз иде. Тирә-якта данлыклы булса да, гакыллылыгы, матурлыгы чаклы чабы китмәгән иде. Дөресте генә, су буйларында, урманлыкларда үскән, матур һавада тәрбия кылынган бер чәчәк иде*» [Исхакый, 1988, б. 137]. Әсәрдә Бәдрия күңелдә яхшы тәэсир калдыра торган уңай образ итеп сурәтләнә. Әлеге өзектән, күренгәнчә, Г. Исхакый логик эпитетларны да, метафорик эпитетларны да яратып куллана: *зәңгәр күз, алсу йөз, кара чәч* һ.б. туры мәгънәсендә генә кулланылып, логик эпитетлар булып саналсалар да, *татлы сүз, йомшак күңел, ятыш кыз* эпитетлары исә, әсәрдә күчерелмә мәгънәдә килеп, метафорик эпитетлар булып торалар.

Әйтеп үтелгәнчә, Г. Исхакый үзенең сәнгатьле прозасында образлы сыйфатлауларның катлаулы төренә дә мөрәҗәгать итә. Аларда эчке мәгънә, образлылык төрле лексик мәгънәдәге сүзләр ярдәмендә белдерелә. Мәсәлән, Г. Исхакыйның үз геройларының йөзен, характерлы сыйфатларын ачу өчен китерелгән эпитетларына игътибар итик. Әдип «Бай угълы» әсәрендәге Фәхри образын түбәндәгечә сурәтли: «*мәктәп бусагасына аяк басмаган, китап битенә күз ташламаган, дин белмәгән, дөнья күрмәгән бала*» [Исхакый, 1988, б. 117]. Әлеге җәенке эпитет аркылы без Фәхринең эчке һәм тышкы дөньясын, аны тәртипсез, укымышсыз, тәҗрибәсез, күңелдә тискәре тәэсир калдыра торган образ итеп күз алдына китерәбез. «Кәләпүшче кыз» хикәясендәге Кәримәнең икенче ирен әдип түбәндәгечә характерлый: *«җыйнак кына, сак кына, ашамы-эчеме яхшы гына тереклек итә торган кеше»* [шунда ук, б. 60]. Әлеге мисалдан аңлашылганча, без аның бай да түгел, ярлы да түгел, уртача хәлле, шул ук вакытта, табигате белән дә уртача холыклы, тыныч, сабыр кеше дип беләбез. Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г. Исхакый үзенең персонажларын сурәтләгәндә, портретларын тасвирлаганда уңай геройларын гел ачык, якты, ә тискәре образларны гел кара буяулар белән генә бирми. Ул аларның һәрберсен дә

гадәти, гап-гади җир кешеләре итеп сурәтли һәм аның эпитетлары да гади сөйләм лексикасындагы сүзләрдән гыйбарәт.

Г. Исхакый әсәрләрендә әйберләрне сурәтләү өчен бер үк төрле эпитетны куллану очраклары да бар. Мәсәлән: *татлы яшь* [Исхакый, 1988, б. 52]; *татлы минут* [шунда ук, б. 70]; *татлы тел* [шунда ук, б. 117]; *йомшак күңел* [шунда ук, б. 69]; *йомшак кояш* [Исхакый, 1995, № 5–6, б. 33] h.б. Әлбәттә, бу эпитетлар нәфис сүз сәнгатен бизәми. Ләкин әдип әлеге сыйфатларның күп мәгънәлелегенә нигезләнә һәм, чыннан да, сәнгатьле сөйләмдә аның эчке мәгънәсе көтелмәгән ягы белән ачылып китә. Г. Исхакый «Кәләпүшче кыз»да Камәрнең әтисен искә төшереп, сагынып елавын *татлы яшь* аша сурәтли. Чөнки Камәр өчен әтисен искә алу бик зур сөенеч. Татлы яшь «сөенеч яше» дигән мәгънәдә килгән. Шул ук әсәрдә әдип Камәрнең яшьлек вакытларын *татлы минут* эпитеты аша тасвирлый. Чөнки фахишәлек юлына баскан Камәр үзенең яшьлеген «*гомеренең татлы минутлары*» итеп искә ала. *Татлы* сүзе бу очракта «иң бәхетле, кадерле, гөнаһсыз» дигән мәгънәне белдерә. «Бай угълы» әсәрендә *татлы (тел)* эпитетын Исхакый болай куллана: *«татлы телләреннән дә әдәпсез сүзләр коела башлаган иде»* [Исхакый, 1988, б. 117]. Әлеге сурәт аша без Кәримнең ямьсез, начар сүзләр сөйли торган, тәмсез телле, әдәпсез малайга әйләнүен күрәбез.

*Йомшак* сүзенең эчке мәгънәсе дә контекст эчендә ачыла: *йомшак күңел* – «нечкә күңел», *йомшак кояш* – «җылы кояш» дигән мәгънәне белдерә.

Г. Исхакыйның үзенеке генә булып исәпләнерлек образлы сыйфатлаулары да бар. Мәсәлән: *көлемсерәп торган кояш* [Исхакый, 1988, б. 43]; *күңелендә тулган, төенләнеп торган хиссиятләр* [шунда ук, б. 54]; *исерек, сасы, җәйсыз кешеләр* [шунда ук, б. 70]; *үткен, җазибәле күзләр* [шунда ук, б. 101]; *иренне яра торган эссе җил; арканы кыздыра торган шәфкатьсез кояш; шәфкатьсез ягъмур* [Исхакый, 1995, № 5–6, б. 33] h.б.

Г. Исхакый әсәрләрендә кулланылган эпитетларның эчке мәгънәсен, образлылык нигезен тагын бик күп мисаллардан табып тикшерергә мөмкин булыр иде. Алда язылганнарга нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: Г. Исхакый метафораларны күбрәк эчке хисләрне сурәтләгәндә кулланса, табигать күренешләрен, пейзаж, портретларны ул төрле лексик-грамматик чаралар ярдәмендә ясалган чагыштыру конструкцияләре, эпитетлар аша тасвирлый.

Китерелгән мисаллардан без Г. Исхакыйның прозада телсурәтләү чараларын мул куллануын, аларны уңышлы файдалана белүен күрдек. Гаяз Исхакый әсәрләрендә сурәтләү чараларының образлы, эмоциональ яңгыравы һәм идеялелеге моны тагын бер кат раслый.

**Әдәбият**

*Губайдуллина (Зиннатуллина) Г.Ф.* Стилистические особенности прозы Г. Исхаки // Языковые и стилистические особенности ранней художественной прозы Гаяза Исхаки: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2001. С. 152–217.

*Исхакый Г.* Бай угълы. Оренбург: М. Кәримов матбагасы, 1903.

*Исхакый Г.* Кәләпүшче кыз. Казан, 1900.

*Исхакый Г.* Солдат. Казан: Хөсәен Әбүзәров кит. нәшр., 1908. 47 б.

*Исхакый Г.* Теләнче кызы. Казан: «Шәрәф» матбагасы, 1907.

*Исхакый Г.* Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер. 1899.

*Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 томда. Татар. кит. нәшр., 1998. Т. 1. 400 б.

*Исхакый Г.* Мулла бабай // Мирас, 1994–1996.

*Поварисов С.Ш.* Мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 124 б.

*Хаков В.Х.* История татарского литературного языка. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1999. 326 с.

***Зиннәтуллина Гөлзара Фазылрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан милли тикшеренү техника университеты доценты*

УДК 82-94

***Р.Г. Галләм***

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ – ЯУШИРМӘ АВЫЛЫНЫҢ УКАЗЛЫ МУЛЛАСЫ
## (Гаяз Исхакый биографиясе эзләреннән)

Статья посвящена жизнедеятельности известного татарского писателя и общественного деятеля Гаяза Исхаки (Мухамметгаяза Исхакова) в самом начале XX века. Публикуются документы из архивного дела, обнаруженного в фондах Государственного архива Республики Татарстан, датированного 1903 годом, под заглавием «Об определении крестьянина дер. Лашманкиной Бугульминского уезда Самарской губернии Мухаметгаяза Гилязетдинова Искакова имамом к соборной мечети дер. Кутлушкиной Чистопольского уезда», которые содержат в себе новые сведения по его родословной биографии.

**Ключевые слова**: Гаяз Исхаки (Мухамметгаяз Исхаков), Гилязетдин Исхаков, татарское духовенство на рубеже XIX–XX вв., Казанская губерния, Чистопольский уезд, дер. Кутлушкино (Яуширма), Самарская губерния, Бугульминский уезд, дер. Лашманкино.

Соңгы дистә елларда күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы Гаяз Исхакыйның (Мөхәммәтгаяз Гыйлаҗетдин улы Исхаковның) тормыш юлы, сәяси-иҗтимагый, әдәби эшчәнлеге шактый дәрәҗәдә тәфсилле итеп өйрәнелеп, аның әсәрләренең 15 томлык басмасы чыкса да, төрле мирасханәләрдә, шәхси тупланмаларда аның тәрҗемәи хәленә, эшчәнлегенә кагылышлы яңа документлар әледән-әлегә табылып тора. Мөгаен, Татарстан дәүләт архивы фондларында сакланып, үзләрендә Гаяз Исхакыйның тәрҗемәи хәленә, нәсел шәҗәрәсенә, XX гасыр башында дини, иҗтимагый эшчәнлегенә нисбәтле берникадәрле мәгълүмат туплаган архив эшләре дә шундыйлар рәтендә карала аладыр [Татарстан милли архивы, 2 нче фонд, 2 нче тасв., 6626, 6838,7363 архив эшләре һ.б.]. Бер яктан, алар күренекле язучының, җәмәгать эшлеклесенең XX гасыр башындагы тормыш елъязмасына, аның аерым сәхифәләренә мәгълүм дәрәҗәдә төгәллек, ачыклык кертергә мөмкинлек бирсә, икенче яктан, аның шул чордагы тәрҗемәи хәленә бәйле яңа сораулар да куя. Без биредә ул архив эшләренә тулы анализ ясау максатын куймыйча, алардагы мәгълүматны берникадәр барлап, шулардан берсендәге документларны, түкми-чәчми, Г. Исхакыйның тормыш юлын, иҗтын өйрәнүче галимнәр, аның белән кызыксынучы киң катлау укучылар карамагына җиткерергә булдык.

Татарстан дәүләт архивы фондларында сакланып, 1903 елга караган бу архив эше «Самара губернасы Бөгелмә өязенең Лашман авылы игенчесе Мөхәммәтгаяз Гыйлаҗетдин

улы Исхаковны Казан губернасы Чистай өязе Яуширмә авылының җәмигъ мәчетенә имам итеп билгеләү турында» дип атала [ТМА, 2 нче фонд, 2 нче тасв., 6838 нче архив эше]. 1903 елның 4–31 нче марты (яңа стиль белән 14 марты – 10 апреле) белән даталанып, 18 архив битеннән (кәгазеннән) торган бу эштә Г. Исхакыйны Чистай өязе Яуширмә авылына указлы имам, андагы беренче җәмигъ мәчетенә икенче мулла итеп билгеләүгә нисбәтле, 11 документ теркәлгән (алар укучылар карамагына тәкъдим ителә). Алардан тыш, бу архив эшендә, гадәтенчә, стандарт калыпка салынган «мулла антының» басма тексты да урын алган (17 нче кәг.). Ул чорда, үз вазифасына керешер алдыннан, патшага, дәүләткә турылыклы хезмәт итү турында андый антны указлы муллага һәр дәгъватчы бирергә тиеш булган.

Документлардан күренгәнчә, Гаяз Исхакый, дөрестән дә, 1878 елның 10 февралендә (яңа стиль белән 1878 елның 20 февралендә) туа. 1902 елның 3 августыннан алып, 1902 елның май аена тикле Казандагы Татар укытучылар мәктәбендә укый. Бу уку йортын бетерү турындагы таныклыгына караганда (№ 337), ул аны шактый уңышлы тәмамлый. Чөнки «3» ле куелган арифметика белән геометриядән кала, аның таныклыкта күрсәтелгән барлык предметлар буенча билгеләре «5» ле белән «4» ле. Аталган предметтан кала, мәктәптә рус теле, педагогика, тарих һәм география, табигый фәннәр («естествознание»), матур язу һәм сызым буенча дәресләр бирелгән. Шулай ук, анда укучылар үзләре дә сынамыш дәресләр биргән, ягъни, укыту-мөгаллимлек эше буенча практика узган. Аннан тыш, монда Гаяз Исхакый китап төпләү, столярлык һөнәрләрен дә үзләштерә [аның бу уку йортында укуы турында өстәмә мәгълүматны кара: Хәсәнов, б. 7].

Гаяз Исхакыйның 15 томлык әсәрләре тупланмасында бирелгән биографиясе буенча, бу мәктәпне тәмамлаганнан соң Г. Исхакый Ырымбурдагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытучы булып эшләп ала. Шуннан соң, 1903 елның җәендә, янәдән Казанга кайтып төшә, университетка әзерләнә башлый. Әмма «әтисе авырып китү сәбәпле аны туган авылына чакырып кайтаралар һәм халыктан җыйган приговор нигезендә мулла итеп куялар» [Хәсәнов, б. 8]. Тик без карап тикшергән архив эшләрендәге документлар бу нәтиҗәгә берникадәр төгәллек кертүне сорый. Мәсәлән, Чистай өязе полиция идарәсенең Казан губерна идарәсенә 1903 елның 29 апрелендә (яңа стиль белән 1903 елның 9 маенда) юлланган «Рапортында» Чистай өязе Яуширмә авылының беренче җәмигъ мәчетенә икенче мулла итеп билгеләнгән Мөхәммәтгаяз Гыйлаҗетдин улы Исхаков «хәзерге вакытта Өфе шәһәрендә, татар мәктәбе укытучысы вазифасында яши һәм Яуширмә авылына быелның 15 июнендә кайтачак», дип искәртелә (9 нчы документны кара). Димәк ки, ул инде бу вакытта Яуширмә авылына мулла итеп билгеләнгән

булган. Аның җәен авылга да Казаннан түгел, ә Өфе каласыннан кайтып төшкән булуы ихтимал. Һәрхәлдә, архив документы шуңа ишарәли сыман.

Чынлыкта 25 яшьлек Гаяз Исхакыйның Яуширмә авылына, андагы беренче җәмигъ мәчетенә икенче мулла итеп Казан губерна идарәсенең карары белән 1903 елның 31 мартында (яңа стиль белән 1903 елның 10 апрелендә), ягъни, шул елның язында ук билгеләнүе ачыклана. 1903 елның 17 апрелендә (яңа стиль белән 27 апрелендә) аңа указлы мулла таныклыклыгы («мулла таныклыгы») бирелә (№ 1009) [түбәндәге 8, 10, 11 нче документларны кара; ТМА, 2 нче фонд, 2 нче тасв., 7363 нче архив эше, 7–8 кәг.].

Гомумән алганда, Яуширмә авылы җәмәгатенең ул вакытта 22 яшьлек Гаяз Исхакыйны әтисе имамлык иткән җәмигъ мәчетенә мулла итеп тәгаенләү турындагы беренче «Приговоры» (карары) әле 1901 елның гыйнварында ук кабул ителә. Тик бу вакытта Гаяз Исхакыйның Казандагы Татар укытучылар мәктәбендә укуы сәбәпле, ул вакытлыча Кызылъяр волосте идарәсендә саклана. Мәхәллә җәмәгатенең бу турыдагы икенче бер «Приговоры» 1902 елның 8 июненә (яңа стиль белән 18 июненә) карый [3 нче документны кара; ТМА, 2 нче фонд, 2 нче тасв., 6626 нчы архив эше, 25–27 кәг.].

Бу урында шуны да әйтеп узырга кирәк – патша Россиясе шартларында указлы мулла таныклыгын алу, гомумән, җиңел эшләрдән булмый. Беренчедән, моның өчен, махсус уку йортын (мәдрәсә) тәмамларга, таныклыкка дәгъвачының дини эшчәнлеккә әзерлек дәрәҗәсен билгеләүгә нисбәтле, Ырымбурдагы (соңрак Өфедәге) Диния нәзарәтенең күренекле руханиларыннан торган комиссия каршында имтихан тотырга кирәк булса, икенчедән, бу эш төрле дәрәҗәдәге хакимият органнарының, муллаларның эшчәнлеген даими күзәтеп торган полиция идарәсенең, шулай ук, урындагы авыл җәмәгатьләренең – дини мәхәлләләрнең мәсьәләне үзара килештерүенә нисбәтле көчле бюрократия белән бәйле була. Бу уңайдан, Гаяз Исхакыйны муллалыкка билгеләү турындагы архив эше дә моның XIX–XX гасырлар чигендәге тәртибен күзалларга мөмкинлек бирә («мулла анты»н да кертеп, анда 12 документ теркәлгән).

Иң мөһим шартларның берсе булып муллалыкка дәгъватчыларның патшага, дәүләт хакимиятенә карата сәяси тугрылыгы торган. Шунлыктан, аларның «яхшы холыклы», теге яки бу чуалышларда катнашмавы турындагы искәрмәләр мәхәлләләргә мулла билгеләүгә нисбәтле архив эшләрендә документтан документка кабатланып килә. Гаяз Исхакыйга бәйле очракта да, аның «яхшы холыклы» булуы, 1897 елда патша Россиясендә уздырылган халык санын исәпкә алуга нисбәтле («Первая всеобщая перепись населения») булып узган соңгы игенче чуалышларында катнашмавы турында искәртелә (түбәндәге 1, 6, 8 нче документларны кара).

Эш шунда ки, патша Россиясендә ике дистә чамасы ел саен кабатланып торган халык санын исәпкә алулар гасырлар буена дәүләтнең милли, дини изүенә дучар булып яшәгән татар, мөселман игенчеләрендә зур шикшөбһә тудырган. Халык санын 1897 елгы исәпкә алу барышында да Урта Идел буенда (шул исәптән Чистай өязендә дә) игенчеләрнең зур чуалышлары булып уза. Шуңлыктан, аларның яшь Гаяз Исхакыйны мулла итеп билгеләүгә бәйле документларда катлы-кабат искә алынуы гаҗәп түгел.

Гаяз Исхакыйны Яуширмә авылы мәчетенә мулла итеп билгеләү турындагы архив эшенә ул вакытта Самара губернасының Бөгелмә өязенә караган Лашман авылы җәмгатенең Гаяз Исхакыйны авыл игенчеләре исемлегеннән чыгару турындагы 1902 елгы «Приговоры» да теркәлгән. Ул шул елның 24 мартында кабул ителгән (5 нче документны кара). Димәк, үзе анда яшәмәсә дә, күрсәтелгән вакыткача Гаяз Исхакый Лашман авылы игенчеләре исемлегендә торган. Әлбәттә, моны очраклы хәл дип әйтеп булмый. Чөнки аның әтисе, Гыйлаҗетдин мулла, тумышы белән шушы авылдан була. «Унын бабасы [әтисе] Исхак хәзрәт тә имамдыр. Уның бабасы Хәмзә хәзрәт тә, вә аның бабасы Сөбханколый хәзрәт тә, вә аның бабасы Бакый хәзрәт тә имамлардыр», дип яза нәсел агачы турында Гаяз Исхакый үзенең «Тәрҗемәи хәлем»дә [Исхакый, б. 13].

Гаяз Исхакыйның мулла итеп Яуширмә авылына билгеләнүе дә табигый. Беренчедән, ул Гаяз Исхакыйның туган авылы, икенчедән, монда аның әтисе Гыйлаҗетдин мулла Исхаков 29 ел буена диярлек (1873–1902 елларда) имам булып тора (ачыклангaнча, аңа мулла таныклыгы 1873 елның 10 мартында бирелгән була, № 2073) [ТМА, 2 нче фонд, 2 нче тасв., 6626 нчы архив эше, 6, 23 нче кәг.].

«Анам остазбикә Камәрия дә Мөслим авылының Габделвәли хәзрәт илә Махфузә остазбикә кызыдыр вә ундүрт бәтына [буынына] кадәр бабалары-аннәләре хуҗалык япарак, аһалийә хедмәт идән голяма зөмрәсендән. Казан сокут итдеге вакыт [Казан алынган вакыт] Кырымдан Кырым Шаһзадәләре идарәсендән Казан[г]а ярдәм өчен гәлән вә халык миянында «Чура батыр» хикәясенә мәүзугъ тәшкил идән гиранилардандыр», дип яза Гаяз Исхакый әнисе, аның нәсел шәҗәрәсе турында [Исхакый, б. 13].

Гыйлаҗетдин мулла үзе 1838 елгы булган булса кирәк. Чөнки, документлардан күренгәнчә, 1901 елның сентябрендә аңа 63 яшь була [ТМА, 2 нче фонд, 2 нче тасв., 6626 нчы архив эше, 15 нче кәг.]. Дөрес, ул имамлык иткән соңгы елларда аның белән мәзин Сәхабетдин Хөснетдинов арасында низаг килеп чыга (ул мәчеткә азанчы итеп 1883 елның 13 июлендә билгеләнгән була). Соңгысы 1901 елның язында хәтта Гыйлаҗетдин мулла өстеннән Өфедәге Диния нәзарәтенә шикаять тә юллый. Имеш, картайган Гыйлаҗетдин мулла, күзләре күрмәү сәбәпле,

мәхәлләнең метрикә кенәгәләрен тиешенчә тутырып бармый икән.

Дәүләт, Диния нәзарәте күзлегеннән караганда, бу зур кимчелек була. Чөнки ул вакытларда метрикә кенәгәләрен тиешенчә, елдан-елга тутырып бару урындагы муллаларның төп вазифаларынан берсе була. Хәтта моның өчен алар дәүләттән билгеле бер күләмдә акча да алып торганнар. Метрикә кенәгәләренә исә мәхәлләдә ел дәвамында туучыларны һәм вафат булучыларны, никахлашучы һәм аерылушучы парларларны елдан елга тутырып барганнар. Моның өчен Диния нәзарәте урындагы муллаларны кирәкле әсбаплар белән дә тәэмин итеп торган...

Шикаять буенча тикшерү эше башлана. Гыйлаҗетдин мулла мәхәлләдә метрикә язуларын алып баруга бәйле ачыкланган кайбер кимчелекләрне үз вакытында аның бу эшне мәзингә йөкләп тә, соңгысының аның сүзләрен тыңламавы, мәзиннең мәчеттә Гыйләҗетдин мулла урынына үзенең имам буласы килүе белән аңлата.

Бу вакытта Гыйлаҗетдин мулланың күзләре, дөрестән дә, инде начар күрә башлаган була. Кайчандыр кичергән трахома авыруының бер нәтиҗәсе буларак, аның сул күзе кибә, бөтенләй диярлек күрми, уң күзе дә томалана. Чистай өязе врачы аның күрү сәләтен «1 аршын (71,1 см) ераклыктан бармакларын саный алмас дәрәҗәдә», дип бәяли. Күрәсең, мәзин бу хәлдән үз максатларында файдаланып калырга була. Аны бу ямьсез адымга мәхәллә җәмәгатенең яшь Гаяз Исхакыйны әтисе урынына мулла итеп билгеләү турында 1901 елның гыйнвар аенда кабул ителгән «Приговоры» (карары) да этәргән булса кирәк. Ничек кенә булмасын, карт Гыйлаҗетдин мулла авыру булганлыктан, ә яшь мулла, аның улы Гаяз Исхакый, әле авылга кайтып җитмәгәнлектән, мәзин хәрәкәт итәргә була. Үз чиратында, Уфадагы Диния нәзарәте да, Гыйлаҗетдин мулланың сәламәтлеген исәпкә алып, аны имамлык вазифсыннан читләштерергә карар кыла. Тик авыл җәмәгате, бу мәсьәләдә бердәм диярлек булып, мәзинне түгел, Гыйлаҗетдин мулланы яклап чыга. Аны үз вазифасында калдыруны сорап авыл җәмәгате 1901 елның ахырында Казан губерна идарәсенә юллаган ике гарызнамәдә дә Гыйлаҗетдин мулла мәхәллә халкына озак еллар буена турылыклы хезмәт иткән, намуслы, диндар шәхес буларак бәяләнә. Шул ук вакытта, документларда Сәхабетдин мәзиннең сәүдә эшләре алып баруы, шул сәбәпле, еш кына мәхәлләне калдырып, авылдан озак вакытларга югалып торуы, Гыйлаҗетдин мулланы тыңламыйча, үзбашлы эш йөртүе бәян ителә.

Тик, күрәсең, болар барысы да ярдәм итми. 1901 елда авылда икенче мәчет тә ачылуга карамастан, шул елның ноябрь аенда Гыйлаҗетдин мулладан мәхәлләнең метрикә кенәгәләре тартып алына [ТМА, 2 нче фонд, 2 нче тасв., 6626 нчы архив эше, 1–30 нчы кәг.]. Берникадәрле вакыт үзара тартыштан соң, күрәсең, 1902 елның гыйнварыннан башлап, мәчеттә мулла

вазифаларын элеккеге мәзин (азанчы) Сәхабетдин Хөсәенов башкара башлый. Һәрхәлдә, Гыйлаҗетдин мулланы вазифасыннан алуга багышланган эш 1902 елның 21 гыйнварында ябыла. Соңрак Гаяз Исхакыйга мулла таныклыгын бирү өчен кирәкле, мәхәлләдә сакланучы метрикә кенәгәләреннән алып тутырылган, 1903 елның 3 феврале белән билгеләнгән метрикә белешмәсен дә Кызылъяр волосте идарәсенә мулла Сәхабетдин Хөсәенов язып тапшыра (түбәндәге 7 нче документны кара). Бәян ителгән хәлләрдән соң ел ярым чамасы вакыт узгач, этисе имамлык иткән беренче җәмигъ мәчетенә икенче мулла булып, авылга 25 яшьлек Гаяз Исхакый кайтып төшә. Аңарчы мәчеттә икенче мулла вазифасын Вафа Әлмөхәммәтов дигән кеше башкарып килә (3 нче документны кара).

Тик Гаяз Исхакыйның авылда муллалык итү чоры озакка бармый. Бу хакта аның әсәрләренең 15 томлык басмасында урын алган биографиясендә «ул анда озакка калмый, бер елдан соң муллалыгын ташлап, яңадан Казанга китә, сәяәт, иҗтимагый тормыш дәрьясына ташлана» диелә [Хәсәнов, б. 8]. Монда да берникадәр төгәллек кертергә кирәк. Беренчедән, ул Яуширмә авылында үзенең муллалык вазифаларын 1903 елның җәй башыннан алып, 1905 елның ноябрь аенача, ягъни, ике ел ярым диярлек башкара. Икенчедән, 27 яшьлек Гаяз Исхакый муллалык вазифасын һич тә ихтыярый, үз теләге белән «ташлап» китми. Авылдан чыгып китергә аны 1905 елның ноябрь ае башында (яңа стиль белән ноябрь уртасында) булган гадәттән тыш бер вакыйга мәҗбүр итә.

Эш болайрак була: 1905 елның ноябрь ае башында Гаяз Исхакый күршедәге Дүртөйле (русча «Четыре Двора») дигән татар авылына килеп (ул вакытта бу авыл Чистай өязенең Мөслим волостена караган була), авыл халкын якындагы рус алпавыты Толстойның утарын туздырырга, җирләрен тартып алырга өнди. «Электә ул җирләр безнеке булган, – дип аңлата ул җыелган халыкка, – шуңа ике арада генераль ызан да юк». Документ эчтәлегенә караганда, ахыр чиктә, авыл картлары Гаяз Исхакыйны авылдан куып җибәрә. Әмма Гаяз Исхакый чыгышыннан рухланган авыл яшьләре, коткыга бирелеп, алпавыт Толстой кырыннан берничә олау печәнне авылга кайтарып аударалар. «Бу эшләрдән авыл халкына бәла-каза чыкмагае» дип борчылган авыл картлары аларны алдагы хәрәкәтләрдән туктата. Печәнне киредән үз урынына, алпавыт Толстой кырына кайтарталар.

Бу әллә ни зурга китмәгән вакыйга, бәлки, шуның белән төгәлләнер дә иде. Әмма Дүртөйле авылы старостасы Рәхмәтулла Мөхәммәдъяров, йөзбашы Мөхәммәткамал Мөхәммәтшин, Дүртөйле авылы игенчеләре Миңнегалим Мөхәммәтшин, Миңнегалим Әхмәтшин һәм Камалетдин Вахитов, шул хәлләрне бәян итеп, 1905 елның 25 ноябрендә Казан губерна идарәсенә хат (гариза) юллыйлар. Тикшерү

башлана. Менә шунда инде Гаяз Исхакый авылдан чыгып китәргә мәҗбүр була.

Әлбәттә, бу вакыйгага патша Россиясендә XX гасыр башында күзәтелгән гомуми инкыйлаби хәрәкәтнең, сыйнфый чуалышларның мәгълүм дәрәҗәдә йогынтысы булмый калмаган. Кулга алу максаты белән, полиция Гаяз Исхакыйны эзләргә керешә, тик тота алмый. 1905 елның 21 декабренә караган бер хәбәр (донесение) буенча, мәсәлән, ул Казанда яши икән, имеш, аның хатыны анда «Царьград» дигән хәрчәүнә дә тота икән... Ахыр чиктә, Казан губерна идарәсенең 1906 елның 21 гыйнварында кабул ителгән карары буенча (№ 453), Гаяз Исхакый эшеннән (муллалык вазифасыннан) алына, үзе табылган хәлдә, аннан мулла таныклыгы да тартып алынып, Казан губерна идарәсенә тапшырылырга тиеш була [ТМА, 2 нче фонд, 2 нче тасв., 7363 нче архив эше, 1–12 нче кәг.].

Гаяз Исхакыйның муллалык эшчәнлеге әнә шулай төгәлләнә. Аның биографиясендә яңа чор башлана.

Йомгаклап, Гаяз Исхакыйның биографиясенә нисбәтле безнең берникадәрле өстәмәләрне, төзәтмәләрне, искәрмәләрне кабаттан искәртеп узыйк:

1. Архив документларына караганда, Гаяз Исхакыйның әтисе, Гыйлаҗетдин Исхаков, тумышы белән 1838 елгы булган булса кирәк (чөнки 1901 елның сентябрендә аңа 63 яшь була).

2. Ул Казан губерна идарәсенең 1873 елның 10 нчы марты карары буенча (мулла таныклыгы № 2073) Чистай өязе Яуширмә авылының җәмигъ мәчетендә мулла һәм мөдәррис вазифаларын башкара башлап, анда 1901 елның ахырына – 1902 елның башына кадәрле – 29 ел диярлек (!) имамлык итә.

3. Архив документларының берсендә Гаяз Исхакыйның Яуширмә авылына муллалык итәргә, моңарчы бәян ителгәнчә, Казаннан түгел, ә бәлки Өфе каласыннан, андагы татар мәктәбендә укыткан җиреннән кайтачагы искәртелә (түбәндәге 9 нчы документны кара). Бу хәбәр – Г. Исхакый биографиясенә нисбәтле бер «ак тап».

4. Гаяз Исхакый, аның әсәрләренең 15 томлыгында урын алган биографиясендә шәрехләнгәнчә, 1903 елның җәеннән башлап, бер ел дәвамында түгел, ә бәлки 1903 елның 31 мартыннан алып, 1906 елның 26 нчы гыйнварына тикле, ягъни, 3 елга якын диярлек вакыт, рәсми рәвештә, Яуширмә авылының беренче җәмигъ мәчете мулласы булып тора. Гамәлдә исә аның авылда (мәхәлләдә) торып муллалык итү чоры 1903 елның җәй башы – 1905 елның ноябрь ае белән чикләнә.

5. Ул авылдан үзе теләп, «бер елдан соң муллалыгын ташлап» китми. Моңа аны өченче ел муллалык итү чорында – 1905 елның ноябрь ае башында Яуширмә төбәгендә булып узган сәяси характердагы вакыйга этәрә.

6. Гаяз Исхакый сәясәт, иҗтимагый көрәш дәрьясына да «муллалыгын ташлап» Казанга күченгәч түгел, ә бәлки шул Яуширмә авылында муллалык

иткән чорында ук ташлана. Бәян ителгән вакыйга – моның бер ачык дәлиле.

Мәкалә башында берникадәр шәрехләнгәнчә, Гаяз Исхакыйны 1903 елда Яуширмә авылындагы 1 нче җәмигъ мәчетенә мулла итеп билгеләүгә нисбәтле тәкъдим ителгән архив документларына кагылышлы, тагын шуны әйтеп узыйк: басмага әзерләгәндә, XX гасыр башы документларының оригиналдагы орфография, пунктуация, стилистика үзенчәлекләре, мөмкин булганча, тулы итеп сакланды. Аларның эчтәлегенә, архив эшендә бирелешләренә бәйле, безнең искәрмәләр, аңлатмалар туры почмаклы җәяләр эчендә, курсив белән бирелде. Ә хәзер документларның үзләренә мөрәҗәгать итик [ТМА, 2 нче фонд, 2 нче тасв., 6838 нче архив эше, 18 кәг.]:

**1 нче документ**

В Казанское Губернское Правление

Чистопольского Уездного
Полицейского Управления

**Рапорт.**

Полицейское Управление имеет честь представить на распоряжение Губернского Правления отношение Земского Начальника I участка Чистопольского уезда от 23 сего Февраля за № 91 вместе с приговором крестьян деревни Кутлушкиной прихожан 1-ой соборной мечети об избрании на должность муллы к означенной мечети крестьянина Самарской губернии Бугульминского уезда, Верхне-Кармальской волости, дер. Лашманкиной Мухаметгаяза Гилязетдинова Искакова и поименованными в отношении за № 91 документами и донести, что Искаков поведения хорошего, под судом и следствием не был и ныне не состоит и в татарских волнениях во время всеобщей народной переписи *[1897 елгы]* не участвовал.

Помощник исправника *[имза укылмый]*.

Секретарь Степанов.

№ 430.

Февраля 27 дня 1903 г.

Отделение I, стол I.

*[**Документка искәрмә:** архив эшенең 1 нче кәгазендәге кара язу белән язылган документның басма, трафарет башламы өлешенә Казан губернасы идарәсенең 1903 елның 1 нче марты белән билгеләнгән овал рәвешле, шәмәхә мөһере сугылган. Шул ук турыда документ текстына карата кыеклап куелган «№ 68», архив кәгазенең өске, сул почмагында – 490 саннары укыла].*

## 2 нче документ

№ 430
В Чистопольское Уездное Полицейское Управление

При сем имею честь препроводить на распоряжение Полицейского Управления приговор крестьян дер. Кутлушкиной прихожан I соборной мечети от 8 Июня 1902 г. за номером 1-м о принятии в муллы крестьянина Самарской губернии, Бугульминского уезда, Верхне-Кармальской волости, дер. Лашманкиной Мухаметгаяса Гилязетдинова Искакова и принадлежащие ему документы: 1, Свидетельство Бугульминского Уездного по воинской повинности Присутствия от 21 Января с/г. *[«сего года»]* за № 30 об исполнении Искаковым воинской повинности, 2, Копию с свидетельства за № 337, выданного 29 Мая 1902 г. Казанской Татарской Учительской Школой об испытании, 3, Свидетельство Оренбургского Магометанского Духовного Собрания от 16 Июня 1902 г. за № 3568 в знании Искаковым магометанской религии, 4, Увольнительный приговор крестьян дер. Лашманкиной от 24 Марта 1903 г. за № 17, 5, Удостоверение Верхне-Кармальского Волостного Правления от 1 Декабря 1902 г. за № 2213 о несудимости Искакова и о неучастии в татарских волнениях *[1897 нче елгы]* и 6, метрическую справку от 2 Февраля с. г. за № 5 о рождении Искакова.

Земский Начальник 1 уч. *[имза; аны «Еремин» яисә «Ермилин» дип укырга була]*.

*[**Документка искәрмә:** 2 нче кәгазьдәге бу документ кара язу белән язылып, ул башлам өлешендә Чистай өязе полиция идарәсенең 1903 елның 26 феврале белән даталанган овал рәвешле, шәмәхә мөһере белән беркетелгән. Шулай ук, архив кәгазенең сул кырына Казан губернасы Чистай өязе земство идарәсенең беренче участогы башлыгының зур дүртпочмак конфигурациясендәге мөһер-штампы да сугылган. 1903 елның 23 феврале белән даталанып, «с. Красный Яр» дип тә язылган бу мөһер-штампның канцелярия номеры 91]*.

## 3 нче документ

1902 года июня 8 дня, мы, нижеподписавшиеся крестьяне Казанской губернии, Чистопольского уезда, Красноярской волости, деревни Кутлушкиной, прихожане 1-ой соборной мечети, заключающие в себе 1943 души и 202 домохозяина, имеющих право голоса, быв сего числа в общем собрании на приходском сходе в присутствии местных наших Волостного Старшины Ефима Емелина и Сельского Старосты Зялалетдина Шарафутдинова в числе 176 человек, т. е. не менее 2/3 имеющих право голоса на сходе, где имели суждение о том, что при нашей мечети Правительством разрешено иметь два муллы, но так как один из них, Вафа Альмухаметов, от занимаемой им должности ввиду перехода на другую отказался и часть прихода

этой мечети осталась без муллы, то нам является необходимым вновь назначить к своему приходу второго муллу, какую должность занять изъявил желание крестьянин Самарской губерниии Бугульминского уезда Вехнекармалинской волости дер. Лашманкиной Мухамет-Гаяз Гилязетдинов Исхаков 24-х лет. Имея ввиду, что изъявивший желание на должность муллы Исхаков, как видно из представленных им документов, а так равно и лично нам известно, поведения хорошего, под судом и следствием не состоял и не состоит, и назначению своему по образованию вполне соответствует, поэтому признавая желание Исхакова заслуживающим удовлетворения, с общего всех нас согласия приговором сим постановили *[«постановили» сүзе эре хәрефләр белән язылган]:* крестьянина Самарской губернии Бугульминского уезда Верхнекармалинской волости деревни Лашманкиной Мухамет Гаяза Гилязетдинова Исхакова избрать на должность муллы при мечети в нашем приходе и настоящий приговор, для утверждения Исхакова в этой должности на предмет представления в Губернское Правление, передать в местное наше Волостное Правление, в том и подписуемся: 1, Фатхутдин Файзутдинов 2, Хуснутдин Губайдуллин 3, Аглиулла Гизетуллин 4, Сафа Камалетдинов 5, Галим Сайфутдинов 6, Шарафутдин Фахрутдинов 7, Гафиятулла Сибигатуллин 8, Миннивалей Сабиров 9, Хасан Салахутдинов 10, Сулейман Багаутдинов 11, Садретдин Багаутдинов 12, Зиганьша Ибрагимов 13, Зариф Ибрагимов 14, Миньшарып Гизетуллин 15, Зямалетдин Садретдинов 16, Гайнятулла Мрадымов 17, Фатхутдин Мифтахутдинов 18, Муртаза Валеев 19, Нафига Бядигин *[хатын-кыз?]* 20, Сиразетдин Сайфутдинов 21, Хуснутдин Хакимов 22, Махмут Фахрутдинов 23, Салахутдин Хакимов 24, Миннигуль Файзутдинов *[хатын-кыз?]* 25, Саяр Юсупов 26, Нурутдин Фасахутдинов 27, Закир Мухамедьяров 28, Хатып Фасхутдинов 29, Гата Мухаметаминев 30, Миннигадый Валиуллин 31, Загидулла Галиуллин 32, Валей Мухарлямов 33, Закир Ситдиков 34, Гилязетдин Мифтахутдинов 35, Карим Натеев 36, Миндубай Вахитов 37, Низамутдин Мязитов 38, Садретдин Хакимов 39, Шарафутдин Хамитов 40, Салахутдин Фахрутдинов 41, Хайбулла Хисьметуллин 42, Валиулла Хисьметуллин 43, Ахметсафа Бикбов 44, Шигабутдин Нафеев 45, Ахмет Мухамедияров 46, Нургалей Фатхутдинов 47, Низамутдин Камалетдинов, 48, Сафа Кабиров 49, Абдрахман Фатхутдинов 50, Нурулла Сабиров 51, Давлетша Ахметшин 52, Нураней Ризванов 53, Гатаулла Ризванов 54, Мингазетдин Вафин, 55, Зиганьша Ахметшин… *[шул рәвешле, барлыгы 173 кеше саналып кителә]*…170, Фатхутдин Кабиров 171, Шарафутдин Багаутдинов 172, Ганиятулла Кабиров 173, Губайдулла Давлетшин – не грамотные, а за них, не грамотных, по личному доверию и за себя расписались 174, Гата Ахмедзянов 175, Хайдар Юсупов 176, Шарафутдин Багаутдинов.

*[174–175 номерлары текст сүзләре арасына, юл өстенә өстәп язылган; гомумән, исемлектә бу номерлар белән күрсәтелгән соңгы өч*

*кешенең исеме икенче бер кул белән, документның төп текстыннан аермалы буларак, тигезсез, төзек булмаган язу белән «тырнап» язылган].*

На сходе присутствовали и правильность сего приговора свидетельствуем.

Волостной Старшина *[имзасыз].*

Сельский Староста Зял. Шарафутдинов *[имза Яуширмә авылы старостасының сигез кырлы, шәмәхә мөһере белән беркетелгән].*

1903 года Февраля 1 дня *[баштарак язылган «Того же числа» сүзләре сызылып, алар юл өстендә, кызгылт язу белән, «1903 года Февраля 1 дня» дип төзәтелгән]* настоящий приговор в книгу приговоров Кутлушкинского сельского общества подлинником № 1 записан, что Красноярское Волостное Правление удостоверяет подлинность с приложением именной печти.

Волостной Старшина Емелин.

*[Волость старшинасы имзасы астына, архив кәгазенең сул кырына, Чистай өязе Кызылъяр волосте идарәсенең түгәрәк, шәмәхә мөһере сугылган].*

Волостной писарь *[имзасы укылмый].*

*[**Документка искәрмә:** 3–5 нче кәгазьләрдәге кулдан язып тутырылган бу алхәбәрсез документ – Казан губернасы Чистай өязе Яуширмә авылы җәмәгатенең 1902 нче елның 8 нче июненә (яңа стиль белән – 18 нче июненә) караган авыл җыены «Приговоры». Ул кара, вак, каллиграфик язу белән язылган. 3 нче кәгазьдә, документ башламының югары, сул почмагына, кыеклап, «Утверждаю» дигән резолюция салынган. Аның имзасы укылмый, хакимияттәге вазифасы да күрсәтелмәгән].*

## 4 нче документ

Копия

Казанский Учебный Округ

Свидетельство

Предъявитель сего Мухамед-Гаяз Исхаков, сын крестьянина, родившийся 10 февраля тысяча восемьсот семьдесят восьмого года, обучался в Казанской татарской учительской школе на собственный счет с 3 Августа 1898 года по *[көне куелмаган]* Мая 1902 года и окончил полный курс положенных уставом учебных предметов. Во все время учения был поведения отличного и в преподаваемых предметах оказал успехи:

В Магометанском вероучении отличные (5) пять

– Педагогике хорошие (4 четыре)

– Русском языке хорошие (4 четыре)

– Арифметике и Геометрии удовлетворительные (3 три)

– Истории и Географии (русской) отличные (5 пять)

– Естествознании отличные (5 пять)

– Чистописании и черчении хорошие (4 четыре)

– Практических занятиях по преподаванию хорошие (4 четыре)

Кроме того, обучался гимнастике и ремеслам: переплетному и столярному. Окончил полный курс учения в татарской учительской школе, он – Исхаков, на основании ст. 20 п. 4 и ст. 27 Высочайше утвержденного 27 марта 1872 г. Положения о татарских учительских школах, удостоен Педагогическим Советом Казанской татарской учительской школы звания учителя начального татарского училища. Как успешно окончивший курс учения в Казанской татарской учительской школе, он – Исхаков, по отправлению воинской повинности пользуется льготами, предоставленными второму разряду по образованию. Лица, окончившие курс учения в татарских учительских школах, на основании 2605 и 1585 ст. 1 ч. IX т. Свода законов, изд. 1893 г., пользуются относительно поступления в гражданскую службу правами, указанными в Уставе о службе по определению от Правительства для лиц, окончивших курс учения в прогимназиях.

В удостоверение сего и выдано ему, Исхакову, сие свидетельство за надлежащей подписью с приложением печати школы. Г. Казань Мая 29 дня 1902 года. Подлинное свидетельство подписали: Председатель Педагогического Совета, Инспектор школы М. Пинегин. Члены Педагогического Совета Ив. Петяев, И. Терегулов, П. Траубенберг и Ш. Тагиров. Секретарь Н. Коржавин. 1902 года Июня 8 дня, настоящая копия с подлинного свидетельства по просьбе Исхакова снята в Красноярском Волостном Правлении Чистопольского уезда и правильность этой копии с подлинным свидетельством Волостное Правление удостоверяет подписом и приложением печати.

Волостной Старшина Ефим Емелин.

*[Документ Чистай өязе, Кызылъяр волосте идарәсенең түгәрәк, шәмәхә мөһере белән беркетелгән. Имза белән мөһер турысына шул чорның почта маркасы да ябыштырылган].*

Волостной Писарь *[имзасы укылмый]*.

*[**Документка искәрмә:** 6–7 нче кәгазьләрдәге бу документ каллиграфик, кара язу белән язылып, 6 нчы кәгазьнең сул кырына, документның башлам текстына аркылы итеп, 337 номеры сугылган («№ 337»)].*

**5 нче документ**

1902 года Марта 24 дня, мы, нижеподписавшиеся Самарской губернии, Бугульминского уезда, Верхне-Кармальской волости общество крестьян деревни Лашманкиной, быв сего числа на сельском сходе от 242 домохозяев в присутствиии 186 наличных человек, имеющих право голоса на сходе и Сельского Старосты Шарифуллы Ибрагимова, где слушали ходатайство крестьянина нашего деревни Мухаметгаяза Гилязетдинова Искакова об избрании его на должность

указного муллы к соборной мечети деревни Кутлушкиной Красноярской волости Чистопольскоо уезда, имея ввиду что препятствий к увольнении *[дөресрәге, «к увольнению»]* Искакова не имеется, казенных недоимок и других взысканий за ним нет, а потому Постановили уволить крестьянина нашей *[дөресрәге, «нашего»]* селения Мухаметгаяза Гилязетдинова Искакова 24 лет на предмет поступания в указные муллы к соборной мечети деревни Кутлушкиной Чистопольского уезда, в чем и подписуемся: 1. Баязит Сабитов 2. Земалетдин Сабитов 3. Идиятулла Мухутдинов 4. Тухфатулла Мухутдинов 5. Губейдулла Сангатуллин 6. Сафиулла Хайбуллин 7. Фархутдин Фахрутдинов 8. Валиулла Рахматуллин 9. Гафиятулла Биктимиров 10. Насибулла Гафиятуллин 11. Аглиулла Валиуллин 12. Дерземан Тухфатуллин 13. Вильдан Тухфатуллин 14. Гайса Тазетдинов 15. Садык Мухаметзянов 16. Зиганша Гайметов 17. Бикмухамет Надреев 18. Шарафутдин Гаряев 19. Валиулла Хайбуллин 20. Валиулла Нигоматуллин 21. Мияс*[с]*ер Магазов 22. Хасанша Гаряев 23. Губейдулла Нигоматуллин 24. ифтахутдин Фахрутдинов 25. Нигоматулла Ибятуллин 26. Мудерис Ибятуллин 27. Летфулла Ибятуллин 28. Зигангир Искаков 29. Билялетдин Валитов 30. Миннихаир Билялетдинов 31. Муртаза Садыков 32. Мухаметзян Муканов 33. Камалетдин Гофоров 34. Абдулсатдар Мязитов 35. Абдулгазиз Мязитов 36. Гафиятулла Губейдуллин 37. Тухфатулла Халитов 38. Салахутдин Ахметзянов 39. Илялетдин Ахметзянов 40. Ахметвяли Шаговаляев 41. Гариф Зарипов 42. Хайрулла Шагимерданов 43. Абдряфик Нафиков 44. Гизатулла Тухфатуллин 45. Миннихаир Гайнуллин 46. Миннигалим Хисматуллин 47. Хамидулла Хисматуллин 48. Ахметзян Габитов 49. Хамидулла Тухфатуллин 50. Вильдан Иксанов 51. Билялетдин Мухутдинов 52. Гарифулла Хакимов 53. Билялетдин Рязепов 54. Шамсувар Мухутдинов 55. Гильман Иксанов... *[шул рәвешле, барлыгы 186 кеше саналып кителә].*

Правильность сего удостоверял Сельский Староста дер. Лашманкиной Шарифулла Ибрагимов приложением должностной печати.

*[«Приговор» авыл старостасының түгәрәк, кара мөһере белән беркетелгән. Анда «Сельский староста Лашманкинского общества Бугульмин. у.» дигән сүзләр укыла].*

1902 года Марта 24 дня приговор тот в Верхне-Кармальском Волостном Правлении к свидетельству явлен, который в книгу на записку приговоров сельских сходов под № 17 записан, что Волостное Правление и свидетельствует.

Волостной Старшина Мордвинов.

*[Имза Бөгелмә өязе Югары Карамалы волосте идарәсенең патша Россиясе гербы төшерелгән түгәрәк, шәмәхә төстәге мөһере белән беркетелгән, аннан сулдарак – билгесез хакимият әһеленең имзасы].*

Писарь *[имза укылмый].*

*[Документның кара язу белән язылган төп текстыннан аермалы буларак, түбәндәге җөмләләр коңгырт кара белән язылган].*

1902 года Апреля 5 дня настоящий приговор мною в порядке 30 ст. Полож. Зем. Нач. рассмотрен.

Земский начальник 9 уч. Бугульминского *уезда [имзаны «В. Ермолаев»дип укырга була*].

*[Имза аның административ вазифасын раслаучы, патша Россиясе гербы төшерелгән түгәрәк, шәмәхә мөһер белән беркетелгән, мөһердән сулдарак – 3 нче документта да шәрехләнеп киткән билгесез хакимият әһеленең култамгасы].*

*[**Документка искәрмә**: 9–10 нчы кәгазьләрдәге бу алхәбәрсез документ – Гаяз Исхакыйны Лашман авылының игенчеләр җәмәгате исемлегеннән чыгару турындагы 1902 елгы авыл җыены «Приговоры». Аның төп тексты кара, вак язу белән тутырылган].*

## 6 нчы документ

## Удостоверение

Дано сие Верхне-Кармальским Волостным Правлением крестьянину дер. Лашманкиной сей волости Мухамет Гиасу Гилязетдинову Искакову 24 л. рожд. 10 февраля 1878 г. в том, что он, Искаков, действительно есть то самое лицо и того звания, кою выше значится, под судом и следствием не был и ныне не состоит, и не состоит в последних татарских волнениях *[1897 елгы].*

Волостной Старшина Мордвинов

*[Имза өстенә XX гасыр башының почта маркасы ябыштырылган. Алардан түбәндәрәк Бөгелмә өязе Югары Карамалы волосте идарәсенең патша Россиясе гербы төшерелгән түгәрәк, шәмәхә мөһере сугылган. Аның сул читендә – 3, 5 нче документларда да шәрехләнгән билгесез хакимият әһеленең имзасы].*

Писарь *[имза укылмый].*

*[**Документка искәрмә**: дәфтәр бите форматын хәтерләтүче 11 нче архив кәгазендәге кара язу белән язылган документ башламының сул кырында Самара губернасы Бөгелмә өязе Югары Карамалы волосте идарәсенең зур дүртпочмак рәвешендәге кара, ике башлы каракош сурәте төшерелгән мөһер-штампы урын алган. Таныклык 1902 елның декабрь ае белән даталанып, аның идарә канцеляриясендәге тәртип номеры 2213].*

## 7 нче документ

## Метрическая справка

1903 года Февраля 2 дня, я, исполняющий обязанности муллы 1-ой соборной мечети деревни Кутлушкиной Чистопольского уезда Казанской губернии Сахабутдин Хуснутдинов, производил справку

в метрических книгах названной мечети о родившихся и оказалось: тысяча восемьсот семьдесят восьмого года, Февраля десятого дня под № 5, записан родившимся Мухамед Гаяз сын имама Гилязетдина Искакова, мать Камария. Что подписом своим по-татарски удостоверяю. Исполняющий обязанности муллы Сахабутдин Хуснутдинов *[аның гарәп шрифты белән татарчалап куелган имзасы].*

1903 года Февраля 2 дня, что настоящая метрическая справка действительно подписана собственноручно исправляющим обязанности муллы Сахабутдином Хуснутдиновым, в том Красноярское Волостное Правление Чистопольского уезда удостоверяет.

*[Раслама текстының сул читенә патша Россиясе чорында чыгарылган почта маркасы ябыштырылган].*

Волостной старшина Ефим Емелин.

*[Имза астына, кәгазьнең сул читенә Чистай өязе Кызылъяр волосте идарәсе башлыгының түгәрәк, кара мөһере сугылган].*

Волостной писарь *[имза укылмый].*

[***Документка искәрмә**: 12 нче архив кәгазендәге бу документ кара, матур почерк белән язылган].*

**8 нче документ**

№ 80 I/VI Административный. 13

**Журнал присутствия Казанского Губернского Правления**

По 1-му столу 1-го Отделения Марта 31 1903 года

Слушали:

Чистопольское Уездное Полицейское Управление при рапорте от 27 февраля 1903 г. за № 430 представило на распоряжение Губернского Правления приговор прихожан 1-ой соборной мечети, состоящей в дер. Кутлушкиной Красноярской волости, от 8 Июня 1902 г., ходатайствующих об определении к их мечети вторым муллою крестьянина Самарской губ., Бугульминского уез., Верхне-Кармальской вол., дер. Лашманкиной, Мухамед-Гаяза Гилязиндинова Искакова, составленный в присутствии местного волостного старшины и сельского старосты деревни 176 домохозяевами-прихожанами, из числа 202 домохозяев, имеющих право голоса на сходе, т. е. более, чем 2/3, подписанный надлежащим порядком и засвидетельствованный в Красноярском Волостном Правлении, и документы Искакова: 1) метрическую выпись о рождении, из которой видно, что Искаков родился 10 Февраля 1878 г.; 2) свидетельство о явке к исполнению воинской повинности, за № 30; 3) копию свидетельства Педагогического Совета Казанской Татарской Учительской Школы, за № 337, об успешном окончании Искаковым полного курса названной школы; 4) свидетельство Оренбургского Магометанского Духовного Собрания за

№ 3568 об *[алга таба «познаниях» сүзе язылып, сызылган]* испытании Искакова в знании правил магометанской религии, по которому он оказался быть способным имам-хатыпом и мугаллимом *[алга таба «Кроме того, Чистопольским Полиц. Управлением при том же рапорте представлены» дигән сүзләр язылып, алар сызылгын];* 5) приговор общества крестьян дер. Лашманкиной, Верхне-Кармальской вол., Бугульминского у., Самарской губ. от 24 марта 1902 г. об увольнении Искакова из среды того общества для поступления в духовное звание. Из переписки *[алга таба «данно» дип язылып, сызылган]* усматривается, что Искаков поведения хорошего, под судом и следствием не был и ныне не состоит и участия в татарских волнениях, во время всеобщей народной переписи *[1897 елгы],* не принимал.

Справка: По ведомости о магометанских приходах за 1902 г. по Чистопольскому уезду *[алга таба «значится» дип язылып, сызылган]* в дер. Кутлушкиной значится две соборных мечети. При 1-ой из них старшим муллой состоит крестьянин Гилязетдин Искаков *[Гаяз Исхакыйның әтисе].*

Приказали: согласно ходатайству крестьян-прихожан 1-ой соборной мечети деревни Кутлушкиной, Чистопольского уезда, выраженному в приговоре их от 8 июня 1902 г., и неимению препятствий, крестьянина дер. Лашманкиной, Бугульминского у., Самарской губ., Мухамед-Гаяза Гилязетдинова Искакова, на основ. 1393 и 1416 ст. ст. *[документта шулай]* и примеч. к ним и 1431–1436 ст. ст. *[документта шулай]* XI т. I ч. Уст. Ин. Испов. *[«Устава Иностранных Исповеданий»],* изд. 1896 г. определить имамом к 1-ой соборной мечети дер. Кутлушкиной, в чем ему и выдать надлежащее свидетельство на звание имама, с возвращением свидетельства о явке к исполнению воинской повинности за № 30, предписав при этом Полицейскому Управлению, предварительно выдачи свидетельства на звание имама, привести в Присутствии Полицейского Управления Искакова на верность службы к присяге, и чтобы присяжный лист, вместе с распискою Искакова в получении высылаемых документов, был представлен в Губернское Правление, а о вышеизложенном было бы объявлено прихожанам 1-ой соборной мечети дер. Кутлушкиной. Об этом постановлении, для сведения, дать знать и Оренбургскому Магометанскому Духовному Собранию.

Вице-губернатор *[имзасыз].*

Старший Советник *[имзасыз].*

И.у. *[«Исполняющий управляющий»?]* Советника *[имзасы укылмый].*

Об определении крестьянина *[алга таба «дер.» дип язылып, сызылган]*

Мухамед-Гаяза Искакова имамом к 1-ой соборной мечети дер. Кутлушкиной, Чистопольского уезда.

Старший Делопроизводитель *[имзасыз].*

*[**Документка искәрмә:** 13–14 нче кәгазьләрдәге бу документ таблица рәвешендә эшләнеп, басма трафаретка кулдан, кара, вак язу белән тутырылган. Таблицаның «Когда исполнено» дигән исем астындагы уң графасында «17 апреля, № 1009, Чистопол. Полиц. Управл., № 1010, Ор. Маг. Дух. Собр., № 1011» дигән мәгълүмат бирелгән].*

## 9 нчы документ

В Казанское Губернское Правление

*[Аскарак Казан губернасы идарәсенең 1903 елның 3 мае белән даталанган овал рәвешле, шәмәхә мөһере сугылган. Шул ук турыга, документ текстына кыеклап, билгесез имза куелган]*

Чистопольского Уездного
Полицейского Управления

**Рапорт.**

Вследствие указа от 17-го сего Апреля за № 1010, Полицейское Управление имеет честь доложить Губернскому Правлению, что крестьянин Самарской губ., Бугульминского уезда, дер. Лашманкиной Мухамед-Гаяз Гилязетдинов Искаков, назначитый вторым муллою к 1-ой мечети дер. Кутлушкиной Чистопольского уезда, проживает в настоящее время в г. Уфе на должности учителя татарской школы и возвратится в дер. Кутлушкино к 15 Июня сего года.

Исправник Афонасьев.

Секретарь *[имзасы укылмый]*.

№ 1362.
Апреля 29 дня 1903 года.
Отд. I. Стол I.

*[**Документка искәрмә:** дәфтәр битен хәтерләтүче 15 нче архив кәгазендәге басма башламлы бу документ кара, матур, йөгерек почерк белән кулдан язылган].*

## 10 нчы документ

В Казанское Губернское Правление

*[Астарак Казан губернасы идарәсенең 1903 елның 7 сентябре белән даталанган мөһере сугылган. Шул ук турыга, документ текстына кыеклап, билгесез имза куелган]*

Чистопольского Уездного
Полицеского Управления

**Рапорт.**

Во исполнение Указа от 17 апреля сего года за № 1010, Полицейское Управление имеет честь при сем представить в Губернское Правление присяжный лист и расписку крестьянина Самарской г. Бугульминского уезда, деревни Лашманкиной Мухамед-Гаязы Исхакова

в получении им свидетельств: на звание имама I мечети деревни Кутлушкиной Чистопольского уезда за № 1009 и о явке к исполнению воинской повинности за № 30.

Исправник Афонасьев
№ 1362.
Сентября 23 дня 1903 г. Секретарь Степанов
Отделение I. Стол I.

*[**Документка искәрмә:** дәфтәр битенә охшашлы 16 нчы архив кәгазендәге бу документ язу машинасында басма хәрефләр белән басылган].*

**11 нче документ**

1903 года Сентября 23 дня я, нижеподписавшийся крестьянин Самарской губ. Бугульминского уезда дер. Лашманкиной Мухамед-Гаяза Искаков, настоящую расписку выдал Чистопольскому Уездному Полицейскому Управлению в том, что присланные при Указе Казанского Губернского Правления от 17 апреля сего года за № 1010 свидетельство на звание имама за № 1009 и свидетельство о явке к исполнению воинской повинности за № 30 я сего числа получил, в чем и подписуюсь *[имза: «Мухамед Гаяз Исхаков»].*

Уездный исправник Афонасьев.

*[**Документка искәрмә:** 18 нче кәгазьдәге кульязма документ кара, матур, йөгерек почерк белән язылган].*

**Әдәбият**

*Гайнанова Л.* Гаяз Исхакый шәҗәрәсе // Мәдәни җомга. 2008. 19 декабрь (№ 50). Б. 14–15.

*Исхакый Г.* Тәрҗемәи хәлем // Гаяз Исхакый: тарихи-документаль җыентык / төз-авт.: С. Рәхимов, З. Мөхәммәтшин, А. Заһидуллин. Казан: Җыен, 2011. Б. 34–80.

*Мөхәммәтшин З.* Гаяз Исхакый: шәхес, әдип, милли рәһбәр (лидер) // Гаяз Исхакый: тарихи-документаль җыентык / төз-авт.: С. Рәхимов, З. Мөхәммәтшин, А. Заһидуллин. Казан: Җыен, 2011. Б. 3–32.

*Хәсәнов М.* Татар ренессансының бөек каһарманы // Гаяз Исхакый. Әсәрләр: унбиш томда. I т.: Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Б. 5–30.

***Галләм Рәшит Габделфәрт улы,***
*тарих фәннәре кандидаты*

УДК 82-94

***Н.И. Таиров, И.Н. Таиров***

# Г. ИСХАКЫЙ МӘСКӘҮДӘ МӨСЕЛМАН СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН: БЕР ФОТОРӘСЕМ ТАРИХЫ

В статье, опираясь на материалы архивов, периодических изданий, воспоминаний, рассматриваются вопросы времени, места и истории появления фотоснимка Г. Исхаки со студентами в Москве, его расшифровки.

**Ключевые слова:** татары, предприниматели, студенты, фотоснимок, Г. Исхаки, Г. Тукай, Москва.

Гаяз Исхакыйның Мәскәүдә мөселман студентлар белән төшкән фоторәсеме 1995 елда безнең тарафтан татар эшмәкәренең гаилә архивыннан табылып, мәртәбәле «Сөембикә» журналының 6 нчы санда басылып чыкты [Таиров, 1995, с. 14]. Алга таба әлеге фотодокумент белән галимтикшеренүчеләр дә кызыксынып, ул Г. Исхакый әсәрләре җыентыгының 3 нче томында дөнья күрде. 2002 елда әлеге фотоны без «Акчуриннар» китабына да урнаштырдык [Таиров, 2002, с. 30, 96–97]. Соңгы елларда бу фотоны өйрәнү эшен дәвам итеп, Акчурин, Камалов, Рәхимов, Терегулов нәселеннән булган кайбер шәкертләрнең шәхесен ачыклауга ирештек.

Эзләнү, өйрәнү барышында рәсемнең кайбер мәгълүматлар язылган икенче бер экземпляры да табылды. Мәсәлән, бу нөсхәдә фотога төшү датасы һәм андагы кешеләрнең исемлеге дә китерелә. Әлеге кыйммәтле тарихи чыганакка инде 100 елдан артык, шуңа күрә аның сакланышына бераз зыян да килгән. Бу, нигездә, андагы язуларга карый. Рәсемнең аскы өлешенә сурәттәге кызлар һәм егетләрнең, Г. Исхакыйның исемнәре язылган булган. Кызганычка каршы, әйтеп үтелгәнчә, аларның сакланышы бик түбән дәрәҗәдә. Текстның аерым урыннары кыршылып, бөтенләй юкка чыккан, кайбер җирләре бик нык бозылган. Шулай да күренекле галим, филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов аларның кайберләрен ачыклау мөмкинлегенә ирешә алды. Мәскәү студентларының Г. Исхакый белән берлектәге күмәк фотода түбәндәге исемнәр язылган:

1. Хәлил Галиев, Бари Госманов, Гали Рәхимов, Сәгыйть Дебердиев, Ибраһим Аитов, Гомәр Акчурин, Мостафа Шәкулов, Гомәр Терегулов, Сөләйман Агишев, Мөхәммәт Терегулов, Мостафа Сәйфелмөлеков, Таһир Исаев, Гайнетдин Дебердиев;

2. Гариф Кәримов, Мәрьям Айдарова, Ак кәгазь Рустамова (Дустанова – ?), Рабига Богданова, Гаяз Исхаков, Мәрьям Паташова, Хәтимә Камалова, Зөһрә Акчурина;

3. Гыйззетдин Сәйфелмөлеков, Шәйхулла Алкин, Нурмөхәммәт Татабаев.

Фотографиянең арткы ягына фотоательеның адресы язылган: «Фотогр. М. Перцев. Москва, Пятницкая 17». Шунда ук кемдер каләм белән фотога төшү вакытын һәм урынын да теркәгән: «8-го апреля 1914 г. Москва». Әлеге уникаль тарихи документның алгы ягында ательеның башка шрифтта бирелгән исеме дә саклангән.

Фото безгә моннан бер гасыр элек Мәскәүнең генә түгел, ә XX йөз башында Россиядәге татар студентларының кыяфәтләрен, килеш-килбәтләрен күзалларга ярдәм итә. Бу тарихи фотода, бер тамчы суда диңгезне күзаллагандай, 1917 елга кадәр илнең татар бергәлеге, төгәлрәге – аның студентлары гәүдәләнә. Авылларда һәм зур булмаган шәһәрләрдә туып үскән студентлар Россиянең ерак төбәкләрендәге чынбарлыкны яхшы беләләр. Мәскәүгә укырга килгән яшьләр, белем алып, илгә һәм үз халкына хезмәт итү максаты белән яши. Шунысы игътибарга лаек, аларны авырлыклар да, матди кыенлык та, туган якларыннан еракта булу да куркытмый. Илдәге татар бергәлегенең белемле өлеше, ягъни губерна үзәкләрендәге һөнәри уку йортларын тәмамлап килгән яшьләр Мәскәү студентлары арасында үз урыннарын тиз табалар, кушылып китә алалар. Алар, барыннан да бигрәк, эшмәкәрлек (җитештерү, сәүдә һәм финанс) өлкәсен киңрәк үзләштерергә омтылалар.

Безнең каршыбыздагы фотода Г. Исхакый янәшәсендәге студентлар – Россия татар сәүдәгәрләренең, сәнәгатьчеләренең, дин әһелләренең һәм мәгърифәтчеләрнең балалары. Укучыларның географияләре дә шактый киң: Сембердән, Саратов, Казан, Оренбург, Уфа губернасыннан. Алар арасында Акчурин, Дебердиев, Аитов, Рәхимов, Терегулов кебек күренекле татар эшмәкәрләренең нәсел дәвамчылары бар.

Гомәр Акчурин, мәсәлән, күренекле татар фабриканты һәм меценаты Хәсән Акчуринның улы. Мостафа Сәитшәкулов – Тимербулат Курамша кызы Хәнифәнең улы. Акчуриннарның нәсел шәҗәрәсендә аларны Тимай-бай Акчуриннарның оныклары дип карарга мөмкин. Тимай байны бер шигырендә Габдулла Тукай да телгә ала [Тукай, II т., б. 221, 359–360].

Зөһрә Акчурина – Исмәгыйль Курамша улы Акчуринның кызы. Ул, Сембердәге кызлар гимназиясен тәмамлап, Мәскәү югары уку йортларының берсендә белем ала. Җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. 1917 елның 24–27 нче апрелендә Казанда узган Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары корылтаенда вәкил буларак катнаша.

Тагын бер студент – Гайнетдин Дебердиев турында аерым тукталып үтик. Ул – Саратов губернасы Кузнецк өязендәге атаклы постау фабрикасы хуҗалары һәм сәүдәгәрләр нәселе вәкиле. Гайнетдин күпмедер дәрәҗәдә Акчуриннар белән дә бәйләнешле була. Акчуриннар белән Дебердиевлар үзара бик тыгыз

элемтәдә булалар, алар арасында гаилә-туганлык мөнәсәбәтләре урнашу да билгеле. Гайнетдин үзе Йосыф бай Акчурин (Иске Тимошкино авылындагы постау фабрикасы хуҗасы) хатынының кардәше була. Гайнетдин Дебердиев студентлык чорында Акчуриннар нәселеннән булган яшьтәшләре белән даими элемтәдә яши. Болганчык 1917–1918 елларда Гайнетдин, күңеленә тынычлык эзләп, Иске Тимошкинога (Зиябашы) – Акчуриннарга кунакка килә. Бу авылда аны белүчеләр күп булмый. Ләкин шушы төбәктәге 1917–1918 елның канлы вакыйгасы нәкъ менә аның исеме белән бәйле. Йосыф Акчуриннарга еш кына кызылармиячеләр килеп, алтын һәм башка кыйммәтле әйберләр эзлиләр, аларны фабриканттан таләп итәләр. Беркөнне шундый эзләнүләр вакытында Гайнетдин балконга чыккан була һәм атып үтерелә. Аны авыл зиратына – Акчуриннар нәселе янәшәсенә җирлиләр. Авыл халкы, егетне якыннан белмәсә дә, аның үтерелүен бик авыр кабул итә. Хәтта бу вакыйгага бәйле бәет чыгаралар. Халык телендә йөргән әлеге бәетнең бер өлешен Ульяновск өлкәсе Барыш районының Калны (Калды) авылында яшәүче Зөләйха Әбдерәшит кызы Таировадан (1916–2001) язып алган идек.

Бәеттә кызылгвардиячеләр отряды җитәкчесе Шамил турында да сүз бар. Авыл өлкәннәре бу исемне күренекле татар язучысы һәм сәяси эшлекле Шамил Усманов белән бәйлиләр. «Канлы көннәрдә», «Беренче адым» пьесалары, «Легион юлы» повесте һәм башка әсәрләр авторы нәкъ менә Сембер губернасында яңа хакимият оештыруда катнашкан.

Фотода Акчуриннарга турыдан-туры мөнәсәбәте булган затлардан Сөләйман Агишев та бар. Ул фабрикантларның якын кешесе була. Акчуриннар, тәрбия һәм белем бирүне үз өсләренә алып, егеткә башта Сембер сәүдә көллиятендә, аннан Мәскәүдә дәрәҗәле генә югары уку йортында белем алырга мөмкинлек тудыралар. Туганнары архивында аның уку йортын уңышлы тәмамлавы турында документ та саклана. 1917 елга кадәр ул Акчуриннар ширкәтенең берсе белән идарә итә. Кызганычка каршы, ул революцион күтәрелеш чорында юкка чыга. Шул төбәктә яшәүче аксакалларның мәгълүматларына караганда, ул фабрикалар бистәсеннән Акчуриннар белән бергә киткән булырга тиеш.

Фотодагы студентлар арасында постау фабрикасы хуҗасы, сәүдәгәр, хәйрияче һәм меценат Дебердиевлар нәселе вәкиле дә бар – ул Сәгыйть Дебердиев. Сәйфелмөлековлар исә икесе дә Оренбург ягы татар эшмәкәрләренә барып тоташалар. Рәсемдә галим, язучы булып танылган Гали Рәхимов та (Гали Рәхим) Казанның татар сәүдәгәрләре нәселеннән. Үз вакытында ул да Казан сәүдә көллиятен тәмамлап, Мәскәү коммерция институтына укырга керә.

Фотода татар студент кызлары төркеме булу игътибарны аеруча җәлеп итә. Алар Мәскәүнең төрле югары уку йортларында укыганнар. Хәтимә Камалова –

танылган дин эшлеклесе, Чистай мәчете имамы Мөхәммәдзакир Камаловның кызы. Хәтимә, Мәскәүдә белем алып, үз гомерен иң авыр, әмма игелекле һөнәр – медицинага багышларга җыена. Кама буенда үскән кызның ниятләре изгедән булса да, кызганычка каршы, ул тормышка ашмый кала. Совет хакимиятенең беренче елларында ук ул вафат була.

Язучы Г. Исхакый белән янәшә үк утырган Мәрьям Поташова Балкан сугышы вакытында, бер төркем татар кызлары (Гөлсем Камалова, Мәрьям Якупова, Рокыя Юнысова) белән Төркиядә була. Анда кызлар үзләрен татар һәм төрек дөньясында таныталар. Мәрьям Гөлсем Камалова белән яхшы таныш була. Гөлсем исә, 1913 елда фабрикант Габдулла Акчуринга кияүгә чыгып, Сембер губернасындагы Гурьевка авылында яши. Мәрьям 1916 елда аларда кунакта була һәм аларның шул чакта бергәләп төшкән фотолары да саклануы хакында Гөлсем Камалованың (Акчуринаның) кызы искә алды. Күмәк фотода татар кызларының булуы Россия җәмгыятендә аларның роле арта баруны дәлилли.

Г. Исхакый белән очрашу, аның белән фотога төшү кайбер яшьләр өчен, бәлки, беренче очрашу һәм якыннан танышу да булгандыр. Мөгаен, алар бу очрашуны күңелләрендә гомер буена саклаганнардыр.

Кайбер студентлар, язучы белән танышып, аралашып яшәү белән беррәттән, Г. Исхакый нәшер иткән татар телендәге газеталар белән хезмәттәшлек тә итәләр. Шәйхулла Алкин Казанның милли зыялылары вәкиле була, югары белемле коммерсант, балалар язучысы. Мәскәүнең коммерция институтында укыган елларында ул «Ил» газетасында һәм «Ак юл» журналы битләрендә мәкаләләре һәм хикәяләре белән катнаша. Шул ук вакытта Ш. Алкин яшьләр кичәләре оештыруда да актив катнаша [Исхаков, б. 292, 396].

Бу кызыклы фото, мөгаен, Г. Тукай исеме белән бәйле булгандыр дигән фикер туа. Нәкъ менә 1914 елның апрель көннәрендә илнең татар зыялылары һәм шигърияткә омтылучылар Г. Тукайның вакытсыз вафат булуына бер ел тулуны билгеләп үтәләр.

Ул көннәрдә Г. Тукай истәлегенә багышланган чаралар Россиянең татарлар яшәгән төбәкләрендәге уку йортларында һәм эш урыннарында уздырыла. Фотоның максаты да шул вакыйгаларның берсен мәңгеләштерү ниятеннән булса кирәк. Әлеге төркем вәкилләре дә Г. Тукай һәм башка татар язучылары белән очрашуларда аларның иҗаты турында сөйләгәннәрдер, шигырьләрен укыганнардыр. Шундыйларның берсе дип фабрикант һәм меценат Хәсән Акчуринның улы Гомәр Акчуринны әйтергә мөмкиндер, чөнки танылган шагыйребез 1909 елда Акчуриннарда (Сембердә) була. Ул анда Акчуриннар гаиләсендәге балалар, яшүсмерләр белән аралашмый калмагандыр. Шагыйрьнең Акчуриннарда булу фактына татар язучылары һәм драматурглар, театр коллективлары әле хәзер дә зур игътибар бирәләр.

Шуны әйтергә кирәк, XIX–XX гасырлар чигендә татар сәүдәгәрләре һәм сәнәгатьчеләре балаларын милли әдипләребез, җырчыларыбыз, музыкантлар, театр коллективлары белән таныштыруны үз бурычлары дип санаганнар. Моңа 1912 елда Г. Тукайның С.-Петербургта булуын мисал итеп китерергә була. Мәсәлән, эре сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе, меценат Галим Максутов шагыйрь белән очрашуга улы Кәримне дә алып килә [Таиров, с. 120–122]. Г. Тукай белән таныш булган студентлардан Гали Рәхимне дә әйтми калдыру мөмкин түгел.

Мәскәүдә һәм С.-Петербургта уздырылган төрле очрашуларга чакырулы кунаклар арасында һәрчак татар язучылары, журналистлары һәм артистлары да булган. Алар хакындагы мәгълүматлар татар вакытлы матбугаты битләренә теркәлгән. Андый чаралар ике башкалада укучы яки яшәүче татар яшьләренең очрашып аралашу, фикер алышу урыны саналган. Яшьләр шулай ук Россия мөселманнарының дини һәм дөньяви бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр.

Фотодагы башка затларның язмышы да төрле юнәлеш буенча китә. Аларга әле күз алдына китерә алмастай җитди сынаулар кичерергә туры килә. Алар тормышында, эшчәнлегендә 1917 ел һәм аннан соңгы еллар вакыйгалары зур роль уйный. Кызганычка каршы, Октябрь инкыйлабы аларның яшәү рәвешен тискәре якка үзгәртә, хәтта фаҗигагә әйләндерә. Күбесе, хәтта, укуларын да тәмамлый алмый калалар. Белем алып өлгергәннәренең кайберләренә һөнәрләре буенча ихтыяҗ булмый – эш таба алмый интегәләр. Андыйлар үз илләрендә кирәксез кешегә әйләнә.

Яңа хакимият аларга шикләнеп карый, яки турыдан-туры дошманы итеп күрә, күп гамәлләрен большевиклар корткычлык дип саный. Яңа җәмгыятьне алар үзләре дә кабул итә алмый. Өстәвенә, кайберләре нигезсез кимсетелүләргә һәм, хәтта, репрессияләргә дучар ителә.

Фотодагы студентларның кайберләре 1917–1918 елгы вакыйгалардан соң Россиядән китәргә, калган гомерләрен чит җирләрдә уздырырга мәҗбүр була.

Фоторәсемне игътибар белән өйрәнү кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Фотосурәт – кыйммәтле чыганак булып хезмәт итә. Андагы затларның һәркайсын тәфсилләп өйрәнү яшәүнең мәгънәсе һәм шул чор татар язучыларының инде танылып өлгергән вәкиле Г. Исхакый иҗаты хакындагы фикерләребезне тирәнәйтә. Г. Исхакыйның гаять бай әдәби иҗаты, әле XXI гасырда да, татарларның гына түгел, Россия Федерациясендәге һәм чит илләрдәге башка халыкларның да игътибарын җәлеп итә. Мәгълүм булганча, язучының тормыш юлы вакыйгаларга гаять бай, шул исәптән сәфәрләр һәм күченеп йөрүләр дә күп булган. Фоторәсем аша без Г. Исхакыйның гына түгел, андагы студентларның да шул вакытта кайда булуын, төгәл көнен билгели алабыз (бу хакта фотода күрсәтелгән). Бер үк вакытта тарихи

әһәмияткә ия фотодокументта студентлар исемлеге дә бирелгән. Әнә шулай, акрынлык белән булса да, язучы биографиясендәге һәм шушы төркем вәкилләренә кагылышлы «ак тапларны» киметә барабыз. Гомумән алганда, әлеге мәкалә Г. Исхакыйның күпкырлы иҗатын һәм татар студентларының биографияләрен алга таба тикшерүгә ярдәм итәр, дигән өметтә калабыз.

**Әдәбият**

*Таиров Н.* Фотография Гаяза Исхаки // Сююмбике. 1995. № 6. Б. 14.

*Таиров Н.И.* Акчурины. Казань. 2002. С. 30, 96-97.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда: академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011; 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913). 2011. Б. 221, 359–360.

*Исхаков М.Г.* Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 2 т. Б. 292, 396.

*Таиров Н.И.* Г. Тукай и Максутовы // Материалы международной научно-практической конференции, посвященной 125-летию со дня рождения Г. Тукая «Наследие Г. Тукай в контексте национальных культур» (25 апреля 2011 г.). Казань, 2011. С. 120–122.

***Таиров Наил Измаил улы,***
*тарих фәннәре докторы, Казан дәүләт мәдәният институты профессоры*

***Таиров Илһам Наил улы,***
*Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе табибы*

УДК 82.512.1-131

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ТӨРЕ БУЛАРАК ЭТНИК МУЗЫКАЛЬ ТРАДИЦИЯДӘ ХУШАВАЗЛАР

Статья предполагает изучение некоторых теоретических вопросов по татарским народным песням, охватывает тему сбора образцов песенного наследия татар, проживающих в разных уголках России. Автор реконструирует ранее неизученную в фольклористике разновидность лирических песен «хушавазы», выявляет место и роль татароязычных хушавазов в системе фольклорных жанров, определяет их ареал распространения среди татар, описывает общие структурно-содержательные особенности текстов.

**Ключевые слова**: хушаваз, лиро-эпический, песенный, народный, татары, запись, текст, музыкальный, этнический, фольклор.

Татар халкының җыр мирасы – төсле бизәкләрдән тукылган моңлы, шигъри бер дөнья. Җырның хискә, мәгънәгә бай нәфис сүзләре һәм гамьгә, дәрткә бай тылсымлы музыкасы халыкның рухи бөтенлеген һәм тиңдәшсез талант иясе булуын раслый. Җыр хәзинәсендә чал тарих авазлары да, бүгенге көннәр аһәңе дә тирән булып уелган. Жанр үзенчәлеген шигъри хәзинә буларак тикшергәндә татар традицион җыр мирасын дүрт төркемгә бүлеп карау кабул ителгән: йола җырлары, уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик җырлар [Миңнуллин, б. 47–48; 48–64]. Соңгы төркем үзе икегә бүлеп өйрәнелә: лирик озын җырлар, лирик кыска җырлар. Хушавазлар исә – лирик озын җырлар төркемендә үзенчәлекле бер төрне тәшкил итә торган, фольклористикада әлегәчә игътибардан читтә кала килгән иҗат.

Әлеге мәкаләдә лирик җырларның хушавазлар дигән төркемենә аерым игътибар бирү максаты күз алдында тотыла. Хушаваз – фольклористикада сүз сәнгате буларак махсус өйрәнелмәгән өлкә, чичәннәр иҗаты белән бәйле лирик, лиро-эпик жанр төре. Хушавазларны махсус көйгә салып җырлыйлар, ул татарлар яши торган төрле урыннарда очрый. Халык аны «җыр» дип тә, «хушаваз» дип тә, «хушаваз җыры», «хушаваз белән җырлана торган җыр» дип тә атый. Лирик һәм лиро-эпик характердагы әлеге әсәрләр бүгенге көнгәчә ни эпос, ни җыр буларак өйрәнелми читтә кала киләләр, гәрчә халык авыз иҗатының соңгы елларгача саклана килгән актив үрнәкләре булсалар да.

Хушавазлар – җыр жанрының һәм этник музыкаль традицияләрнең үзенчәлеге, бу жанрга караган үрнәкләр татарларның бай һәм күптөрле музыкаль фольклоры турында тулырак һәм җентекле күзаллау тудыра. Хушаваз жанрына музыкаль әсәр буларак игътибар юнәлтеп, Г.М. Макаров мондый фикер белдергән иде: «Бу төшенчәнең татар

халкы традицион мәдәниятендә ике мәгънәдә кулланылуы билгеле. Беренчесендә ул Әстерхан төбәге татарларының шигъри-вокаль сәнгатендә жанр буларак мәгълүм; икенчесендә Урта гасыр шигъриятендә кулланылган махсус атама буларак билгеле» [Макаров, б. 17]. Үзенең китабында галим «хушаваз» төшенчәсенең татар музыка белеменә М.Н. Нигъмәтҗанов хезмәтләре аша кергән булуы турында яза. «Хушавазлар, – ди ул, – автор язганча, бәетләр тематикасы кебек үк, шактый киң колачлы һәм гади көнкүрештә булганнардан алып зур тарихи вакыйгаларны тасвирларга сәләтле. Кайбер хушавазларны башкару вакыты берничә сәгатькә сузылырга мөмкин» [Макаров, б. 17]. Халык музыкасы белгечләренең татар халык иҗатындагы хушавазны жанр буларак танулары – бик кирәкле һәм мөһим гамәл. Әлеге хаклы фикергә [Макаров, б. 19–20] кушылып, шуны әйтәбез: фольклор текстлары буларак хушавазлар аз чагылган, тикшеренүчеләр тарафыннан хушаваз атамасы белән теркәлмәгән булса да, халыкта бу төшенчә үз функцияләрен үти һәм яши бирә. Хушавазларның халык иҗатында хосусиятен өйрәнү, барлыкка килгән сорауларга җавап эзләүне дәвам итү – бүгенге фольклористика алдында торган актуаль мәсьәлә.

Халык шигыренә нигезләнгән мондый жанрның шактый тармаклы булуы, архаик чорлардан ук фольклорда киң кулланылуы мәгълүм. Халык иҗатында бер үк авазны яисә сүзне кат-кат кабатлаган аллитерацион шигырьнең әллә ничә төрен, һәр юлда иҗекләр саны төрле булып та, сүзләр саны тигез китерелгән сүз-буын (слово-стопа) шигыре, сан-иҗек, халык шигыренең так-маза шәкеленә нигезләнгәнен һ.б.ны куллану тезмә текст булдыру чарасы саналган һәм язмачылыкка күчкәнче гаять популяр кулланылган. Башкорт, казакъ, үзбәк, азәрбәйҗан, кыргыз, төрекмән, Кырым татарлары, якут, алтай, Себер татарлары, хакас, шор һ.б. төрки халыклар, бурят һ.б. төрки булмаган кайбер халыклар мәҗлесләрендә оста җыручылар чыгыш ясый торган булган. Сүз осталары, халык шигыре стиленә таянып, бер сөйләгәнен икенче тапкыр кабатламыйча җыр башкарулары белән дан тотканнар [Жирмунский, с. 33].

Көньяк Себер һәм көньяк халыкларының күпчелегендә бу традиция әле бүген дә югалмаган, әмма кайчандыр ритуал-мифологик контекстка ия мондый җырларның төрле шартлар йогынтысында идея-структур үзгәрешләрне бик нык кичергәнлеген дә онытырга ярамый. Бүгенге көнгә килеп җиткән хушавазларның да борынгылык белән тирән бәйләнеш тотулары шик уятмый. Бу – махсус тикшеренү сорый торган өлкә. «Тере» фольклорның музыкаль башкарылу, чичән-импровизатор чыгышы һәм аның сүзләрен тыңлап торучы аудитория синтезыннан гыйбарәт җырларның мондый төре утрак тормышны үз иткәнгә кадәр күчмә тормыш шартларында озаграк яшәгән, җир эшкәртеп яшәүгә чагыштырмача соңрак

килгән, шәһәр мәдәнияте һәм язма әдәбиятка ихтыяҗы да бераз соң формалашкан халыкларда стабильрәк сакланган. Хушаваз иҗатының Әстерхан татарларында еш очравы – нугай, казакълар белән тыгыз аралашу тәэсире булырга мөмкин. Хушавазларны көйләп әйтү, гадәттә, думбрага кушылып башкарылган.

«Хушаваз» сүзе «яхшы сүз», «күңелгә охшардай җыру», «яңгыравы тансык аваз» мәгънәләрендә XIV йөздә иҗат иткән төрки шагыйрь Котб иҗатында ук күзгә чалына, лиро-эпик фольклорга якынлыгы белән игътибарны җәлеп итә:

*Шаһ андин сорды кем: «Ушбу хуш аваз*
*Ни аваз? Ача тип мәңа раз.*
*Бу хуш аваз белә җанымны алда...»*

[Источники..., с. 130–131].

Моннан тыш, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъяр шигъриятендә [Мөхәммәдъяр, б. 28, 36], «Таһир белән Зөһрә»дә [Таһир белән Зөһрә, б. 217] һ.б.да «хушаваз» гыйбарәсенә юлыгабыз. Болар барысы да хушавазларның Урта гасырларда үсеш алган, классик шигъриятә һәм халык иҗатында популяр шигъри-музыкаль жанр булуын дәлилли.

Хушавазлар башкаруның татарларда бүгенге көндә дә очравы – халкыбызның җыр жанрын баета торган күренеш. Татар халык иҗаты буенча милли фольклор томнарын төзегәндә халкыбызда моңа кадәр табылган хушаваз текстларын исәпкә алу – басмаларның академик дәрәҗәсен тәэмин итүдә бер адым. Шушы вазгыятьне исәпкә алып, бүгенге көндә төзелә торган «Татар халык иҗаты» 25 томлыгының «Халык җырлары» томнарына хушавазларны аерым бүлек итеп кертү планлаштырыла. Хушаваз җырларының зур күпчелеге Әстерхан татарларыннан язып алынган. Томнарга сайлап алынган материаллар Әстерхан ягында яшәүче татарларның кариле (йорт) һәм карагаш исемле төп төркемнәренең (борынгы кабиләләренең) традицион мәдәниятенә бәйле, шулай ук алар арасында таралган башка төркемнәргә дә хас хушаваз үрнәкләрен үз эченә ала.

Әстерхан өлкәсе татар авылларында яшәүче халыкта сакланган татарча җырлар 1998–2000 елларда Казан дәүләт консерваториясе тарафыннан оештырылган экспедиция вакытында ноталары белән язып алынган. Әстерхан шәһәренә һәм Әстерхан өлкәсенең Идел буе, Нариман, Началов, Володар, Краснояр һәм Хәрабәле районнары авылларына оештырылган экспедициядә барлыгы 16 авыл тикшерелгән. Болар – Хәрабәле районында Лапас; Краснояр районында Яшен-Суккан, Сәетләр (Сеитовка), Растопуловка; Володар районында Кундрау (Тулугановка); Идел буе районында Киләче (Килинчи), Җәмәле (Три Протока), Кызан (Татарская Башмаковка), Мәйле күл (Яксатово); Нариман районында Сүләнкә (Солянка), Картузан (Курченко), Төлкетөбә (Туркменка), Яңа Аскәр (Янго-Аскер), Кәменни (Линейное), Иске һәм Яңа Каңга (Кучергановка) авыллары.

Хушаваз һәм башка лирик җыр текстларын, ноталарын, аудиоязмаларын туплаган зур җыентык 2007 елда басылып та чыкты [Памятники...], әлеге җыентыктагы үрнәкләр Әстерхан татарларындагы популяр җырларның музыка белгечләре тарафыннан бәяләнгән булуы белән кыйммәт.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы экспедиция материаллары арасында хушаваз текстлары шулай ук шактый очрый. 2013 елда Институттан бер төркем галим һәм аспирантлар Әстерхан өлкәсе Идел буе районында татарлар яши торган Киләче (Килинчи), Җәмәле (Три Протока), Ярлы Түбә (Осыпный Бугор), Кызан (Татарская Башмаковка), Мәйле Күл (Яксатово), Каргалык (Карагали) һәм Нариман районындагы Каңга (Кучергановка) авылларында комплекслы фәнни экспедициядә булдылар. Әлеге экспедиция материаллары арасында телче һәм фольклорчы галимнәр Әстерхан татарларында киң таралган хушавазларга зур игътибар бирделәр, үзләрен нугай татарлары дип атаучы информантлардан хушаваз текстларын яздырып алып һәм беренчел эшкәртеп, аларның күпчелеген фәнни җыентыкта бастырып чыгаруга ирештеләр [Милли-мәдәни...]. Моннан тыш 2014 елда Чиләбе өлкәсе Нязепетровск, Чибәркүл, Уй, Нагайбәк районнарына карый торган күпчелек татар авылларына, 2017 елда Татарстанның Мөслим, Минзәлә районы авылларына Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплекслы фәнни экспедиция вакытында җыелган фольклор материаллары арасында да хушаваз жанрына керә торган лирик иҗат үрнәкләре шактый. Институт уздырган экспедицияләрдә информант авызыннан язып алынган хушаваз текстлары, кәгазьгә төшерелгәннән соң, жанры билгеләнеп, «Милли-мәдәни хәзинәләребез. Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә чыгып килә торган коллектив монографияләрдә апробация узды. Биредә хушавазлар, моңа кадәр билгеләнгән белән чагыштырып, фольклор үрнәкләре буларак анализлана, текст беренче кат басылып чыга.

«Татар халык иҗаты. Җырлар» академик томнарының бүгенге көндә төзелеп бетү этабында торган «Татар халык иҗаты. Традицион һәм халыклашкан лирик җырлар (халыктан соңгы ярты гасырда тупланган лирик иҗат)» юнәлешендә исемләнәчәк томына материал туплау эшендә югарыда саналган җыентыкларга кертелгән хушавазлар чыганак ролен башкара, әлеге хушаваз текстлары киң файдаланыла. Моннан тыш, төрле төбәкләрдә яшәүче татарларның традицион музыкасына багышланган башка басмаларда очрый торган хушаваз үрнәкләре дә игътибарга алына [Азиатский...; Мошков; Нигъмәтҗанов, 1976; Нигмедзянов, 1982; Арсланов һ.б. ].

Хушавазларның иң зур күпчелеге Әстерхан татарларында сакланып калу бик кызыклы.

Билгеле булганча, Әстерхан өлкәсе татарлары Идел елгасының түбән агымында урнашкан Әстерхан шәһәрендә һәм аның тирә-ягындагы районнарда аерым авыллар булып көн итәләр. Әстерхан татарларының этник төзелеше бер төрле генә булмыйча, төрки телле этник төркемнәр җыелмасын тәшкил итә. Ул җыелма Әстерхан шәһәре һәм Әстерхан өлкәсендә урта гасырлар заманыннан ук яшәп килгән нугай татарлары, шулай ук Урта Идел, Кама, Урал төбәкләреннән күчеп утырган татарларның этник төркемнәр вәкилләреннән тора. Нугай татарлары, үз чиратында, тел, территориаль, көнкүреш-хуҗалык үзенчәлекләре буенча аерылып торган берничә төркемгә бүленә. Алда әйтеп үтелгәнчә, алар кариле нугайлары һәм карагашлардан башка, татарларның кундырау, алабугат һ.б. төркемчекләренә аерыла. Моннан тыш, Урта Иделдән күчкән татарлар мишәр һәм урта диалект вәкилләренә бүленәләр. Бу үзенчәлекләр аларның җыр-музыка иҗатларында чагылмый калмаган.

Әстерхан татарларының полиэтник төзелмәле булулары аларның музыкаль-шигъри традицияләренең дә бер генә төрле түгел, күп компонентлы булуына китерә. Әстерхан өлкәсе территориясендә яшәүче һәр төркитатар этник төркемнең үзенә хас традицион жанр комплексы бар. Әмма алар аерым үсеш алмаган: өлкәдәге тарихи һәм этник процесслар күрше төркиләр белән мәдәни бәйләнешларга керү нәтиҗәсендә төрле музыкаль-шигъри катламнарның үзара тәэсир итешүләренә китергән. Әстерхан татарлары өчен бу процесс индивидуаль төсмер алган һәм аларның традицион җыр-көй һәм инструменталь жанр формаларына хас аерым үзенчәлекләр хасил булган. Аларда хушаваз лирик иҗатының аеруча популярлыгы да шуны раслый.

Әстерхан татарлары җырларында әдәби телдән морфологик һәм лексик характердагы тайпылышлар еш очрый. Кайбер хушавазларда җырны әйтүченең сүзләре табышмакны хәтерләтә, хушавазларда бүгенге көн укучысы өчен аңлашылмаслык урыннар очрап куя. Хәтта сүз ни турында бара дигән сорауга һәрвакыт җавап табылмаска да мөмкин, әмма җыручы хушавазны ахыргача башкарып чыга. Мондый текстлар әдәби әсәр закончалыкларына һәм нормаларына сыешып бетә алмый. Теле, фикер сөреше җәһәтеннән хушавазларның кайберләрен аңлауда кыенлык тууны жанрның борынгылыгы, татар теленең этник төркемнәрендә тел байлыгының гаять күп төрлелеге һәм нугай теле тәэсире белән аңлатырга мөмкин.

Әстерханда яшәүче милләттәшләребездән тыш, хушавазлар татарлар яши торган башка төбәкләрдә дә очрый. Төмән һәм Омск өлкәләрендә яшәүче татарларда, Удмуртия Республикасында, шулай ук Татарстан авылларында да җырны хушаваз белән башкару әлегәчә сакланган. Шунысы кызыклы: тикшерү-өйрәнү барышында төрле төбәкләрдә язып алынган хушавазларның вариантлылыгы ачыклана. Әйтик,

«Яттым, я Алла...», «Салават», «Үгет-нәсыйхәт», «Аятелкөрси» «Моңнар», «Вакыт җиткәч, чаралар юк» кебек ядкәрләр Әстерхан татарларыннан язып алынган хушавазлар рухын хәтерләтә, аларның көе үзенчәлекле булырга мөмкин, әмма текст нигездә кабатлана, башка төбәктә язып алынган хушавазның вариантын тәшкил итә. Шунысы да бар: Татарстан авылларында башкарылган хушавазларның күбесе мөнәҗәт жанры белән җыр жанры чигендә торган иҗат, аларның тематикасы дин һәм әхлак тәрбиясеннән, шушы өлкәгә карый торган үгет-нәсыйхәттән гыйбарәт, информант аны «хушаваз» дип башкармый, «мөнәҗәт» әйтәм, дип тәкъдим итә. Әстерхан татарларында «Әйт, дисәгез, мин әйтәм» кебек гыйбарәләрне Казан татарлары йогынтысы кичергән төбәкләрдә «Укы, дисәгез, укырмын» гыйбарәсе алыштыра. Бу – тел-авыз иҗатының язмага күчүе, язма фольклор формалашу белән бәйле күренеш, хушавазны информант кәгазьгә теркәп куйган булырга да мөмкин. Хушавазлар, кагыйдә буларак, лирик характерда була.

Хушавазларны әдәби сүз сәнгате буларак кына түгел, аның көе, башкарылу үзенчәлекләре белән бергә кабул итү һәм җыр сәнгатенең үзенчәлекле төре дип бәяләү мөһим. Күләме белән шактый озын хушавазлар бар. Әйтик, «Җиңүләр булды бер талай...», «Һич бу бер ялган дөньяда...», «Авырлык төште ил-йортка», «Советка чыгарылган җыр» кебек хушавазларда чичәннең хискичерешләре белдерелү, ягъни, лирика белән белән беррәттән, эпиклыкка да урын табылган. Боларны тарихи җыр характерындагы хушавазлар дип тә билгеләргә мөмкин булыр иде. Чыннан да, шактый күләмле тезмәләрдә чынбарлык вакыйгалары да телгә алынган, шул чор рухы чагылыш тапкан. Әмма биредә чичән, тарихи эпик фольклорга хас булганча, нейтраль позициядә калмый, җырда хушаваз башкаручының лирик кичерешләрен тасвирлау өстенлек итә. Тарихилыкка да дәгъва итә торган мондый хушавазларда текстны башкаручы теге я бу вакыйгага мөнәсәбәттә үз бәясен белдерми калмый, «Белгәнемне сөйләдем», «Гыйбрәт алыгыз яхшыдан», «Төшенеп, колак салыгыз» кебек гыйбарәләр белән ул тыңлаучы аудиторияне үз фикеренә колак салырга, аныңча эшләргә өнди. «Ырусия – безнең ил...», «Мин әйтсәм, кем тыңлар соң?» кебек хушавазларда, мәсәлән, чичәннең колхозны мактавы, совет хакимиятенә дан җырлавы кебек, бүгенге көн укучысы өчен артык төче тоелган яисә искергән карашларны гәүдәләндергән аһәңнәр дә яңгырый. Яисә «Ай, уникенче апрель...» дип башланып киткән алты куплетлы озын җыр совет чорында галәмгә чыккан космонавтларга багышлана, алар шушы вакыйгалардан илһамланып җыр чыгарган чичән-җыручының иҗатыннан гыйбарәт. Хәлбуки, болары да – халкыбыз мирасы, үз чоры өчен характерлы идеологияне чагылдыра, бүгенге көндә актуаль түгел дигән сылтау белән мондый әсәрләрне сәхифәдән сызып ату хаклы булмас иде. Күптән үткән

вакыйгалардан алып, хушавазларда хәзерге көн вакыйгалары да чагылырга мөмкин. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышы, фаҗигале үлем һ.б. вакыйгалар турындагы хушавазлар бар. Бигрәк тә Әстерхан татарларыннан язып алынган хушавазлар арасында халыкның килеп чыгышы, СССР төзелү һәм совет җәмгыяте үсеше, Бөек Ватан сугышы, беренче совет космонавтларының галәмгә очышы хакында бәян итә торганнары еш очрый.

Татарларның традицион мәдәниятендә хушаваз һәм җыр (бигрәк тә мөнәҗәт дип башкарыла торган иҗат) бер-берсенә якын яңгыраш алган – алар бер үк этник мохиттә, охшаш иҗтимагый-гамәли максатта еш кына бер үк башкаручының репертуарына керәләр. Хушавазны, гадәттә, олы яшьтәге ир-ат туган-тумачалар җыелганда яисә авылдагы бәйрәм тантаналарында тыңлаучылар өчен башкара. Музыка белгечләре хушаваз көйләренең музыкаль стиль нисбәтеннән дә аз аерылуларын, ягъни аерым-аерым хикәяләнә торган шигъри текстларның бер үк көйгә башкарылырга мөмкин булуын ассызыклыйлар [Памятники..., с. 4]. Интонацион яктан хушавазларга декламацияләү, көйләмле иҗекләрнең (слогораспевларның) бик аз булуы, түбән төшмәле хәрәкәт, минорга авышлы диатоник ладларга таяну (эолий, локрий, дорий, фригий һ.б.), иҗек-ритмлы изосиллабизм, тирада принцибындагы композицион шәкелләндерү күренешләре хас.

Хушавазлар җыр жанрында шигъри текстларның эчтәлеге, композицион төзелешенең үзенчәлекле булулары белән аерылып торалар. Хушавазларның сюжет эчтәлеге башкаручыларның үз тормышлары тәҗрибәләренә нигезләнә яисә ата-бабалар васыятьләре итеп, үгет-нәсыйхәт шәкелләрендә шигъри әйтелмәләр белән баетылып бирелә. Кагыйдә буларак, аларда берәр мәҗлеснең (гадәттә туй йоласы) ничек узуы хакында сүз алып барыла, җырчы-импровизатор башкаруында өлкәннәрнең дидактик киңәшләре бирелә, үз кабиләсе, халкы һәм туган ягы турында сөйләнелә. Хушавазларны хикәяләү фабуласыз була, тематик блоклар теземе барышында аларның һәркайсы үз эчендә сюжеты һәм мәгънә бәйләнеше булмаган хәлдә башкарыла, алар сан ягыннан да чикләнмәгән. Бу ягы белән хушавазлар һәрвакыт нинди дә булса бер сюжет белән бәян ителә һәм эзлекле бер темага багышлана торган җырлардан аерылып тора, ә эпос жанрына якынлаша төшәләр. Әстерхан татарлары эпик традициясендәге хушаваз термины казакъ культурасындагы җыр мәгънәсенә якын.

Җыручы башкаруындагы хушавазлар – халык мәдәниятенең үзенчәлекле кадерле ядкәре. Лирик җырлар төркемендәге әлеге иҗатны үзенчәлекле сүз сәнгате, музыкаль башкарылышы, шулай ук тыңлаучыга тәэсире һәм, әлбәттә, халык җырлары классификациясендә тоткан урыны җәһәтеннән махсус өйрәнү көн кадагындагы мәсьәлә булып кала.

**Әдәбият**

Азиатский музыкальный журнал, издаваемый И. Добровольским. Астрахань, 1816–1917 гг. // Рыбаков С. Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта. СПб., 1897. С. 297–315.

*Арсланов Л.Ш.* Язык карагашей-ногайцев Красноярского и Харабалинского районов Астраханской области (Грамматический очерк. Тексты и переводы. Словарь). Набережные Челны, 1992.

*Жирмунский В.М.* Некоторые итоги изучения героического эпоса народов Средней Азии // Вопросы изучения эпоса народов СССР. М.: Изд-во АН СССР, 1958. С. 24–65.

Источники древнетюркской и татарской литературы. Казань: Изд-во Казан. ун-та , 1981. 248 с.

*Макаров Г.М.* Дәрвишләрнең сөхбәтендә: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 159 б.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Әстерхан татарлары. Фәнни экспедицияләребез сәхифәсеннән. Казан: ТӘһСИ, 2017. 420 б.

*Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. 400 б.

*Мошков В.А.* Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края // Известия общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. Т. 12. Вып. 1. Казань, 1985; Т. 14. Вып. 3. Казань, 1897; Т. 17. Вып. 1. Казань, 1901.

*Мөхәммәдьяр.* Төхфәи мәрдан. Нуры содур / URL: http://kitap.net.ru/muhammadiar.php (мөрәҗәгать ителде: 4.05.2018).

*Нигмедзянов М.К.* Народные песни волжских татар. М.: Советский композитор, 1982. 135 с.

*Нигъмәтҗанов М.Н.* Татар халык җырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 216 б.

Памятники татарского народного музыкально-поэтического творчества. Вып. 1. Песни Астраханских татар. Әстерхан татарлары җырлары. Сост. и нот. транскр. Е.М. Смирновой и Н.Г. Гайнуллиной. Казань: Казанская консерватория, 2007. 550 с.

Таһир белән Зөһрә // Татар халык иҗаты. Дастаннар / төз. Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 206–248.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты халык иҗаты бүлегенең баш фәнни хезмәткәре*

УДК 81.373

***Л.Х. Дәүләтшина***

# АПАС ТӨБӘГЕ СӨЙЛӘШЛӘРЕНДӘ «ҖЕН» ПЕРСОНАЖЫНА БӘЙЛЕ ЛЕКСИКА

В данной работе проанализирована мифологическая лексика татар нагорной стороны, связанная с наиболее активным персонажем нечистой силы «җен», который может свободно замещать некоторые другие, принимая на себя их специфические функции. Автором представлены материалы к словарю мифологической лексики. В основу словаря положен лексический принцип с элементами идеографического: выделены пучки релевантных признаков и функций для персонажа.

**Ключевые слова:** этнолингвистика, словарь, персонаж, обряд, лексика.

Тел – ул милли тарихыбызның чагылышы. Анда халыкның үткәне, бүгенгесе, мәдәни багланышлары, дөньяга-карашы, ышаныч-өметләре чагылыш таба. Халык сөйләшләре элек-электән галимнәрнең игътибарын җәлеп итеп килде. Татар халкының җирле сөйләшләре дә инде бер гасыр дәвамында өйрәнелә. Дөнья әйләнәсендә барган үзгәрешләр, әлбәттә, телне дә читләтеп узмый. Тел һаман алга бара, үсә, үзгәрә. Әмма шул ук вакытта телдә халыкның этномәдәни байлыгы, инде яшәештән төшеп калган мәдәни күренешләрнең исемнәре-атамалары саклана килә. Димәк, халыкның тарихын, рухи һәм матди байлыгын өйрәнүнең төп чыганагы ролен телнең лексик составы үти. Этномәдәни лексика исә халыкның үткәнен һәм бүгенгесен сурәтләп кенә калмый, ә бәлки аның бай рухи тормышын да күз алдында тергезә, көндәлек яшәештән төшеп калган күренешләрнең, ышану-йолаларның асылын аңларга ярдәм итә. Бу юнәлештә эзләнүләр алып барган белгечләр (Ф.С. Баязитова, Ф.Ю. Юсупов, М.И. Әхмәтҗанов, Г.Ф. Мөхәммәтова һ.б.) өчен халык мәдәниятенең һәр тармагы кызыклы. Бу мәкаләдә төп игътибар «мифологик лексика»га юнәлтелә, чөнки татар һәм башка халыклар мифологиясе мифологик персонажлар турындагы күзаллауларны гына түгел, ә бәлки алар белән бәйле функцияләрне (куркыту, адаштыру, яклау, басу, зәхмәт җибәрү һ.б.), мифологик образларга бәйсез мотивларны (абага чәчәген табу, хәзинә эзләү һ.б.), мифологик лексиканы үз эченә алган катлаулы система буларак билгеләнә [Виноградова, Толстая, 1994, с. 16–44]. Мифологик лексика төшенчәсе мифологик персонажларның исемнәрен, хәрәкәт атамаларын, аларның тышкы кыяфәтләрен, кешеләр белән мөнәсәбәтенә бәйле төшенчәләрне, мифологик персонажлар белән бәйле хәлләрне аңлатырга мөмкинлек бирә.

Биредә татар традицион мәдәниятендә таралыш тапкан

түбән рухлар хакындагы ышанулар системасында иң актив персонажларның берсе булган «җен» образына бәйле лексика анализланды. Ислам дине өйрәтүләре аша татар традицион мәдәниятендә үз урынын яулаган әлеге персонаж белән бәйле ышанулар Гарәбстан территориясендә VI–VII гасырларда яшәгән халыклар арасында ислам динен кабул иткәнче үк киң таралыш тапкан булган. Мөселман традициясе буенча, Аллаһы Тәгалә җеннәрне уттан яраткан һәм аларга аң биргән, дип исәпләнелә. Җеннәрнең күбесе Иблис белән бәйле булса да, кайберләре ислам динен кабул иткән [Мифы народов мира, с. 374], шуңа күрә халык ышануларында алар «шәйтани» һәм «мөселман» җеннәренә аерыла.

Татар халкының бүгенге көн мифологик күзаллауларында җен, бер яктан, кешегә зыян китерердәй персонажларны алыштырып килә, икенче яктан, аның үзенә генә хас функциональ кыры да оеша. Экспедиция барышында язып алынган текстларда информантлар әлеге персонажны *җен, чин, чин-сәхмәт, җен-зәхмәт, шайтан, зәхмәт* дип атыйлар. Җен көндәлек тормышта күзгә күренеп йөрми, ул гаиләсе белән параллель дөньяда яши, әмма, үзенә кирәк булганда, кеше, берәр әйбер, табигать күренеше һ.б. кыяфәтләргә керергә мөмкин. Җеннең яшәү урыны буларак халык телендә иң еш искә алына торган урын (лат. *локус*) – мунча, шуңа да мунчага тамак кырып керү кабул ителгән, кояш баегач, көн уртасында һәм төн уртасында керү тыелган [Дәүләтшина, 2017, б. 88].

Җен белән бәйле фольклор текстлары күпчелекне тәшкил итсә дә, алар нигездә берничә сюжетка кайтып кала. Җен кешенең яши торган йортына үтеп кереп, йортка бәла-каза алып килергә мөмкин, шуңа күрә дә әлеге персонаждан саклану чаралары бүгенге көндә дә актив кулланыла (ишек өстенә ат дагасы, артыш таягы кую; ишекләрне, ризык өсләрен бисмилла әйтеп ябу, тәрәзә төпләренә ризык куюны тыю һ.б.). Әлеге мифик затның зәхмәте кешегә йорт эчендә генә түгел, ә бәлки юлда, җиде юл чатында, пычрак урында, ташландык нигезләрдә дә тияргә мөмкин.

Җеннең эшчәнлеге күп очракта бала алыштыру белән бәйле. Адәм баласын җен юкка гына урламый. Урланган бала үсеп җиткәч, җеннәр арасында имче функциясен башкара, чөнки кешегә җен зәхмәте кагылган шикелле, җеннәргә дә адәм зәхмәте йогарга мөмкин икән. Персонажның әлеге функциясе баланы саклау белән бәйле гамәлләр комплексын да барлыкка китерә (баланы һәм көмәнле хатын-кызны ялгыз калдырырга ярамый; ялгыз калдырырга туры килгән очракта янына тимер әйбер, сарымсак, артыш таягы, миләш ботагы куярга кирәк һ.б.).

Гомумән алганда, халык телендә җен дип аталып йөртелгән персонаж ислам дине өйрәтүләре нигезендә таралыш тапкан булса да, бүгенге көндә исемнәре, генезисы, тышкы кыяфәте ягыннан мөселман традициясенә якын-

лыгын саклаган хәлдә, функциональ яктан, татар халкының мифологик күзаллауларына бәйле рәвештә, шактый баеган һәм үзгә персонажга әверелгән.

Түбәндә Апас төбәгендә яшәүче татарларның телендә актив кулланылышта булган җен персонажына бәйле мифологик лексика урын алды. Иң беренче итеп, персонажның җирле сөйләшләрдә кулланылышта йөргән исемнәренә, алар белән бәйле күренешләргә аңлатма бирелә. Әгәр дә персонажның исеме сөйләштә тотрыклы конструкцияләр төзүдә катнаша икән, әлеге әйтелмәләр дә күрсәтелә, аларның мәгънәсе аңлатыла. Һәр төшенчә диалекталь вариантта китерелә, аның аңлатмасы бирелә һәм әлеге лексема кулланылган фольклор текстларының вариантлары күрсәтелә (аңлатмалар – рус телендә, ә текстлар татар һәм рус телләрендә бирелде, чөнки әлеге материаллардан башка халык вәкилләре дә файдаланырга мөмкин). Бу төр эзләнүләрне әлеге юнәлештә беренче адым дип исәпләргә кирәк, чөнки максатка ирешер өчен һәр сөйләш, һәр диалект мифологик контекстка бәйле рәвештә анализланып чыгарга тиеш. Шул чакта гына татар теленең мифологик лексикасын туплаган этномәдәни сүзлек турында сүз алып барырга мөмкин.

* * *

**Җен** – демонический персонаж, выступающий в качестве обобщенной фигуры для всей нечистой силы.

*Элек күп булган җен. (Раньше было много джиннов).* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Багишево).

*Җен бар ул, бар, җенсез ни юк. (Джинны есть они, есть, без джиннов ничего нет)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Бакрче).

*Ятам. Йемшек кенә нәрсә менә. Тотам, этеп җибәрә. Әни әйтә: «Нишлисең», – ди. Менә шулай дип әйттем. Җен ул, дип, әнкәй үз янына чакырды. (Лежу, мягкое что-то. Дотрагиваюсь, отталкивает. Мама говорит: «Что ты делаешь?» Ей сказала. Мама сказала, что это джинн и позвала к себе)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Тявгельдино).

*Безнең бер күрше әби барие монда килгәчтен. Кояш баегач суыңы түкмә, диде. Кыйблага каршы карап атма суны. Әгузе бисмилланы әйтеп ат, диде. Бисмилласыз аткан су, диде, шишага җеннәр килеп тутырыр икән, үлгән чагында шул суны сиңа күрсәтер икән, дип әйтәләр ие инде. (У нас была бабушка-соседка. Она говорила, что нельзя выливать воду после заката солнца. Не выливай ее, в сторону киблы. Когда выливаешь, нужно произносить «Әгузе бисмилла». Воду, вылитую без бисмиллы, соберут джинны, наполнят ею бутылку и дадут выпить после твоей смерти)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Деушево).

**Җен богаулану** – наложить путы на джиннов.

*Хәзер богаулandылар җеннәр уразада... Богаулана Уразада, анда гыйлем җеннәре генә кала. (Во время уразы на джиннов*

*накладываются путы. Остаются только мудрые джинны)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Тявгельдино).

**Гыйлем җеннәре** – мудрые джинны (доброжелательные персонажи нечистой силы) / **Мөселман җеннәре** – праведные джинны.

*Ул шәйтани җеннәр бар, гыйлем җеннәре бар. Кайбер ишесе бик каты белгәчтен, моны гыйлем җеннәре өйрәткән дип әйтәләр иде әбиләр безнең. Менә догаларны бик белә, бик каты дин буенча белә инде. Аны төннә гыйлем җеннәре эрәтә дип әйтәләр ие әбиләр... Алары яхшыдыр, күрәсең, яхшыдыр. (Есть плохие джинны, а есть мудрые джинны. Если некоторые (люди) много знали, бабушка говорила, что их обучали мудрые джинны. Молитвы вот знает, по религии много знает. Говорят, что их ночью обучают мудрые джинны. Они хорошие, видимо, хорошие)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Черемшан).

**Шәйтани җеннәр** – джинны-шайтаны (вредоносные персонажи нечистой силы) / **Начар җеннәр** – плохие джинны.

*Шәйтани җеннәр зәхмәтләр, ниләр эшли инде сиңа, начарлыклар эшли. Элек бит мунчаны иртә белән җагалар ие. Менә Югары Балтайда җен тыккан икән башын дип (әйтәләр иде), аның чәчләре дә югие, битләре дә әллә ниндие. Мунча җагарга баргач, башын тыгып куйган икән мунчага дип ишеткәнем бар. Утка тыккан икән ди-ди. Ничек үлмәгәндер. Чәче дә җугие, бите дә бик ни ие. Хатын-кыз. Менә шуңа күрә тамак кырып керергә кушканнар инде. (Джинны-шайтаны вредят тебе. Раньше баню рано топили. В В. Балтае говорили, что джинн засунул человека головой в печь. У него и волос не было, и лицо какое-то было. Когда пошел баню топить засунули его. В огонь засунули. Как он не умер. И волос не было, и лица. Женщина. Поэтому и говорят, что нужно оповестить о том, что идешь)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Бакрче).

**Җен табыны** – стол, накрытый джиннами (участок дороги, грязное место, заброшенные дома при переходе через которые человека заболевает).

*Җен табыннары була инде ул. Әшәке төштә була ул. Тизәкле, ниле. Берәү борчак чабырга барган. Бу шул төштә җатып йоклаган. Арбага тияп апкайттылар аны. Шуның белән үлде дә ул. Без табын ничек корабыз, алар шулай кора икән. Ашап-эчеп утыра икән алар. Минем үземә дә очрады ул җен табыны. Кыз чагында. Апалар безнең кич утыра. Апа әйтә, бар әле гармунны аптөш әле, ди. Кайтам, койма буена ак таш үгән ие әле. Шул төшкә җиттем, бөтен урам тулды халык белән. Җен табыны шул булган. Бөтенесе кеше менә. Әнкәй чыкты да: «Нишлисең?» – дип кычкырып җибәрде. Урамда бер кеше калмады. Әнкәй әйтә: «Нишләп сикереп торасың анда». Әнкәй эндәшмәгән булса, нәрсә дә булса булган булыр иде. (Бывают столы, накрытые джиннами. Они бывают в плохих местах. В грязных. Кто-то*

*пошел косить горох. Лег там и уснул. В телеге его привезли. Так и умер он. Как мы накрывам на стол, так же и они накрывают. Едят и пьют оказывается. И я наткнулась на такое место. Когда девочкой была. Сестры наши вечером выходят гулять. Сестра мне сказала принести гармонь. Иду домой, около нашего забора белый камень был. Дошла до этого места, вся улица наполнилась людьми. Все люди. Мама вышла и закричала: «Что ты делаешь?» Никого не осталось на улице. Мама говорит: «Почему ты прыгаешь? Если бы мама не позвала меня, что-нибудь случилось бы»)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Бакрче).

**Җен табынына очрау** – встретить стол, накрытый джиннами.

*Шуны ишеткәнем бар. Җеннәр табынына очрадым. Кулуkуллар таккан, атлар җиккән, артымнан куаладылар дигәнне ишеткәнем бар. (Слышала кое-что. Повстречался стол, накрытый джиннами. С колоколами, с запряженными лошадьми за мной гнались, говорят)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. В. Балтаево).

**Җен табынына басу** – наступить на стол, накрытый джиннами.

*Мин безнең авылда бер әби барие. Тормый торган нигез аркылы чыккан. Менә шул кояш баегач, тормый торган нигезләрдән чыгарга ярамый дип, силәшәләр иде әниләр. Ул телсез калды, түлке бүтән сүзне әйтми. «Әй, алла», аның бар сүзе. Менә аңа син сүз яшәсең, ул сиңа «Әй, алла», дип җавап бирә. Менә шул җен табынына баскан дип әйтәләр ие. (У нас в деревне жила бабушка. Она прошла через заброшенный дом. Родители говорили, что после захода солнца нельзя ходить в местах, где никто не живет. Он потеряла дар речи. Говорит только: «О, боже». Ты ей что-нибудь говоришь, а она тебе отвечает «О, боже». Говорили, что она наступила на стол, накрытый джиннами)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Багишево).

**Җен җулы** – тропинка джиннов (тропинка для нечистой силы).

*«Тәрәзә төбе – җен җулы», – диләр. (Говорят, что подоконник – это дорога джиннов.)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Бакрче).

*Тәрәзә төбенә ризык куймагыз, җен җөри торган урын. (На подоконник ничего не ставьте, это место, где ходят джинны)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. В. Балтаево).

**Алыштыру** – подменить (подмена нечистой силой ребенка своим).

*Бер хатын бар ие. Аның малае булган. Шулай бишеккә салган инде. Аның малаен җен алыштырган. Бишеккә салган, малай үзенеке түгел. Шулай малайны күтәреп алган да, күтенә суга-суга ишек бусагасына илтеп куйган. Син үзеңнекен үзең апкит, минем үземнекен үзең китер, дип әйткән. Китереп куйды, ди. Җен иләмсез, ди. Зәгыйфь була алар. Озак яшәми алар.*

*Аның җанына пычак, я качы куялар малай башына. Килми инде аннан соң. (Жила одна женщина. У нее был ребенок. Положила она его в люльку. Ее ребенка подменил джинн. Смотрит, ребенок не ее. Подняла она его и, стукая по мягкому месту, отнесла на порог. Сказала: «Ты унеси своего, мне принеси моего». Принес, говорит. Дитя джинна бывает некрасивым. Они долго не живут. Рядом с ребенком надо положить нож или ножницы. Не приходит потом)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Бакрче).

**Иләшү** – повадиться (о приходе нечистой силы к одинокой женщине).

*Җен иләшкән булган икән бу хатынга. Ул табагачка атланып, сүгенеп куып чыгара икән аны ишектән. Өендә атланып-атланып, сикреп-сикреп йөри икән дә, ишек төбенә сөяп куеп, «Барыгыз чыгып китегез, күземә күренмәгез», дип сөяп куя икән, ди. (Джинн повадился ходить к этой женщине. Она его прогоняла, сев на ухват и бранясь. Садится на ухват и прыгает по дому, затем прислоняет его к двери и говорит: «Идите, уходите, не показывайтесь мне на глаза»)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Черемшан).

*Кайсы кеше ирсез кала бит инде яшьли. Ирсез кала, аңарга иләшә диләр. Менә бездә бар ул арҗакта бер хатын. Менә аңарга иләшкән диде җен. Бүтән кешенең малае булып килә, ди, җанына. Ясин чыгасы, ди, аңа. Аңар җиде кеше алып килеп укыталар, ди, инде җортта. Җиде көнгә хәтле укыйлар инде алар. Кайсы инде чатлыкка мылтыктан атарга кирәк дип тә әйтәләр. Куарга, ди, ди. Ир кеше ата инде, ир кеше. Бар инде ул иләшкән кешеләр. Зәгыйфь калучылар да бар иләшкән нигә. (Некоторые смолоду остаются вдовами. Без мужа живет, к ней джинн приходит, говорят. У нас тоже была такая женщина. Вот к ней повадился ходить джинн. Приходит в образе ребенка другой женщины. Надо прочитать суру Ясин. Семь человек собираются в доме и читают. До семи дней они читают. Некоторые говорят, что нужно стрелять по углам из ружья. Чтобы прогнать. Мужчина стреляет, только мужчина. Бывают такие люди, к которым повадился джинн. Больными остаются некоторые)* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Тявгельдино).

**Сыптыру** – погладить (нечистая сила забирает ребенка из чрева матери, погладив живот).

*Ана карынында чагында әйтәләр аны. Менә шулай бер сыптырса, бала төшә ди, ди. Эчтән җен бер генә сыптыра, ди, ул. Аска таба сыптырып бала төшә, ди. (Об этом говорят, когда ребенок в чреве матери. Вот так гладит и случается выкидыш. Джинн гладит живот. Гладит и случается выкидыш).* (Республика Татарстан, Апастовский район, д. Черемшан).

## Әдәбият

*Әхмәтҗанов М.* Татар археографиясе. Соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кульязмаларның тасвирламалары. Сигезенче кисәк. Казан, 2011. 287 б.

*Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан, 1997. 248 б.

*Баязитова Ф.С.* Себер татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор. Казан, 2001. 309 б.

*Виноградова Л.Н., Толстая С.М.* К проблеме идентификации и сравнения персонажей славянской мифологии // Славянский и балканский фольклор. Верования. Текст. Ритуал. М., 1994. С. 16–44.

*Дәүләтшина Л.Х.* Татар халкының мифологик системасына бер караш // Фәнни Татарстан. 2017. №3. Б. 81–91.

Мифы народов мира: энциклопедия: в 2 т. / под ред. С.А. Токарева. М.: Большая Российская энциклопедия, 2003. Т. 1. С. 374.

*Мухаметова Г.Ф.* Актуальные проблемы этнолингвистического изучения говоров региона Восточного Закамья Татарстана // Тюркологический сборник: материалы Всероссийской тюркологической конференции «Языки и литература тюркских народов: История и современность». Елабуга: Изд-во ЕГПУ, 2006. Вып. 3. С. 374–376.

*Юсупов Ф.Ю.* Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты. Казан: Татполиграф, 2006. 607 б.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 297

*Д.З. Мәрданова*

# XIX ГАСЫРНЫҢ СОҢГЫ ЧИРЕГЕНДӘ ИДЕЛ БУЕ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ ХОКУКЫЙ ТӨШЕНЧӘЛӘРЕ ТАРИХИ СЕМАНТИКАСЫНА КАРАТА
## («иҗтиһад», «мөҗтәһид», «иҗмаг» терминнары хакында Ш. Мәрҗани һәм аның оппонентлары арасындагы бәхәс мисалында)

Экономические, политические, социальные и культурные изменения второй половины XIX века заставили мусульманских ученых искать ответы на вызовы Нового времени в рамках собственной традиции. В статье через полемику между Ш. Марджани и его оппонентов рассматривается пример переосмысления сложившихся ранее правовых и богословских понятий и представлений.

**Ключевые слова:** конец XIX века, Российская империя, Поволжье, Марджани, иджтихад, муджтахид, иджма‘, история понятий.

Телнең тарихи семантикасы яки төшенчәләр тарихы, нигездән үзгәртеп кору һәм һәм эволюция методы буларак, сәясәт белеме, фәлсәфә, социология, әдәбият белеме һәм тарих фәннәрендә файдаланыла. Төшенчәләр тарихы сәясәт белеме тикшеренүләренең ике төрле историографик юнәлештәге немец һәм инглиз (Кембридж) мәктәпләрендә барлыкка килә. Беренче юнәлешнең теоретик нигезләре «Германия иҗтимагый-сәяси теленең тарихи лексиконы» проектының җитәкчеләреннән берсе булган Р.Козеллек хезмәтләрендә формалаша. Әлеге проект кысаларында тарихи төшенчәләрне өйрәнүнең башлангычы булган «Төп тарихи төшенчәләр. Германиядә иҗтимагый-сәяси телнең тарихи сүзлеге» дип исемләнгән сигезтомлык зур хезмәт чыгарыла. Козеллек 1700 елдан алып 1970 елларны үз эченә алган иҗтимагый тарихчылар тарафыннан кулланылган катлаулы төшенчәләрнең семантик бәйләнешен ачыклый. Сүзлек мәкаләсенең нигезен теге яисә бу чор чыганаклары теле түгел, хәзерге тел тәшкил итә [Словарь..., 2014]. Тасвирланучы чынбарлыкның аерылгысыз өлеше буларак кабул ителгән сәяси теориянең телен өйрәнгән Дж. Покок һәм К. Скиннер хезмәтләре икенче юнәлешнең нигезен тәшкил итәләр. Икенче төрле әйткәндә, алар төшенчәләрне тарихи шартлар һәм контекстка бәйле булган тел аркылы өйрәнәләр. Кембридж мәктәбе юнәлеше «чынбарлык»ның барлык объектлары алар сыйфатлаган төшенчәләр ярдәмендә чагылуын искәртә. Скиннер карашынча, тарихта яңа идеяләр һәрдаим барлыкккa килеп тормый; бер темага мөрәҗәгать ителә һәм аерым бер төшенчә очраган төрле фикерләр аркылы телнең яңа-

лыгын һәм үзгәрешләрен күзәтеп була. Скиннер өчен шулай ук автор күздә тоткан интенция (автор нәрсә әйтергә теләве), яисә әлеге фикернең нинди дискурс эчендә барлыкка килүе, аның контекстуаль чолганышы мөһим булып тора [Скиннер, с. 12–74]. Икенче төрле әйткәндә, идеяне билгеләүче автор акторга – фикер уятка һәм яшәешен дәвам иткән бәхәснең, телнең агентына әйләнә. Пококка килгәндә, аның әлеге дисциплинага керткән методологик өлеше сәяси фәлсәфәнең тарихын «сәяси телләр», «идиомалар», «бәхәсләр» тарихы буларак караудан гыйбарәт [Атнашев, Велижев].

Безнең уебызча, дини әңгәмәбәхәсләрне өйрәнгәндә, Скиннерның төшенчәләр тарихы һәм контекстуаль анализы дини традициядә яшәп килгән хокук буенча өйрәтмәләрнең үзгәрешен, аларның әйләнә-тирә иҗтимагыймәдәни җирлек шартларына җайлашуын, адаптацияләнүен ачык күзаллауга ярдәм итә. Әлеге мәкаләдә XIX гасырның соңгы чирегендә Ш. Мәрҗани һәм аның оппонентлары арасында бәхәс уяткан «иҗтиһад», «мөҗтәһид», «иҗмаг» кебек ислам хокукы төшенчәләренең тарихи семантикасы өйрәнелә. Әлеге ракурс хокук төшенчәләре мәгънәләренең үзгәрешен һәм яңа төшенчәләрнең өстәлүен, барлыкка килүен ачыкларга мөмкинлек тудыра.

Мәкалә биш мәгънәви өлештән гыйбарәт. Беренче өлеш полемика контекстына кереш, икенче бүлек ислам хокукының төшенчәләрен тасвирлаучы кисәк булып тора. Өченче өлештә «иҗтиһад» термины һәм «иҗтиһад капкасы ябылу» мәсьәләсе күтәрелә, дүртенче кисәктә «мөҗтәһид» категориясенә карата төрле карашлар чагыла, бишенче бүлек «иҗмаг» мәсьәләсенә багышлана.

## Кереш яисә XIX гасырның соңгы утыз еллыгында Россия империясендә мөселманнар яшәешенең чынбарлыгы

XIX гасыр азагы – XX гасыр башында мөселман галимнәре арасында исламны ислах кылу идеяләре киң таралыш таба. Әлеге процесска Европа модерны нәтиҗәсендә мөселман җәмгыятендә барлыкка килгән идея кризисы этәргеч бирә. Көнбатыштан икътисади һәм иҗтимагый бәйлелектә яшәгән мөселман голямалары, М.Уотт билгеләвенчә, ислам дөньясының сәяси һәм икътисади бәйсезлеге турында төп мәсьәләләрне чишәргә тиеш булалар [Watt, p. 158; Hourani, 1983]. Мөселманнар, өстенлекләрен югалтып, «христиан» дөньясы шартларында яшәешнең яңа формаларын эзләргә мәҗбүр ителәләр. Тискәре үзгәрешләрнең барлыкка килүен галимнәр дөрес юлдан тайпылу, дингә (хокук һәм догматикага) тиешсез яңа үзгәрешләр кертелү белән бәйләп аңлаталар. Әлеге үзгәрешләрдән динне арындыру өчен реформалар яки ислах үткәрү идеясе тәкъдим ителә, ягъни әлеге ислахның төп максаты – зарарлы һәм дөрес булмаган гамәлләрне «төзәтү» һәм «яхшырту». Ислах динне тәҗдид кылу, ягъни яңарту, мөселманнар яшәеше өчен беренчел чыганаклар булган Коръән һәм

Сөннәткә нигезләнеп башкаруны күздә тота.

Россия империясендә яшәгән мөселманнар арасында дини яңарыш идеяләре XVII йөздә үк барлыкка килә, соңга таба XIX–XX гасыр башы мөселман галимнәре арасында киң тарала [Юзеев; Кемпер]. XIX гасырда, Идел–Урал регионында бай сәүдәгәрләр һәм сәнәгатьле мөселман буржуазиясе барлыкка килгәч [Салихов], аерым бер мөселман авторлары әсәрләрендә хакимият һәм җәмгыять тәнкыйтьләнә башлый. Ислам диненә карата күп кенә голямалар саклану позициясендә, ягъни руслардан чыккан яңарышларга карата сак булу ягында торалар. Русларга юнәлтелгән тәнкыйтьтән тыш, мөселман мәзһәбенең үзенең эчке кимчелекләре дә күрсәтелә, күп кенә бәхәсле темалар барлыкка килә. Мөселман галимнәре дини текстларны дөрес укуның заманга ярашлы яңа ысул һәм интерпретацияләрен тәкъдим итәләр.

Әлеге моназара-бәхәстә күренекле татар галиме, дин белгече һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) карашлары аерым бер урын били, хәтта кайбер замандашлары тарафыннан кискен тәнкыйтьләнә дә. Әлеге тәнкыйди карашлар аның 1870 елда Казанда «Нәзурәт әл-хак...» («Хакыйкатьне күзаллау») хезмәте басылып чыкканнан соң аеруча көчәя. Кемпер фикеренчә, автор үзенең бу хезмәтендә киләчәк буын мөселманнары өчен ислам диненең башлангыч чоры кыйммәтләренә нигезләнгән идеал җәмгыять төзү проектын сурәтли [Кемпер, б. 615]. Бу образга туры килмәгән үзгәрешләр ялгыш дип табыла һәм кире кагыла. Мәрҗани мөселман җәмгыяте тормышын әлеге юл белән тәҗдид кылырга, ягъни яңартырга чакыра. Мисал рәвешендә ул ‘иша – төнге ястү намазы мәсьәләсенә аеруча басым ясап, аны иҗтиһад хокукын исбатлауда куллана. Хокук мәсьәләләре, «Нәзурәт әл-хак...» хезмәтеннән тыш, Мәрҗанинең башка әсәрләрендә дә урын ала, аларга Казанда 1889 елда дөнья күргән «Хикмәт әл-бәлигат» һәм 1883 елда басылган «Вафийәт әл-эсляф...» хезмәтләрен дә кертеп карарга мөмкин.

Мәрҗанинең әлеге реформаторлык карашлары барлык замандашлары тарафыннан да хупланмый, зур бер төркем голямалар аның фикерләренә каршы чыга. Мәсәлән, Мәрҗанинең оппоненты Габдулла ән-Нәсавиның 1874 елда Казанда басылган, «Нәзурәт әл-хак...» фикерләрен тәнкыйть итүгә корылган «Әл-Җәрудә» хезмәтен китерергә мөмкин. Габдулла ән-Нәсавидән тыш, Мәрҗанинең татар дөньясына Ишми хәзрәт исеме белән танылган төп идея дошманы Әбү-Нәкыйб Түнтәри (1842–1919), Ишми хәзрәт мәдрәсәсендә традицион мөселман белеме алган Мөхәммәт эш-Шауләнкари [эш-Шауләнкари, Тазкират, б. 66], Динмөхәммәт бине Ярмөхәммәт бине Мансур эт-Түнтәри (1849–1919), Гыйләҗетдин бине Мөхиддин эс-Сәрдәви әл-Казани кебек мөселман зыялылары җирле традицияләрне саклап калырга

тырышулары һәм Мәрҗани карашларына каршы чыгучылар буларак танылалар. Шунысы да игътибарга лаек: тикшеренүдә кулланылган барлык хезмәтләр дә турыдан-туры Мәрҗанинең «Нәзурәт әл-хак...» китабына каршы язылмаган, аларның кайберләре Мәрҗани һәм аның дәвамчыларының карашларын гомуми рәвештә тәнкыйть итүгә корылганнар.

## Хокук төшенчәләре

Мөселман хокукының нигезе бер-берсенә бәйле булган ике төп чыганактан гыйбарәт. Беренче чыганакны Коръән һәм Сөннәтнең хокукый яссылыктагы өйрәтмәләре тәшкир итә. Аның нигезендә мөселманнарның әхлакый һәм дини вөҗданы формалаша [Словарь..., 1991, с. 292]. Икенче төркем үз эченә рациональ чыганакларга нигезләнеп, беренче чиратта, иҗмаг, ягъни теге яки бу дини мәсьәләгә карата абруйлы мөселман голямаларының (мөҗтәһидләр һәм фәкыйһларның) уртак хөкеме, аларның кыяс ярдәмендә системалашкан мөселман хокукы доктринасы нормаларын эченә ала [Сюкияйнен]. *Иҗмаг* – абруйлы илаһият галимнәренең аерым бер мәсьәләгә карата килештерелгән уртак фикере, мөселман хокукының бер чыганагы [Словарь..., 1991, с. 91].

Мәгълүм булганча, иҗмагның барлыкка килүе VII гасырның икенче яртысындагы мөҗтәһидләр эшчәнлеге белән бәйле. Алар аерым бәхәсле мәсьәләләрне тикшерүнең билгеле бер тәртибен тәкъдим итәләр. Кыяс – тиңләштереп карау, охшашлыкка нигезләнеп фикер йөртү. Ул – әрра’й, ягъни мөстәкыйль фикер йөртүнең бер категориясе, хокук буенча рациональ эзләнүләрнең берсе булып тора. Кыяс Коръән текстларына, Сөннәткә (әл-кыяс әш-шәригый) яисә танылган һәм дәлилле фактка таяна (әл-кыяс әл-гакъли) [Словарь..., 1991, с. 137]. Икенче төркемнең нормалары соңрак, Коръән һәм Сөннәттә чагылыш тапмаган мәсьәләләр белән очрашканда, яисә әле яңа гына мөселман диненә күчкән кешеләрнең ислам тәгълиматы нигезендә тормышларын төзү очракларында барлыкка килә.

## Иҗтиһад

Мәрҗанинең оппонентлары аның «иҗтиһад капкаларын ачу»ына каршы чыга. Мөселман хокуклары доктринасы күп еллар дәвамында ирекле иҗтиһад принцибына таянып үсеш ала. «Иҗтиһад» сүзе гәрәп теленнән «тырышу, эшкә күңел биреп эшләү, тырышлык – шаригать буенча, динне алга җибәрү максатыннан фәкыйһ, яисә ислам хокукы белгече тарафыннан барлык көчен юнәлдерү» буларак билгеләнә [Словарь, 1991, с. 91–92]. X–XI гасырларда хокук нормаларын тикшергәндә, иҗтиһадка мөнәсәбәт тә нык үзгәреш кичерә. Тора-бара ул Коръән һәм Сөннәткә таянып ирекле рәвештә хөкем чыгаруыннан туктап, төрле мөселман мәзһәбләре юнәлешен сайлау мөмкинлеге булып кына кала. Бу процесс «иҗтиһад капкалары ябылу» исеме белән йөртелә башлый. X гасыр башына (Һиҗридә IV гасыр) илаһият

галимнәре барлык мәсьәләләрне җентекле тикшереп, иҗмагта иҗтиһад капкаларын ябу карары чыгаралар. Әлеге консенсус күпчелек голямалар тарафыннан кабул ителсә дә, иҗтиһад хакында бәхәсләр вакыт-вакыт яңадан күтәрелеп тора. Бу исә, Вейл Халлак карашынча, фәкыйһларның әлеге хөкемне кабул итмәве буларак бәяләнә [Hallaq, 1984, p. 4]. Шулай ук дин белгеченең Коръән һәм Сөннәткә таянып иҗтиһад кылу өчен тиешле квалификациягә ия булу вакыты узу турында фикер урнаша. Әлеге вакыттан алып галим үз мәзһәбендә генә иҗтиһад кылырга тиеш була, бу иҗтиһад *тәхриҗ* дип аталып йөртелә башлый. Аны тормышка ашыру өчен катгый махсус билгеләнгән хокук нормалары барлыкка килә. Иҗтиһад чикләрен кысу нәтиҗәсендә, аның эчтәлеге дә үзгәрә, фәкыйһлар арасында доктрина тарафыннан күрсәтелгән тәкълид идеясе популярлашып китә [Hallaq, 1984, p. 4]. Мөҗтәһидләрнең дәрәҗәләре арту белән бергә, илаһият галимнәре арасында иҗтиһад кыла алучыларның саны кими төшә, аларның күпчелеге мөкаллид, ягъни традиция тарафдарлары *(каллада, таклид)* гына булып калалар дигән фикер мөселманнар арасында киң таралыш ала [шунда ук, б. 29].

Идел–Урал төбәгендәге тәкълид белән иҗтиһадны чагыштырып, М. Кемпер түбәндәге фикергә килә: тәкълид аерым метод буларак кабул ителми, ул иҗтиһад кебек динамик процессны тәшкил итә, төрле категорияләрдән гыйбарәт, һәм нинди дә булса актуаль бәхәстә үзең теләгән карашларны нигезләүдә ярдәм итә [Кемпер, с. 413–418]. Иҗтиһад һәм тәкълид тарафдарлары үткәннәргә мөрәҗәгать итеп, үз чорларын тәнкыйтьләп чыгалар. Әлеге төшенчәләрнең икесе дә үзгәрүчән чынбарлыкка карата яңа караш һәм аерым дини мәсьәләләрне Коръән һәм Сөннәткә таянып чишү юлларын тәкъдим итәләр. Шул сәбәпле исламны яңа тормыш шартларына яраклаштыру яисә яңа шартларны аңа туры китерү бары тәкълид яисә иҗтиһад белән башкарылырга мөмкин дип санала. Мәрҗани үзенең «Нәзурат әл-хак» әсәрендә, Коръән, Сөннәт дәлилләренә, иҗмаг, дүрт төп мәзһәб һәм башка күренекле фәкыйһлар карашларына таянып, гыйбадәт кылу мәсьәләсендә иҗтиһад итүнең барлык мөэминнәр өчен фарыз булуын, мәҗбүрилеген исбат итә. Бу очракта Мәрҗанинең иҗтиһад терминына нинди мәгънә салуын һәм нәрсәгә кабат әйләнеп кайтырга чакыруын истә тотарга кирәк.

Мәрҗани иҗтиһадны Коръән һәм Сөннәт буенча гыйбадәт кылуның *(иҗтиһад мотлака)* мөэминнәр өчен фарыз булуын һәм Кыямәт көненә кадәр сузылуын дәлилли [Мәрҗани, 2012, б. 105, 133]. Аның оппонентлары, киресенчә, Коръән һәм Сөннәткә нисбәтле иҗтиһадның тәмам булуы ягында торалар. «Җәрудә» авторы исә моңа дәлил буларак, иҗтиһад капкаларының ябылуы хакында «бөек голямаларның» сүзләрен китерә, аларның алга таба «гыйбадәт кылучының мөҗтәһид сүзләренә таянып эш

итәргә тиешлеге мәсьәләсендә фикъһе галимнәренең бер сүздә булуы» [ән-Нәсави, б. 27] турында уртак фикергә килүен, ягъни тәкълидне алга сөрүләрен искәртә.

Иҗтиһад кылуның вакыты турында Мәрҗани позициясе традицион буларак кабул ителә. Мәрҗани түбәндәгечә яза: «Әгәр дә Коръән һәм Сөннәткә яисә иҗмагка теге яисә бу сорау турыдан-туры кагылмаса, кыяс аркылы иҗтиһадка мөрәҗәгать итү тиештер». Әгәр Коръәндә, Сөннәттә, иҗмагта билгеле һәм кабул ителгән *(мутаватир)* дәлил булмаса иҗтиһад рөхсәт ителә [Мәрҗани, 2012, б. 97]. Мәрҗани фикеренчә, иҗтиһад кирәкле мәгълүмат булмаса, китерелгән дәлилләр йомшаграк яисә текст мәгънәви яктан бик нык җәенке булган очракта үткәрелергә мөмкин.

Бәхәсләрнең төп сәбәбе булып хокук төшенчәләрен төрлечә аңлау тора. ән-Нәсави, мәсәлән, хокук төшенчәләренә Коръән, Хәдис (Сөннәт), риваять, төгәл һәм кабул ителгән кыясны (ягъни иҗтиһад аркылы кыяс итүне) кертеп карый [Габдулла ән-Нәсави, б. 27]. Шул рәвешле абруйлы илаһият галимнәренең күпчелеге тарафыннан иҗтиһад хокук чыганагы буларак кабул ителә, ягъни тәкълидка алып баручы һәм һичшиксез үтәлүне күз алдында тотучы кагыйдә була.

Мәрҗани өчен, хокук чыганагы буларак Коръән, Сөннәт, иҗмаг һәм кыяс кабул ителә [Мәрҗани, 2012, б. 94]. Мәрҗани иҗмагка Пәйгамбәр сәхабәләренең сүзләрен дә кертеп карый, икенче төрле әйткәндә, бу «беренче дәрәҗәдәге иҗмаг» [шунда ук, б. 99–100]. Оппонентларыннан аермалы буларак, кыяс аркылы иҗтиһадны Мәрҗани гамәли мәсьәләләрдә генә фараз дип саный [шунда ук, б. 4]. Коръән, Сөннәт, сәхабәләр иҗмагында күрсәтелмәгән мәсьәләләрне тикшерү – иҗтиһадның төп куллanылу өлкәсе буларак күзаллана. Иҗтиһад Коръән һәм Сөннәттә чагылыш тапмаган, иҗтимагта каралмаган һәм сәхабәләр тарафыннан тикшерелмәгән, ягъни төгәл дәлилләре булмаган мәсьәләләрдән тора.

Иҗтиһадны төгәл һәм дәлилле белемгә кертү теге яисә бу хөкемнең дөрес булуы, шулай ук ялгыш иҗтиһад мәсьәләсен китереп чыгара. Ш. Мәрҗани әйтүенчә, иҗтиһад кеше аңының бары фаразга гына нигезләнгән хакыйкать белеме була, бары Аллаһ тарафыннан иңдерелгән хакыйкать кенә чын дөрес санала. Шул рәвешле, дөрес һәм дәлилле иҗтиһад була алмаган кебек, иҗтиһадта хаклылар һәм хаксызлар да булмый, бер генә кеше икенчесенә аның хаксызлыгын исбатлый алмый. Мәрҗани иҗтиһад кылуны шәхси җаваплылыкка кайтарып калдыра. Иҗтиһад бары фараз буларак кына билгеләнә, иҗтиһад кылгандагы төрле ялгышлыклар кичерелә һәм җәзасыз кала [шунда ук, б. 84]. Дөрес иҗтиһад кылган очракта кеше икеләтә, ялгыш иҗтиһад өчен бер генә тапкыр бүләкләнә. Ялгыш җибәрү гөнаһ буларак саналмый, мөэминнең иҗтиһадны танымавы, ягъни аның хәтта иҗтиһадта дөрес хөкем чыгарырга омтылыш

ясамавы исә зур гөнаһ санала. Мәрҗанинең оппонентлары исә, киресенчә, хата, ялгышлык җибәрү иҗтиһад яшенә җиткән мөҗтәһидкә генә гөнаһ саналмый дигән караштa була. Гадәти кешеләрнең, иҗтиһад яшенә җитмичә торып, ялгыш иҗтиһад кылуы гөнаһ буларак кабул ителә һәм җәзага тартыла [Габдулла ән-Насәви, б. 27–28].

### Иҗтиһад итүнең һәр мөэмин өчен мәҗбүри булуы. Мөҗтәһид

Теге яисә бу дини мәсьәлә буенча хокукый чыганакларда төгәл норма яки конкрет текст күрсәтелмәгән очракта иҗтиһад кылучы кеше *мөҗтәһид* дип атала. Мөҗтәһит иҗтиһад һәм истинбат кыла, ягъни Коръән һәм Сөннәттән, иҗмагтан кыяс, истихсан, мәсалих һәм башка хокукый ысулларлар ярдәмендә дәлилләр китерә. Мөселман сәясихокук теориясе буенча мөселман дәүләтендә хокукый мәсьәләләр мөҗтәһидләр вазифасы, ягъни дин һәм шәригать мәсьәләләрендә җаваплар эзләү үтә абруйлы һәм белемле кешеләрнең эше санала [Сюкияйнен].

«Нәзурәт әл-хакк» һәм «Хикмәт әл-бәлигат» әсәрләрендә Мәрҗани, иҗтиһад капкалары ачык икәнелеген раслаудан тыш, һәр кешегә, үзенең белеменнән чыгып иҗтиһад кылу фарыз, дип яза. Мәрҗани карашынча, иҗтиһад итү дәрәҗәсенә ирешкән барлык кешеләргә дә тәкълидкә таяну рөхсәт ителми [Мәрҗани, 2012, б. 101]. Кешенең аң-фикер сәләтеннән чыгып, Мәрҗани иҗтиһад итүнең берничә төрен аера. Коръән, Сөннәт һәм иҗмагны яхшы белгән галимнәр, Мөхәммәт пәйгамбәрнең беренче өч буын дәвамчылары саваплы иҗтиһад кылырга – абсолют иҗтиһадка бара алалар, ягъни беренчел чыганакларга таяналар; башкалар исә мәзһәб (үз дини-хокукый юнәлешләре) эчендә генә иҗтиһад кылырга мөмкиннәр [Мәрҗани, 2012, б. 105, 133; 2008, б. 356]. Иҗтиһадка сәләтсез кешеләргә, «бер шәригать канунын икечесеннән аермаучыларга» исә абруйлы, үзе сайлап алган мөҗтәһид тәкълиденә таяну фарыз була [Мәрҗани, 2008, б. 356]. Ул шулай ук үзең сайлап алган теләсә нинди мөҗтәһидкә тулысынча ышанып бетмәү ягында булырга кирәк дип саный. Барыннан да элек, дөрес булган хөкемне өйрәнеп кабул итүнең түбәндәге таләпләре аерыла: 1. Сайланылган мөҗтәһид сирәк ялгышырга һәм һәрвакыт хакыйкатьне генә сөйләргә тиеш; 2. Дин һәм белем ягыннан танылган булырга тиеш.

Күренекле һәм абруйга лаек мөҗтәһид юлы белән барган кешеләр һәр очракта да аның хөкеменә таянырга һәм аңа охшарга тырышырга тиеш түгелләр. Галим фикеренчә, яңа мәсьәлә килеп чыкканда, шул мәсьәләгә мөнәсәбәттә иҗтиһад кылу (эшли алсалар) зарур [Мәрҗани, 2012, б. 102]. Голямалар уртак фикергә килә алмаган мәсьәлә буенча, мөҗтәһид сайлаганда, иярүче – мөкаллид ихтийат кылырга, ягъни аеручa сак эш итәргә тиеш. Шикле булган очракларда, әйтик, күңел болгану, кан китү вакытларында (хатын-кызлар тәһарәт

бозылмады дип уйласалар да) тәһарәтне яңарту, су булмаса ком белән һәр намаз өчен тәһарәтләнү кирәк [Мәрҗани, 2012, б. 101].

Мәрҗанинең оппоненты әт-Түнтәри, һәр кешегә иҗтиһад кылуның мөмкинлеген тәнкыйтьләп, түбәндәгечә яза: «Мәрҗани олуг шәехләрне кара халык (*гавам*) дәрәҗәсенә төшерә, шәригатьнең абруйлы белгечләрен аерым, гади кешеләр белән тигезли» [ат-Тунтари, 1909, б. 18]. Әл-Казани фикеренчә, «...гади халык дин мәсьәләренә кысылырага тиеш түгел [әл-Казани, 1899, с. 38], гади халык исламны кабул итеп гыйбадәт кылырга тиеш. Фән галимнәр өчен калсын» [шунда ук, с. 21].

«Җәрудә» авторы Мәрҗанинең Коръән, Сөннәт, иҗмаг, кыяска таяну ягында булуы белән килешсә дә, (аның фикеренчә) «һәр кеше үзлегеннән хөкем һәм нәтиҗәләр чыгарырга тиеш түгел» [Габдулла ән-Насави, б. 46]. Автор «Коръән һәм Сөннәткә нигезләнеп иҗтиһадны гади кешеләргә кылу рөхсәт ителүен алсак, безнең көннәрдә бу мөмкин түгел. Иҗтиһадның барлык кешегә рөхсәт булуы коткы гына тарата. Кешеләр Аллаһ өйрәтмәләре белән уйный башлый һәм галимнәргә каршы чыгарга мөмкиннәр» [шунда ук, б. 25]. Бу очракта «шәригатькә зур куркыныч яный. Шунлыктан динне саклап калу өчен гади кешеләргә иҗтиһад капкалары ябык булырга һәм мөҗтәһидләр өчен генә рөхсәт ителергә тиеш» [шунда ук, б. 25–26].

Ән-Насави иҗтиһадның белемле галимнәр (*хасса*) өчен рөхсәт ителүе хакында язса да, һәрвакыт диярлек голямаларга иҗтиһад кылырга комачау итүче сәбәпләр табылып тора. Мөҗтәһид аерым бер таләпләргә туры килергә тиеш була.

Беренчедән, ул ихсан[1] дәрәҗәсенә җитәргә тиеш. Аллаһы Тәгалә «мөэминнәрнең йөрәкләрен ачып, исламны кабул итәргә һәм ихсан дәрәҗәсенә күтәрелергә ярдәм иткән. Алар арасыннан мөҗтәһидләрне аерып чыгарган һәм аларга сорауларга дөрес җаваплар табарга булышкан. Бу кешеләр аның өйрәтмәләренә таянып хөкем чыгара алалар» [шунда ук, б. 3]. Икенчедән, алар яхшыны яманнан аерырлык итеп гарәп телен әйбәт белергә тиеш. Өченчедән, беренчел чыганаклар булган Коръән, Сөннәт һәм аларның контекстын яхшы үзләштергән булырга тиеш [шунда ук, б. 41–42]. Әгәр бу таләпләргә туры килсә, дүртенче – чикләүче шарт барлыкка килә. «Безнең заманда кайбер талантлы кешеләр изге текстларны әйбәтләп анализлый беләләр, әмма бу алар үзләре иҗтиһад кыла алалар дигән сүз түгел, ул алай гына җиңел башкарылмый» [шунда ук, б. 48]. Бишенчедән, замандашларның иҗтиһадка рөхсәтләре булмау: «Без, мөкаллидләр буларак, Коръән һәм Сөннәткә турыдан-туры таянырга тиеш түгелбез. Без

[1] әл-Ихсан («игелекле», «эчкерсез» ) – Коръәндә әл-ихсан эчкерсез һәм дөрес гыйбадәт кылу төшенчәсе буларак кулланыла һәм икейөзлелеккә, рияга каршы куела.

мөҗтәһидләр сүзенә таянырга тиеш» [шунда ук, б. 36]. Алтынчыдан, барлык мөҗтәһидләрнең үлеп бетүе һәм яңаларының булмавы. «Олуг илаһият галимнәре иҗтиһадның мөҗтәһидләр вафаты белән тәмамлануын искәртәләр, бу очракта безгә ни эшләргә, безнең дәвер иҗтиһад заманыннан тагын да ераграк бит» [шунда ук, б. 50].

Шул рәвешле Мәрҗани тиеш дип тапкан әйберләрне аның оппонентлары кабул итми. Мәрҗани «мөҗтәһид» категориясен аңлауның чикләрен киңәйтә. Мөҗтәһидләр рәтенә, хасса вәкилләреннән тыш, гади кешеләрдән булган барлык мөэминнәрне дә кертеп карый. Аерым мәсьәлә буенча хөкем чыгарган барлык кеше мөҗтәһид дип игълан ителә. Оппонентлары, киресенчә, бары беренчел чыганаклар булган Коръән һәм Сөннәткә таянып хөкем чыгарган кеше генә мөҗтәһид була ала, дип саныйлар.

## Иҗмаг

Тәкълид, Коръән һәм Сөннәттән тыш, илаһият галимнәре тарафыннан уртак килештерелгән хөкемнәр иҗмаг принципларына нигезләнә. Иҗмагның төп функциясе булып абруйлылык мәсьәләсен ачыклау тора. Исламда, Христиан динендәге кебек, дин әһелләренең катгый һәм рәсми иерархиясе булмаганлыктан, текстларның авторитетын һәм канунилыгын раслауны, аларга нигезләнеп кабул ителгән хөкемнәрнең дөреслеген үз өстенә алган аерым бер аппарат булдыру ихтыяҗы туа. Бу аппарат кабул ителгән хөкемнәрнең легитимлыгы өчен җавап бирергә тиеш була. Нәтиҗәдә, барлык мөселманнарны берләштерүче җәмгыять үзе үк шушы вазифаны үти башлый. [Hourani, 1964, p. 16]. Мөселман дөньясының аерымланып торган, географик яктан ерак урнашкан төбәкләрендә (мәсәлән, Идел буенда), әлеге бәхәс аеруча көчәя. Р. Мөхәммәтшин фикеренчә, иҗмаг фикъһе гыйлеменең нигезен тәшкил итә һәм әлеге гыйлемнең сыгылмалылыгын һәм төбәкләр арасындагы дини аермалыкларны канунлаштырырга ярдәм итә [Мухаметшин].

Җәмгыяви консенсус мөселманнарның догматик, хокукый һәм тарихи яшәешен формалаштыра. Барлык вакыйгалар яшәп килүче тәкълиди традиция нигезендә аңлатыла. Шул ук вакытта, иҗмаг нигезендә туган аерым бер хөкемне үтәүмәү әлеге җәмгыятьнең абруен шик астына куя. Мәгълүм булганча, ул чорда Идел буе мөселаннары Урта Азия тәкълиденә таянып эш итә. Шуңа күрә Мәрҗанинең мөселман дөньясында аерым бер «олуг галимнәр»не һәм аларның идеяләрен тәнкыйть утына тотуы Идел буе мөселман җәмгыятендә нык тамыр җәйгән бу традициянең нигезләрен какшата. Дж. Хаурани фикеренчә, иҗмаг оешканнан соң кыяс ярдәмендә иҗтиһад кылу кими төшә, аның урынына истихсан[1] һәм башка дәлилләр китерелә башлый.

[1] Истихсан – Әбү Хәнифә керткән хокукый мәсьәләләрне чишү алымы: кыяска нигезләнгән карардан бигрәк конкрет шартларга туры килүче хөкемне сайлау; фикһның икенче дәрәҗәдәге чыганагы.

Шул рәвешле, әлеге консенсусның карары кире кагылмыйча һәм кичекмәстән үтәлергә тиеш була. [Hourani, 1964, p. 24]. Бу позиция консенсусның Сөннәткә һәм Пәйгамбәр күрсәткән туры юлга таянуы белән аңлатыла. Әлеге фикер, бер яктан, традициянең эчтәлегенә «сакраль» мәгънә салып аның статусын ныгытса, икенче яктан, чикләре катгый билгеләнгән үсеш юнәлешен һәм доктринасын формалаштыруга ярдәм итә. Шул рәвешле, мөҗтәһиднең эшчәнлеге, элеккеге чорларда авторитетлы голямалар тарафыннан кабул ителгән хөкемнәрне үзгәртә алмавы белән бергә, соңгы чорларда туган бәхәсле мәсьәләләргә мөнәсәбәттә иҗмаг билгеләгән тәртипләрдән һәм кысалардан чыга алмавы белән дә чикләнә.

Исламда «консенсусның авторитетлыгы» мәсьәләсе берничә тапкыр күтәрелә. Гадәттә, иҗмагны тәнкыйтьләүчеләргә каршы җавап рәвешендә Пәйгамбәрнең «Минем өммәтем хаталанырга риза түгел» дигән сүзләре китерелә. Иҗмагның һич тә шик астына куелмый торган дөрес хөкем булуын әл-Могътазили, әш-Шафигый кебек дини авторитетлар да яклап чыга. Әш-Шафигый дәлилләре нигезендә консенсус барлык хокукчылар тарафыннан хокук чыганагы буларак раслана. XIX йөздә ислам реформалары барышында әлеге тема яңадан көнүзәк мәсьәләгә әверелә. Консенсусның чыганак буларак кыйммәте һәм абруйлылыгы проблемасы күтәрелә. Әлеге процесс, бөтен ислам дөньясына таралу белән бергә, Россия мөселманнарын да читләтеп узмый. Ул чорда тәнкыйтькә тартырлык нинди үзгәрешләр барлыкка килде һәм моның сәбәбе нәрсәдә булды соң? XIX йөз галимнәре иҗмагның дөреслегенә каршы чыкмыйлар. Консенсус инде исламга кадәрге җәмгыятьтә үк кулланылган һәм ул ислам тәгълиматының аерылгысыз өлеше булып тора. XIX гасыр галимнәре аның чикләрен дөрес билгеләми [Hourani, 1964, p. 13–26].

Мәрҗани өчен дә консенсус абруйлы хокук чыганагы булып тора. Мәсәлән, ул «Гади халык консенсусы буенча, Аллаһ тарафыннан күрсәтелгән, аның Китабында һәм Аның Илчесе хәдисләрендә билгеләнгәннәр барысы да фарыз һәм вәҗиб һәм алар һичшиксез үтәлергә тиеш, җиңел карап эш итү тыела...» дип яза [Мәрҗани, 2008, б. 336].

Мәрҗани, үз оппонентларыннан аермалы буларак, Мөхәммәд пәйгамбәр дәвамчылары иҗмагын гына кабул итә, алардан соңгы галимнәр консенсусы аның өчен кыйммәткә ия булмый. Шул рәвешле ул хәнәфи мәзһәбендәге Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәхабәләре, аның дәвамчылары һәм җирле мөҗтәһидләр консенсусын үз эченә алган иҗмаг традициясе чикләрен төгәлрәк билгеләргә омтыла [Словарь, 1991, с. 91]. Болардан Мәрҗани Урта Азия мөҗтәһидләренең һәм җирле галимнәр консенсусын кире кага.

Мәрҗанинең иҗмаг чикләрен билгеләү хакындагы карашлары аның оппонентлары тарафыннан кискен тәнкыйть ителә. Мәсәлән, Динмөхәммәт

«әлеге рәфидит гомуми килешүне шик астны куя» дип язып чыга [ат-Тунтари, 1909, с. 28]. Динмөхәммәт шулай ук «ислам шәригате билгеләгән законнардан башка безгә башкалары кирәкми. Фәкыйһ һәм сәләфләр әлеге шәригать кануннарын аңлату өчен күп көч түккәннәр, әгәр дә без җәдид кыла башласак барыбыз да, һичшиксез, туры юлдан тайпылачакбыз» – дип фикер йөртә [шунда ук, б. 24]. Ән-Нәсави Мәрҗани эшчәнлеге бары «үз ихтыяҗы һәм максатыттан чыгып мөселман чыгынакларын фаш итәргә генә омтыла, моннан да гайре ни булырга мөмкин?» дип билгели [Габдулла ән-Насави, б. 5].

## Йомгак

Тикшеренү нәтиҗәсендә, XIX гасырда Идел буе мөселманнары акыл ияләренең традицион җәмгыятьнең яңарышын төрлечә кабул итүләре ачыкланды. Бу уңайдан Яңа заманда барлыкка килгән төшенчәләрне кабат тикшереп чыгу ихтыяҗы туа. Яңа тәҗрибә традициянең күрсәтмәләре һәм категорияләре аркылы өйрәнелә, аны яшәп килгән тәртипләргә яраклаштыру мөмкинлеге бирелә. Мөселман хокукы буенча чыганаклар һәм алардагы идеяләр яңа шартларга нисбәтле яңадан каралырга, өйрәнелергә тиеш булалар. Мәрҗани тәкъдим иткән әлеге реформа программасы (ислах) «иҗтиһад», «мөҗтәһид», «кыяс» һ.б. төшенчәләрне кабат тикшеренү объекты итүне күздә тота. Әлеге мәкаләдә без Мәрҗани һәм аның оппонентларының «иҗтиһад», «мөҗтәһид», «иҗмаг» кебек төшенчәләрне ничек кабул итүләрен өйрәндек.

Идел буе мөселман голямаларының иҗтиһад капкалары ябылу турындагы карашларын инкяр итеп, Мәрҗани иҗтиһад капкалары һәрвакыт ачык икәнлеген һәм Кыямәт көненә кадәр һәр кешегә иҗтиһад кылуның фарызлыгын исбатларга омтыла. Барлык мөэминнәр иҗтиһад кылырга тиеш булудан чыгып, Мәрҗани мөҗтәһид сүзенә салынган мәгънәне дә киңәйтеп бирә. Ул мөҗтәһидләр голямалардан гына түгел, гади халык арасыннан да була ала, дигән фикердә тора. Коръән, Сөннәт һәм сәхабәләрнең консенсусы булган иҗмагтан кала, кабул ителгән барлык хокукый хөкемнәр иҗтиһад чыганагы булырга тиеш дигән фикерне яклый. Иҗтиһад хокукының чыганакларын киңәйтеп, Мәрҗани үз оппонентлары карашлары белән килешмәгәнлеген күрсәтә. Галимнең иҗтиһад һәм мөҗтәһид билгеләмәләре үз заманы таләпләренә тулысынча туры килә. Нәтиҗәдә бу караш кеше ирегенең чикләрен киңәйтә, модернизация һәм урбанизация шартларында яңа инсан формалаштыру ихтыяҗын китереп чыгара.

Мәрҗанинең фикерләренә каршы булучылар «ул иҗмагны дөрес тәгъбир итми» дип саныйлар. Чынлыкта да, Мәрҗани иҗмагның авторитеты, аның һәр очракта да хакыйкатькә туры килүе мәсьәләсен күтәреп чыга. Шул ук вакытта ислам чыганагы буларак, ул иҗмагны кабул итә, әмма аны таррак мәгънәдә күзаллый. Галим беренчел дәрәҗәдә-

ге иҗмагны, ягъни Пәйгамбәр дәвамчылары иҗмагын гына кабул итеп, аннан соңгы буын иҗмагы үз кыйммәтен югалта, дип саный. Галим иҗмаг, иҗтиһад, кыяс мәсьәләләрендә җирле һәм Урта Азия галимнәренең хөкемнәре белән килешми.

Иҗмаг мөселман җәмгыяте өчен беренчел чыганак саналганга, Мәрҗани, иң әүвәл, Идел буе мөселманнары өчен Урта Азия голямаларының ни дәрәҗәдә авторитле булулары мәсьәләсен күтәрә, алар чыгарган хөкемнәрне шик астына куя. Безнең уебызча, Мәрҗанинең фикер-карашлары һәм тәкъдимнәре Идел буе мөселман җәмгыятенең үз мөстәкыйль хокукый һәм дини традициясен формалаштыруга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*әл-Казани, Гиладжуддин ибн Мухиддин ас-Сардави.* Нусул ал-хадида фи хыляфи ал-усул ал-джадида («Стальной клинок против новой методики»), (1899). Казань: Иман. рус. перевод.

*Мәрҗани Ш.* Нәзурат ал-хак фи фәрдийәт әл-гашаи вә ин ләм йагаб әшшәфәкъ («Эңгер-меңгер төшүгә бәйсез рәвештә кичке намазның кирәклеге турында хакыйкатькә бер караш»), 1870 елда басыла / Истанбул: Дар-ул-хикме, 2012, гарәп тексты.

*Мәрҗани Ш.* Хикмәт әл-балигат әл-җәннияти фи шәрх әл-гакаид әл-хәнәфияти («Хәнәфиләрнең дини ышанулары турында өлгереп җиткән дөрес карашлар китабы») / гарәп теленнән Д. Шаһавиев тәрҗемәсе. Казань, 2008.

*ат-Тунтари, Абу Накиб (Ишми ишан).* «ал-Ишарат ал-Ламига фи анмузадж ал-фикх ва гавамид ал-Кахстани» («Ясные указания по вопросам фикха и загадкам ал-Кахстани») (1899). Казань: Иман, рус. перевод.

*ат-Тунтари, Динмухаммад ибн Ярмухаммад ибн Мансур.* «Побуждение достойных ученых мужей к борьбе против неучей, искажающих чистое учение шариата» (1909). Казань: Иман, рус. перевод.

*аш-Шаулянкари, Мухаммад ибн Наджиб ибн мулла Биляль ибн дамулла Мазфар.* Тазкират ар-рашид бирадди кайди («Напоминание праведного о кознях завистника») (1901). Казань: Иман, рус. перевод.

*аш-Шаулянкари, Мухаммад ибн Наджиб ибн мулла Биляль ибн дамулла Мазфар*. (Ответ на трактат второго завистника) (1901). Казань: Иман, рус. перевод.

*Габудллаән-Нәсави.* Мөзһир әл-кәлимәт әл-җаруда әл-ләти хийа фи-н-назура («Назурадәге куркыныч сүздәрне фаш итү»), 1874 елда басылып чыккан / Гарәп теленнән Р. Адыгамов тәрҗемәсе. Казань: изд. Иман.

*Атнашев Т., Велижев М.*«Contextisking»: Джон Покок – историк политических языков / Новое литературное обозрение №134 (4/2015), http://www.nlobooks.ru/node/6426 (дата доступа 20.05.2018)

*Идиятуллина Г.* Духовно-религиозная атмосфера в Поволжье в XVII–XVIII вв.

Ислам: Энциклопедический словарь. М.; Наука. Главная редакция восточной литературы, 1991

*Кемпер М.* Суфии и ученые в Татарстане и Башкортостане [1789–1889]: Исламский дискурс под русским господством: пер с нем. Казань: Российский исламский университет, 2008.

*Мухамметшин Р.* Мусульманская община как источник и цитадель татарского традиционализма / Татарские мусульманские приходы в Российской империи. Материалы Всероссийской научно-практической конференции (27–28 сентября 2005 г., г. Казань). Казань: Институт истории АН РТ, 2006. 308 с.

*«Понятия о России»:* К исторической семантике имперского периода: в 2-х томах. Новое литературное обозрение, 2012. Т.м 1. 576 с.; Т. 2. 496 с.

*Салихов Р.Р.* Участие татарского предпринимательства России в общественно-политических процессах второй половины XIX– начала XX в. – Казань: Фэн, 2004. 260 с.

*Сюкияйнен Л.Р.* Мусульманское право. М.: Наука, 1986. Использована электронная версия – http://www.gumer.info/bogoslov_Buks/Islam/Syk_Pravo/index.php (дата доступа 20.05.2018).

*Скиннер Кв.* The State / Пер. с англ. Д. Федотенко // Понятие государства в четырех языках / под ред. О. Хархордина. СПб., 2002. С. 12–74

*Словарь* основных исторических понятий: Избранные статьи в 2-х т. / пер. с немецкого К. Левинсон; сост. Ю. Зарецкий, К. Левинсон, И. Ширле; научн. ред. перевода Ю. Арнаутова. М., 2014

*Шагавиев Д.А*. Роль Шигабутдин Марджани в развитии татарской богословской мысли XIX века: дис. ... канд. ист. наук. Казань, 2010

*Юзеев А.Н.*Татарская религиозно-реформаторская мысль. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012.

*Hallaq W.B.* Authority, continuity, and change in Islamic law. Cambridge University Press, 2004.

*Hallaq W.B.* Was the Gate of ijtihad closed? // International Journal of Middle East Studies, Vol. 16, No. 1 (Mar., 1984), pp. 3–41.

*Hourani A.* Arabic Thought in the Liberal Age, 1798–1939. Cambridge University Press, 1983.

*Hourani G.* The *Basis of Authority of Consensus* in Sunnite *Islam* // Studia Islamica, No. 21 (1964), pp. 13–60.

*Sartori P.* Exploring the Islamic Juridical Field in the Russian Empire: An Introduction // Islamic Law and Society, 2017, № 24, pp. 1–19.

*Watt M.* Islamic philosophy and theology. Edinburg University Press, 1985

*Тикшеренү Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең №16-105-цГ/2018 гранты кысаларында башкарылды*

***Мәрданова Динара Зәмир кызы,***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының фәнни хезмәткәре*

УДК 37.05

***Э.К. Сәлахова***

# БЕРТУГАН ШӘФИГУЛЛИННАР ҺӘМ ТАТАР МӘГАРИФЕ

Статья посвящена анализу развития образовательной системы татар в конце XIX – начале XX века, а также освещает вклад меценатов в образование и просвещение татарского народа. Автор на примере деятельности братьев Шафигуллиных показывает их роль в основании мечетей и медресе. Исследуя архивные документы, восстановлена картина основания и развития знаменитого учебного учреждения – медресе деревни Акзигитово.

**Ключевые слова:** Братья Шафигуллины, благотворительность, образование татар, просветительская деятельность, Загидулла Шафигуллин, Нагорная сторона, медресе деревни Акзигитово, медресе.

Татар мәгарифе барлыкка килү һәм аның үсеш мәсьәләсен өйрәнү, халыкның алга китешендәге әһәмиятен билгеләү – татар тарихы өчен актуаль проблема. Мәгарифнең торышы, үсеш-үзгәреш этаплары халыкның йөзен, аның тарихын билгели. Кызганычка каршы, хәзерге вакытта бу проблема бөтен яклап өйрәнелмәгән.

Мәгълүм булганча, татар мәктәп-мәдрәсәләрен, рус уку йортларыннан аермалы буларак, беркайчан да хөкүмәт финансламаган. Алар я мәхәллә халкы, я аерым хәйриячеләр ярдәмендә оеша һәм эшчәнлек итә. Зур шәһәрләрдә сәүдә иткән яисә башка эшмәкәрлек белән шөгыльләнгән байлар, гадәттә, туган якларында мәдрәсә ачып, аны тулысынча акча белән тәэмин итеп торганнар. Авыл җирлегендәге атаклы мәдрәсәләрнең күбесе Казан арты төбәгенә карый: Кышкар, Курса, Мәтәскә, Түнтәр һ.б. Мамадыш ягындагы Сатыш мәдрәсәсе тирә-якта данлыклы була. Татарлар балаларын, белем бирү максатыннан, ерактагы мәдрәсәләргә илтеп укыта торган булганнар.

Фәнни әдәбиятта Казан, Оренбург, Уфа, Иж-Буби мәдрәсәләренең эшчәнлеге инде күпмедер өйрәнелгән. Бу мәдрәсәләрнең уку-укыту программалары белем бирүнең югары дәрәҗәсе хакында сөйли. Әлеге тикшеренүебездә без Тау ягы мәдрәсәләрен карыйбыз.

1909 елгы мәгълүматлар буенча, Тәтеш өязендә 112 мәктәп булган, Зөя өязендә – 25, Чар өязендә 5 мәдрәсә эшләгән. Атаклы мәдрәсәләр дәрәҗәсендә үк булмаса да, XX гасыр башында Тәтеш өязенең Атабай, Идрәс-Тенки, Олы Кариле, Келәнче, Олы Тормы авылларында шактый көчле уку йортлары булуы билгеле [160 ф., 1 тасв., 1687 эш, 101а кгз.]. Идрәс-Тенки, Олы Кариле авылларында Әҗем мәдрәсәсен тәмамлаган Әхмәтҗан Габделгаффаров һәм Шаһимөхәммәд

Нурмөхәммәтев мөгаллимлек итә, Келәнчедә Буа мәдрәсәсен тәмамланган Шиһабетдин Мифтахетдинев, Олы Тормыда Апанай мәдрәсәсе шәкерте Зыятдин Шәрәфетдинев, Атабай авылында Әҗем мәдрәсәсен тәмамлаган Шаһимөхәммәд Госманов белем бирәләр.

XIX–XX гасыр башында Тау ягындагы иң атаклы мәдрәсә Акъегет авылында урнашкан була. Бу мәдрәсәне нигезләүче һәм матди тәэмин итеп тотучы Шәфигуллиннар, аерым алганда, ике бертуган Шәфигуллинның берсе – Заһидулла Шәфигуллин эшчәнлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. Әлеге шәхеснең хәйриячелек гамәлләре Тау ягында гына түгел, Россиянең ерак Себер якларында да билгеле.

Заһидулла Шәфигуллин 1840 елның 16 декабрендә Акъегет авылында дөньяга килә. 1859 елда, әтисе үлеменнән соң, ул Урал якларына эш эзләп китә. Томск, Иркутск шәһәрләрендә сәүдә эшләрен башлап җибәрә: энесе белән берлектә Кырым алмалары китереп сата башлыйлар. Шулай ук күлмәкләр, җәнлек тиреләре белән сәүдә итәләр. Энесе Шәйхулла белән 1894 елның сентябрендә «Бертуган Шәфигуллиннар» дип исемләнгән сәүдә йорты оештыралар. Иркутск, Красноярск, Чита шәһәрләрендә җәнлек тиреләре сата торган кибетләр челтәре булдыралар.

1887 елда Иркутскидагы үз йортлары утарында мәчет төзетәләр. 1907–1908 еллар арасында өч катлы табыш йорты булдыралар. Шулай ук Шәфигуллиннар Иркутск, Чита шәһәрләрендә мәчет төзелешләренә зур сумма иганә итәләр. Томск шәһәрендәге мөселман балаларына белем бирү мәдрәсәсенә дә зур матди ярдәм күрсәтеп торалар. Хаҗи Шәйхулла Шәфигуллин мәктәп белән идарә итү өчен Төркиянең атаклы уку йортларында белем алган Исмәгыйль исемле мөгаллимне китертүгә ирешә [Казан мөхбире, 1907].

XIX гасырның 90 нчы елларында Заһидулла Шәфигуллин сату-алу эшләре белән җитәкчелекне энесенә, өч улы – Зиннур, Гарифҗан, Хәйруллага һәм туганының уллары Гыйлаҗетдин, Сәлахетдин һәм Абзалетдингә тапшыра. 1912 елның августында «Шәфигуллиннар һәм Әхтәмевләр» ширкәте оеша. Алар, Вятка, Вологда, Архангельск шәһәрләренең атаклы бай сәүдәгәрләре белән туганлашып, нәселтуганлык капиталын арттыруга ирешәләр, табышларының бер өлешен җәдиди мәктәпләр ачуга тоталар [1 ф., 4 тасв., 5482 эш, 253а–255а кгз.]. «Русия сәүдәсе» газетасында түбәндәге юллар теркәлгән: «Аның [Заһидулла] тарафыннан салынган мәктәпләрнең һәммәсендә ысулы җәдидә берлә тәгълим ителә. «Тәрҗеман» мөхәррире Исмәгыйль Гаспринский җәнаблары халыкны ысулы саутиягә өндәгән вакытта иң башлап кабул итүче Заһидулла хаҗи булган» [Русия сәүдәсе, 1913, б. 6–7].

Дөньяны күреп өлгергән, зур капитал туплауга ирешкән Заһидулла Шәфигуллин Туган авылы Акъегеткә кайтып төпләнә. Шул заманның чиновниклары язмаларында ул коры холыклы, кире,

үзсүзле, куркусыз кеше буларак сурәтләнә [1 ф., 4 тасв., 6183 эш, 6а–8б кгз.]. Җирле халык аны хөрмәт итә, тәэсирле кеше булганга, аңа берникадәр курку аша карыйлар. Архив документларында, З. Шәфигуллин нинди генә гамәлләр кылса да, халык аны «сатмаячак», аңа хыянәт итмәячәк, диелә [1 ф., 4 тасв., 3119 эш, 15а–15б кгз.].

Шәфигуллиннар Чар, Зөя, Тәтеш өязләрендә мәчетләр төзү, мәдрәсә, мәктәпләр ачуга зур матди ярдәм күрсәтә. Заһидулла Шәфигуллин хисабына Акъегет авылында да 3 мәчет һәм мәктәп төзелә һәм төзекләндерелә [Русия сәүдәсе, 1913, б. 6–7]. Шулай ук ул башка бай сәүдәгәрләрне дә мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр төзетү эшенә җәлеп итә [1 ф., 4 тасв., 6183 эш, 6а–8б кгз.]. Мәсәлән, аңа Акъегет мәдрәсәсе чыгымнарын күтәрергә Архангель сәүдәгәре Закир Ишмәтев ярдәм итә [1 ф., 4 тасв., 6183 эш, 6а–8б кгз.]. Хәзерге Кайбыч районына керә торган Кошман авылының ике катлы икенче агач мәчетен үз хисабына төзетә [1 ф., 4 тасв., 3119 эш, 15а–15б кгз.].

Заһидулла Шәфигуллин заманында сәүдәгәр, эшмәкәр булып кына түгел, ә җәдидче буларак бик ихтирамлы һәм танылган шәхес була. Аның эшчәнлеген И. Гаспринский, Г. Баруди, Г. Апанаев кебек атаклы кешеләр югары бәяләгән. Жандармерия документларында аның хакында «он был Галеевского и Иж-Бобьинского закала», дип теркәлә [1 ф., 4 тасв., 6183 эш, 6а–8б кгз.].

Чабаксар өязе исправнигы В.А. Лохвинцкий Казан вице-губернаторы Г.Б. Петкевичка биргән рапортында З. Шәфигуллин турында «известный крупный мусульманский деятель-панисламист, человек прогрессивного направления по своим политическим убеждениям, примыкающий по своему мнению к партии конституционалистов-демократов», дип яза [1 ф., 4 тасв., 5482 эш, 253а–255а кгз.].

1870 елда әдип үз туган авылы – Акъегеттә мәдрәсә ачып җибәрә. Бинасы ике катлы итеп 36 аршин озынлыгында төзелә. Мәдрәсә берничә мәртәбә төзекләндерелә. XX йөз башында шәкертләр саны 300 гә җиткәнлектән, 1895 елда бина киңәйтелә. Мәдрәсә утары тулы бер комплексны хәтерләтә, аның янында укытучылар яши торган ике катлы йорт, шәкертләр юыну өчен мунча, ашханә урнаша. Мәдрәсә комплексының янында алма бакчасы үстерелә.

Шәкертләрнең җитмешкә якыны ерактан килеп укучылар була. Әлеге уку йортында Чистай, Буа, Минзәлә өязе авылларыннан килгән балалар һәм яшьүсмерләр белем ала. Бер шәкертнең Владивостоктан булуы да мәгълүм. Мәдрәсәдә торып укучылар аскы катта яшәгәннәр. Алар тулысынча Шәфигуллинар хисабына көн күргәннәр. 1913 ел мәгълүматлары буенча, бу мәдрәсәдә 9–18 яшьлек 114 шәкерт белем алган.

Шәфигуллин татар халкын гыйлемле, укымышлы итү максатыннан күп көч куя. Документларда: «Шафигуллин – убежденный сторонник распространения образования в мусульманской

среде. При разговорах с должностными лицами Шафигуллин высказывает, что татары необразованны, некультурны и экономически оскудели и что только образование может сделать татар культурными и поднять экономический их уровень», дип теркәлеп калган.

З. Шафигуллинның эшчәнлеге аерым кешеләр арасында ризасызлык тудыра. Беренчедән, тирә-як авылларның муллалары җәдиди укытуга шикләнеп, хәтта куркып карый. Шулай ук мәдрәсәдә рус сыйныфлары эшләп килү традицион карашлы халыкны, руханиларны да шик-шөһрәгә сала. Икенче яктан, әлеге ситуация хакимият вәкилләрен дә куркуга сала. Айдар авылы мулласы Гарифулла Шаһиәхмәтев Шәфигуллин мәдрәсәсе турында халык арасында ялган сүзләр дә тарата, бу мәдрәсәнең эшчәнлеген миссионерлар белән хезмәттәшлектә гаепләргә маташа. Ул 1901 елның 21–22 декабрьдә намазга дип килгән Акъегет мәдрәсәсендә укый торган 2 шәкертне төртеп чыгарып җибәрә [1 ф., 6 тасв., 106 эш, 10а–12б кгз.]. Чиновник Н.В. Смирнов «Шафигуллин инспирирует идею национализации мусульманской школы и тратит очень большие средства на осуществления этой идеи», дип белдерә [160 ф., 1 тасв., 1576 эш, 270а–272а кгз.].

Акъегет мәдрәсәсе уку программасында хәтта рус сыйныфында да рус һәм гомум тарих дигән предмет булмый, ә аның урынына Шәрык тарихы укытыла. Чабаксар өязе исправнигы болай дип яза: «Я лично убежден, что медресе в д. Акзигитово создано и поддерживается Шафигуллиным в целях религиозно-национального объединения мусульман» [1 ф., 4 тасв., 5482 эш, 253а–255а кгз.].

1897 елдан башлап Акъегет мәдрәсәсе җәдиди уку программасы белән эшли башлый. Мәдрәсә 1907 елда Казан укытучыларының икенче корылтаенда эшләнгән программа буенча, аерым алганда, Апанай мәдрәсәсе уку программасына якын программа белән укыта. Мәдрәсә 5 бүлектән һәм 2 сыйныфтан тора. Беренче сыйныфта курсны узу вакыты 3 ел, икенче сыйныфның уку курсы 7–8 ел дәвам итә. Биредә гакаид, тәҗвид, ана теле, арифметика һәм башка предметлар укытыла. Укыту татар телендә алып барыла. Жандармерия документында «он большое внимание обращает на народное образование. В этом старается, чтобы муллы и учителя больше обращали внимание на обучение татарскому языку и светским предметам образования», дип күрсәтелә [1 ф., 4 тасв., 6183 эш, 6а–8б кгз.]. Мәдрәсәдә уку дәреслекләре буларак Х. Искәндәревнең «Белек йорты», «Гарәпчә сарыф», «Мең дә бер хәдис», «Тарихы ислам», «Гыйльме хәл», Г.Тукайның «Яңа кыйраәт», «Татар сарфы», «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре», Я. Хәлилинең «Яңа мәктәп», «Гыйльме хәл», Г. Гыйсмәти һәм Ф. Туктаровның «Татар теле», Ф. Кәриминең «Мохтасар тарихы исламия» һ.б. кулланылган.

Мәдрәсәдәге ысулы саутия методы белән укытуның

нәтиҗәлелеген, файдасын, укыту дәрәҗәсен күрсәтү максаты белән дә ел саен ачык имтиханнар оештырылган. Имтиханнарга тирә-як муллалары, Чар һәм күрше өязләрдән мөхтәрәм кешеләр чакырылган. Бу ачык имтиханнар башка төбәкләрдәге уку йортларының да җәдиди укыту ысулына күчүенә этәргеч булып торган.

XX йөз башында мәдрәсә мөгаллиме вазифаларын авыл мулласы Нурулла Ярулла улы үтәгән [ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 1834 эш, 1а кгз.]. Авылның бу беренче мулласы ике башлангыч бүлектә дәресләр алып барган. Дүрт өлкән бүлекләрдә дин дәресләрен һәм башка предметларны башлангыч бүлегендә рус теле укытучысы Фатыйх Сәйфуллин (Фатыйх Сәйфи-Уфалы буларак билгеле) укыткан.

1912 елда мәдрәсә каршында рус сыйныфы ачыла, үз хисабына рус сыйныфы ачуны сорап «Бертуган Шәфигуллиннар» сәүдә йорты әгъзасы Заһидулла Шәфигуллин чиновникларга 1908 елда ук мөрәҗәгать итә. Ул үз үтенечендә бу сыйныфның укытучысы итеп Бирскида укутыучылар мәктәбен тәмамлаган Әхмәди Гордеевны күрергә тели [160 ф., 1 тасв., 1215 эш, 28а–28б кгз.]. Рус телен өйрәнү җирле халык арасында шактый популярлаша, теләүчеләр артканнан-арта бара. Бу сыйныфта 84 кеше белем ала, укырга килергә теләүчеләр саны 40 кеше була. Әлбәттә, мәдрәсә берьюлы шулкадәр кешене сыйдыра алмый, шуңа да рус теле укытучысы Әхмәди Гордеев Шәфигуллин исәбенә рус телен укыту өчен кичке курслар ачарга рөхсәт бирүне сорап мөрәҗәгать итә. Әмма Чар һәм Зөя өязләре исправнигы И.М. Крестников Казан губернасы халык мәктәпләре директоры М.Н. Пинегинга биргән җавабында мондый курслар ачу ягында булмавын белдерә. Ул үзенең фикеренә дәлил итеп түбәндәге сәбәпләрне атый: беренчедән, укытучының нагрузкасы тиешле нормадан күпкә артачак, икенчедән, 300 шәкерт укыган һәм дә яшәгән мәдрәсәгә тагын да өстәмә шәкертләр сыя алмаячак, көне буе шәкертләр булган бинаны җилләтергә дә кирәк булачак, өченчедән, олыларны рус теленә укытуны һәрвакыт күзәтеп торырга кирәк булачак. Гордиев «не внушает мне пока еще доверия, ввиду кратковременной службы в моей инспекции» [160 ф., 1 тасв., 1376 эш, 117а–117б кгз.], дип, чиновник татарларга рус теле укытсаң, аларның дөньяга чыгу, аралашу даирәсе киңәячәгеннән шүрли. Шулай итеп, кичке курслар ачуга ризалык бирелми.

З. Шәфигуллин авылда кызлар укыту эшенә дә нигез сала. Иң беренче итеп кызлар мәктәбен үз өендә, үз исәбенә ачып җибәрә. 1913 елга кадәр кызларны укыту эшен озак еллар буе аның кызы җитәкли [1 ф., 4 тасв., 5482 эш, 253а–255а кгз.]. Соңыннан кызлар мәктәбенең үз бинасы барлыкка килә. Мәктәп берәр катлы ике бинада урнаша. 1913 елга караган волость идарәсе документлары буенча күрсәтелгән вакытка монда 130 (кайбер мәгълүматлар буенча 140) кыз белем алган. Кызлар мәктәбендә дә рус сыйныфы эшләгән. Рус

сыйныфларында уку срогы 4 ел булса, татар сыйныфларында уку срогының кысалары билгеләнмәгән була. 1912 елдан башлап монда рус теленнән М. Салихова, ә татар сыйныфларында 1913 елдан башлап М. Камалова мөгаллимлек итә [160 ф., 1 тасв., 1463 эш, 6а–8б кгз.]. Укытучылар өчен дә, укучылар өчен дә яхшы шартлар тудырылган була. Ике мөгаллим укытучылар өчен махсус төзелгән бинада яшәгәннәр.

Картлык көннәрендә З. Шәфигуллинга югарыда күрсәтелгән уку йортларын тәэмин итү авырлаша башлый. 1910 елда 71 яшендә булган Заһидулла Шәфигуллин эшләренә ярдәм итүне сорап хөкүмәткә мөрәҗәгать итә [160 ф., 1 тасв., 1463 эш, 6а–8б кгз.]. З. Шәфигуллинның хакимият белән мөнәсәбәтләре нинди генә катлаулы булуга карамастан, аның мәгариф өлкәсендә күрсәткән хезмәте югары бәяләнә: мөрәҗәгате канәгатьләндерелеп кенә калмыйча, Земство собраниесе исеменнән күпьеллык фидакяр хезмәте өчен бүләкләүгә тәкъдим ителә. Хөкүмәт тарафыннан да финансланганга бу мәдрәсә соңгы елларда инде «Русско-татарская школа» буларак эшләвен дәвам итә. Мәдрәсә бинасы 1929 елга яраксыз хәлгә килә һәм уку йорты ябыла. Аның күргәзмә материаллары, географик карталары Норлат мәктәбенә алына. Акъегет авылында бары дүртьеллык мәктәп кенә кала [Тимершин, 2001].

Заһидулла Шәфигуллин 79 яшендә үлеп китә һәм үз туган авылы зиратында җирләнә. Заманында үзенең белем алу мөмкинлеге булмаса да, укуның ляземлеген, аның заман таләпләренә туры килерлек югары дәрәҗәдә булырга тиешлеген аңлый. Беренчеләрдән булып, үзе оештырган мәдрәсә-мәктәпләренә җәдидчә укытуны кертә, үз мәктәпләренә укытучы итеп бары тик алдынгы карашлы яшьләрне генә сайлап ала, заманының зыялы кешеләре белән аралаша, мәктәпләренә татар газеталары яздыра, мәктәп китапханәләре булдыра. Жандармерия документларында «в дни пресловутой свободы он мечтал иметь в своей деревне нечто вроде татарского университета», дип күрсәтелә [1 ф., 4 тасв., 6183 эш, 6а–8б кгз.].

XX йөз башындагы иҗтимагый һәм сәяси хәлләрдә дә ул актив катнашучылардан була. Үз мәктәбе тирәсендә үзгәреш, яңарыш яклы муллаларны туплаган. Шул ук жандармерия документларыннан күренгәнчә, «...перед съездом мусульман в Петербурге устраивают Шафигуллины в его школе большое собрание мулл своего околотка, среди которых было много из враждебного Шафигуллину лагеря, но несмотря на это, в этом собрании Шафигуллин был почти единогласно выбран как представитель от них на съезд». 1906 елда социал-революционерлар партиясе файдасына акчалата ярдәм күрсәтә, Гаяз Исхакый аша «Таң йодызы» газетасын химаяли [1 ф., 4 тасв., 6183 эш, 6а–8б кгз.]. Шулай итеп, Заһидулла Шәфигуллинның татар мәгърифәтчелеге өлкәсендәге эшчәнлеге һәм татар мәгарифе үсешендәге роле фәнни яктан танылырга һәм бәяләнергә хаклы.

## Әдәбият

Заһидулла Шәфигуллин // Русия сәүдәсе. 1913. № 2. Б. 6–7.
Тимершин И. Акъегет авылы тарихы сәхифәләре. Казан, 2001. 164 б.
Томскийдан мәктүб // Казан мөхбире. 1907. № 236.
ТР ДА. 1 ф., 4 тасв., 3119 эш.
ТР ДА. 1 ф., 4 тасв., 5482 эш.
ТР ДА. 1 ф., 4 тасв., 6183 эш.
ТР ДА. 1 ф., 6 тасв., 106 эш.
ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1215 эш.
ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1376 эш.
ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1463 эш.
ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1576 эш.
ТР ДА. 160 ф., 1 тасв., 1687 эш.
ТР ДА. 160 ф.,1 тасв., 1834 эш.

***Сәлахова Эльмира Кадим кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 383

*Ф.Ш. Зарипов,*
*Р.И. Сафина*

# МАТЕМАТИКА ФӘНЕН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ УКЫТУ ҺӘМ ТЕЛНЕ САКЛАУ

В Республике Татарстан существует проблема подготовки учителей для школ с татарским языком обучения. Эта проблема связана с тем, что в рамках программы сохранения родного языка не учтены многие факторы по подготовке учительских кадров, а также влияние языка обучения на формирование мышления детей, что в конечном итоге приводит к когнитивным издержкам и не создает необходимой подпитки для сохранения и развития языковой культуры.

В статье обосновывается необходимость подготовки учителей математики, для школ с национальным языком обучения, по специализированной программе «Математика, информатика и информационные технологии в билингвальной татарско-русской среде». В целом работа посвящена обсуждению научно-методических аспектов проблемы билингвального образования.

**Ключевые слова:** сохранение языков, татарский язык, математика, высшее образование, билингвальное математическое образование.

Казан (Идел буе) федераль университетында (КФУ) Н.И. Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институтындагы (ММИ) педагогик белем бирү бүлегендә математика һәм информатика буенча укытучылар әзерләү системасы – уникаль системалардан санала. Ул КФУда математика буенча бердәнбер татарча кадрлар әзерләү методикасы булып тора. Әлеге система, бер яктан, татар телен саклау, аны фән теле буларак үстерү юнәлешендә зур роль уйнаса, икенче яктан, милли мәктәпләрдән талантлы яшьләрне эзләүдә ярдәм итә. Педагогик белем бирү бүлеге КФУ составына кушылган элекеге Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының (ТДГПУ) математика факультеты нигезендә барлыкка килде.

1990 елларда ТДГПУның математика факультетында милли мәктәпләр өчен татар телендә математика һәм информатика буенча укытучылар әзерләү төркемнәре булдырылды [Салехова, Зарипов, 2012; Зарипов, 2013]. Бу төркемнәрдә укыту билингваль нигездә – рус һәм татар телләрендә алып барылды. Әлеге укытуның төп максаты булып ике телдә дә иркле аралашучы белгечләр әзерләү торды. Төркемнәрдә нигездә республика районнарының татар мәктәпләрен һәм гимназияләрен тәмамлаган студентлар укыды. Математик терминология бер үк вакытта рус һәм татар телләрендә бирелде. Шулай итеп, студентлар үзләре сайлаган фәннәрне республиканың ике дәүләт телендә үзләштерү һәм шул ук вакытта күп кенә математик

терминнарның инглиз телендәге эквивалентларын да өйрәнү мөмкинлегенә ия булдылар.

Шунысын да әйтергә кирәк, татар телендә укыту, коллектив укытучыларының үз инициативасы буенча оештырылды. Алар үзләренең лекцияләрен татар теленә тәрҗемә итеп, югары математиканың барлык курслары буенча лекцияләрне татар телендә укыдылар. Практик дәресләр дә әлеге тәртиптә алып барылды.

Укыту процессын бу рәвешле ММИдагы бакалавриат төркемнәренең саны бердән артык булган очракта гына тормышка ашырырга мөмкин иде. Элек, уку йорты теләк белдергән абитуриентлар арасыннан (нигездә милли мәктәпләрне тәмамлаучылардан) татар телендә укытылачак бер яисә ике төркем оештыра алды.

Татарча укытуга күчү бик күп мәсьәләләрне хәл итү бурычын куйды. Мәсәлән: татар телендә укытучы кадрлар булдыру, аларны методик, фәнни әдәбият белән тәэмин итү. Соңгы 20 ел эчендә математика фәне буенча татар телендә күпсанлы уку-укыту һәм методик әсбаплар эшләнде, терминологик сүзлекләр, методик кулланмалар нәшер ителде.

Бу чорда татар телендә укыту төркемнәрендә 500 дән артык студент укып чыкты, аларның күбесе Татарстан мәктәпләрендә эшли, математика һәм информатика фәннәрен татар телендә укыталар, араларында фән кандидатлары да бар.

2011–2014 елларда «Педагогик белем» юнәлеше бакалавриатының «Билингваль татар-рус мохитендә математика, информатика һәм информацион технологияләр» профиле буенча 64 студент кабул ителде, укырга керүчеләрнең өч фән буенча БДИ күрсәткечләре уртача 200 балл тәшкил итте.

Математика фәненә баланы нинди телдә өйрәтергә соң? Үз туган телендәме, әллә киң таралыш алган телдәме? Бу гади сорау түгел, ләкин без аңа җавапны беләбез: математиканы ике телдә укытырга кирәк. Башлангыч этапта – башлангыч сыйныфларда белем алучы балаларда туган тел күнекмәләре формалаша, аларда уйлау, фикер йөртү туган телдә башкарыла. Бу этапта абстракт фикерләү яралгылары формалаша һәм алар субъектның алда булачак фикерләү үсешенә нигез булып торалар. Артык катлаулы математик структураларны башка телдә өйрәнүгә күчү (мәсәлән, югары математиканы) абстракт математик фикерләү үсешенең тоткарлануына китерергә мөмкин. Әлеге хәл килеп чыкмасын өчен, башлангыч этапта математиканы билингваль мохиттә өйрәнү нәтиҗәлерәк. Ә моны тормышка ашыру өчен, билингваль нигездә укытырга сәләтле укытучыларны әзерләү зарур. Бу, үз чиратында, «Туган тел» һәм «Математика» фәннәре арасындагы үзара бәйләнешләрне өйрәнүнең актуальлеген билгели.

М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты ректоры В.А. Садовничий әйтүенчә: «Математика һәм әдәбият – цивилизациянең ике төп баганасы, шуларның берсенең

җимерелүе дә цивилизацияне җимерә» (Бөтенроссия рус теле һәм әдәбияты укытучылары съездындагы докламы, 2012 ел) [Садовничий]. Бу сүзләрне татар телен математик белем бирү теле итеп саклау мәсьәләсенә карата да кулланырга мөмкин.

Монда кайбер төп моментларга игътибар итү сорала. Уй-фикерләрнең, формалашуы (шул исәптән математика өлкәсендә дә) әдәбият белән турыдан-туры бәйләнгән. Шулай ук теоремаларны, математик исбатлауларны тасвирлауның да тел һәм культура белән бәйле аерым үзенчәлекләре бар.

Бу темага кагылышлы В.Н. Кутруновның әйткән фикерләре бик кызыклы: «Бөтен логика нәкъ менә телдә чагыла. Без – математиклар – теорема исбатлаганда сүзләрне кулланабыз, сөйлибез һәм шуның нәтиҗәсендә бер-беребез белән бәхәсләшә, уртак фикергә килә алабыз. Күптән түгел мәктәп темасына мәкалә язганда мин аны "Математика – ул безнең мәдәниятебезнең мөһим бер аспекты. Тел белән берлектә...", – дип башладым» [Kutrunov].

Билингваль укыту проблемаларына багышланган фәнни мәкаләдә [Салехова, 2015], мөмкин чыгымнар һәм аларның төрләре тикшерелгән. Педагогик экспериментта Татарстан Республикасының ике телле татар-рус мәктәпләреннән 39 бала катнашкан. Экспериментан күренгәнчә, әгәр дә фәнне өйрәнгән тел белән контроль эшләнә торган тел аерылса, нәтиҗәдә укучыларның мәгълүматны эшкәртү тизлеге һәм төгәллеге тоткарлана.

Тел мәдәниятен камилләштерүгә дә математиканы өйрәнүнең уңай йогынтысы бар. Укучылар математик текстларны формалаштыру белән шөгыльләнгәндә, аларның тел күнекмәләре дә яхшыра. Мәсәлән, үз фикерләрен логик яктан дөрес итеп формалаштырырга өйрәнгәндә, аларның сүзлек запасы арта, байый.

Биредә геометрия курсын татар телендә укыту тәҗрибәсеннән чыгып, мисал китерү урынлы булыр. Лекцияләргә әзерләнгәндә, мин рус телендәге математик текстларны татар теленә тәрҗемә иттем. Чөнки югары геометрия фәненең күп кенә бүлекләре буенча татар телендә дәреслекләр гомумән юк. Кайбер сүзләрне татар теленә тәрҗемә иткәндә, кызыклы күренешләр барлыкка килде. Кайбер математик терминнарны татар теленә ничек тәрҗемә итәргә дә белмәдем. Лекцияләрдә студентлар белән бу темаларга дискуссияләр үткәрдек. Мәсәлән, рус телендәге «образующая кривых» сүзтезмәсен, уртак тырышлык белән, «кәкреләрнең урап үтүчесе» формасында тәрҗемә иттек. Әлеге эш студентларда күп кенә уңай эмоцияләр тудырды. Тел һәм математика сорауларының гармоник бәйләнеше дәресләрдә аларда бу фәннәрне өйрәнүгә өстәмә психологик мотивация барлыкка китерде.

Мәкаләдә күтәрелгән төп проблема беркемне дә битараф калдырмады. Әлеге проблемага карата җәмгыятьнең,

шул исәптән, бу проблема белән якыннан таныш булган студентларның фикерен белү максатыннан, «Педагогик белем» юнәлеше бакалавриатының «билингваль татар-рус мохитендә математика, информатика һәм информацион технологияләр» профиленең 5 нче курс студенты Сафина Рәзинә Илдус кызы үзенең курсташлары арасында социологик сораштыру уздырды. Әлеге сораштыруда 54 кеше катнашты һәм бүгенге көндә актуаль булган, безне борчыган түбәндәге сораулар каралды:

1. Татар теленә карашыгыз? Телнең киләчәге нинди булыр? Сез аны ничек күз алдына китерәсез?

2. Татар телен мәктәпләрдә нинди формада өйрәтергә? Калган фәннәрне татар телендә укытуга сез ничек карыйсыз?

3. Техник фәннәрне татар телендә алып бару БДИ нәтиҗәләренә тискәре йогынты ясыймы?

4. Югары уку йортларында татар телендә укытылган төркемнәр кирәкме?

5. Киләчәктә укытучы булып эшләргә телисезме? Сез математика фәнен татар телендә укытырга ризамы?

Студентлар арасында үткәрелгән социологик тикшеренүләрдән күренгәнчә, катнашучыларның 70% ы татар теле мәктәпләрдә булырга тиеш дип саный. Алар аның киләчәген уңай яктан күз алдына китерә. Безне борчыган 2 нче сораугa килгәндә, татар телен факультатив формада укытырга һәм кыскартырга дип әйтүчеләрнең саны 40% тәшкил итте, ә студентларның калган 60% ы «татар теле мәктәпләрдә моңарчы нинди күләмдә укытылган – шулай сакланырга тиеш» дип җавап бирделәр. Калган фәннәрнең татар телендә алып барылуына уңай караучылар күбрәк булып чыкты – болар сораштыручыларыбызның 67% ын тәшкил итте. Әлеге сорау буенча студентларда күп кенә кызыклы һәм уйланырга мәҗбүр иткән фикерләр туды. Алар карашынча, мәктәпләрдә татар телен саклап калуны, иң беренче, чиратта авыл һәм районнарда урнашкан татар (милли) мәктәпләреннән башларга кирәк. Нәкь менә әлеге уку йортларында бу юнәлештә төрле чаралар үткәрү, математика һәм башка фәннәрне татар телендә укыту һәм әлеге мәктәпләргә финанс яктан ярдәм күрсәтү мөһим. Башка милләт вәкилләренә татар телен өйрәтер алдыннан, башта татар кешесендә үз ана теленә мәхәббәт һәм ихтирам уяту, аның җәмгыятьтәге ролен аңлату зарур. Димәк, мәктәпләрдә татар балаларын ана телләрендә белем алудан аермаска кирәк, бәлки менә шул фактор татар телен дәүләт теле буларак саклап калу юлында беренче адым булып торадыр.

«Техник фәннәрне татар телендә алып баруның БДИ нәтиҗәләренә тискәре йогынтысы булмасмы?» дигән сорау безне генә түгел, бик күп яшьләрне борчый икән. Социаль тикшерүдә катнашырга теләк белдергән студентларның күпчелеге татар мәктәпләрен тәмамлап ирешкән студентлар булып

чыкты. Ләкин, арада башка фикердә торучылар да булды. Алар татар мәктәбен тәмамлап, БДИны рус телендә тапшыру кайбер уңайсызлыклар тудыра, дип санылар. Биредә фәнне өйрәнгән тел белән контроль эшләнә торган тел арасындагы аерымлык проблемасы туа. Шуңа күрә, бу студентларның күбесе алга таба техник фәннәрне бары тик рус телендә укыту ягында торалар. Ләкин, аларның кайберләре проблеманы башка яктан күрә. Алар фикеренчә, чыннан да, әгәр фәнне өйрәнгән тел белән контроль эшләнә торган тел аерыла икән, укучыларның мәгълүматны эшкәртү тизлеге дә һәм төгәллеге дә кими. Шул ук вакытта әлеге студентлар татар мәктәбен тәмамлаган укучыларга БДИны татар телендә бирү уңайлы, дип саныйлар.

Хәзерге вакытта, төп проблемаларның берсе булып, татар телендә укытырга сәләтле белгечләрләрнең кимүе, җитмәве тора. Шул проблеманы алга сөреп, без студентларга түбәндәге сорауны бирдек: «Югары уку йортларында, математика фәнен татар телендә укытырга сәләтле белгечләр әзерләүче төркемнәр кирәкме?» Студентларның 75% ы, әлеге сорауга: «әлбәттә кирәк, бу – татар теленең яшәешенә, үсешенә, дәүләт теле буларак камилләшүенә беренче зур адымнарның берсе» дип җавап бирделәр.

Безнең уку йортына, киләчәккә планнарын анык күзаллап аяк баскан яшьләр үз тормышларын укытучы һөнәре белән бәйләргә бик теләп риза. Сораштырулардан күренгәнчә, математика фәнен нәкъ менә татар телендә укытырга риза булган студентлар шактый күп булып чыкты.

Биредә югарыда әйтелгәннәргә йомгак ясап, яшүсмерләргә һөнәри юнәлеш бирү өчен, барлык мөмкинлекләрдән файдаланучы уку йорты, заманнан – яңалык, тәҗрибәдән – акыл һәм белем, ә үткәннәрдән үрнәк һәм әхлак үзләштерүче студентлар булганда, безнең татар теленең үсеше, алга китеше бар дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин.

Телне алга таба саклау һәм үстерү өчен, аны һәрвакыт яңа фәнни-техник тенденцияләр белән баетып тору да сорала. Математика фәнен туган телдә укыту – шуның үтемле чарасы. Мәсәлән, без дәресләрдә куллану өчен, «GeoGebra» математик программасына нигезләп, геометрия фәненнән татар телендә дәреслек әзерлибез. Биредә, югарыда телгә алынган «XXI гасырда әдәбият һәм математиканы аермаска, алар бербөтен булганда гына югары үсеш алган җәмгыять тудырырга сәләтле» дигән фикер аеруча актуаль булып тора.

**Әдәбият**

*Зарипов Ф.Ш.* Проблемы школьного математического образования и подготовки учителей математики и информатики на основе методов математического и дидактического моделирования. Электронный методический журнал: KAZANOBR.RU. 2013. № 6. Адрес публикации: http://smi.kazanobr.ru/6/08.php.

*Зарипов Ф.Ш.* Проблемы подготовки учителей на основе билингвального математического образования // Сборник: XXIII международная конференция «Математика, образование, информатизация», Казань: КФУ, 2015. С. 30.

*Kutrunov V.N.* Civilization and prostheses. On the modern technology of education // Mathematics and Information Technology in science education. Collection of scientific papers. Tyumen: Tyumen State University Publishing House, 2014, P. 166–191. http://cyberleninka.ru/article/n/slovesnost-i-matematika-neobhodimo-vosstanovlenie-bylogo-edinstva.

*Садовничий В.А.* http://philol.teacher.msu.ru/thesis/sadovnichiy

*Салехова Л.Л, Зарипов Ф.Ш.* Математическое и дидактическое моделирование как основа подготовки учителей двойного профиля (математика и информатика). Изд-во Казан. ун-та, 2012. 47 стр.. Электронный вариант http://libweb.ksu.ru/ebooks/publicat/05_A5m-000001.pdf

*Салехова Л.Л.* Когнитивные издержки билингвального обучения. Philology and culture. 2015. № 2(40). P. 314–317. http://cyberleninka.ru/article/n/kognitivnye-izderzhki-bilingvalnogo-obucheniya#ixzz45F5gYLkr

*Zaripov F.Sh.* Problems and experience in training teachers of mathematics and computer science for the bilingual environment (tatar-russian) II. International leading teachers summit 15–17 July 2016. Skopje, Macedonia. Proceedings and Workshops Abstracts. 2016. P. 36.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Зарипов Фәрхәт Шәүкәт улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Н.И. Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институтының педагогик белем бирү бүлеге мөдире*

***Сафина Рәзинә Илдус кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты Н.И. Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институтының «Педагогик белем» юнәлеше бакалавриатының «билингваль татар-рус мохитендә математика, информатика һәм информацион технологияләр» профиле студенты*

УДК 373.4 + 811.512.145

***Л.М. Гиниятуллина,***
***М.М. Шәкүрова***

# «ТУГАН ТЕЛ»НЕ УКЫТУНЫҢ ЯҢАЧА ЭЧТӘЛЕГЕ

В статье рассматриваются актуальные проблемы современной методики преподавания предмета «Родной язык». Преподавание родного (татарского) языка предусматривает ознакомление учащихся со спецификой татарского языка и овладение им как средством общения, познания, самореализации и социальной адаптации в поликультурном, полиэтническом мире. Уделяется отдельное внимание обновленному содержанию образовательного процесса и перспективам обучения родному языку.

**Ключевые слова:** родной язык, татарский язык, образовательный процесс, компетенция.

Бүгенге көндә җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләр укуукыту системасының барлык өлкәләренә дә яңача якын килүне таләп итә. Укыту-тәрбия системасын яңарту ул – үрнәк белем бирү һәм үрнәк эш программаларына нигезләп, инновацион технологияләр, яңа ысуллар, алымнар, чаралар, кулай принциплар эзләү, иң отышлы компетенцияләргә нигезләнү дигән сүз. Бүгенге көндә белем бирү оешмаларының бурычы – хәзерге көн таләпләренә, тормыш ихтыяҗларына җавап бирердәй белемле, тирән фикер йөртүгә сәләтле, актив социаль позициядә торган, креатив, карарларны мөстәкыйль кабул итә белгән иҗади шәхес тәрбияләү.

Татар теле – Россиядә сан ягыннан икенче урында торган, күбесенчә Татарстан Республикасында, шулай ук Россия Федерациясе субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә яшәүче татарларның туган теле. Ул Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр» Законы нигезендә дәүләт телләренең берсе статусына ия.

Федераль белем бирү стандарты һәм югарыда күрсәтелгән документлар нигезендә татар телен төп ике юнәлештә укыту күздә тотыла: «Туган тел» (туган телләре татар теле булган укучыларга татар телен өйрәтү) һәм «Дәүләт теле» (туган телләре татар теле булмаган укучыларга, ягъни татарлардан башкаларга татар телен өйрәтү).

1 нче таблица



«Туган тел» юнәлеше үз чиратында тагын икегә бүленә:

1) база өлеше (рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы татар балаларына туган телне (татар телен) өйрәтү);

2) тирәнтен өйрәнү өлеше (татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга туган телне өйрәтү).

Алдагы уку елында гомуми белем бирү оешмаларында туган телне укытуның эчтәлегенә караган үзгәрешләр көтелә. Беренчедән, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан эшләнгән уку планына тәңгәлләштереп, предметның исеме үзгәрә («Туган тел»). Икенчедән, яңа юнәлештә белем бирүдә төп игътибар коммуникатив компетенциягә, ягъни туган телдә дөрес, матур итеп сөйләшергә, логик эзлекле, иҗади, креатив рәвештә уйларга, мөстәкыйль эшләргә өйрәтүгә, әлеге процессны лингвистик (тел) һәм социомәдәни компетенцияләр белән бергә бәйләп алып баруга бирелә, ягъни компетенцияләр бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән, бер-берсен һәрдаим тулыландырып торырга тиеш.

Өченчедән, элеккеге кебек, рус мәктәбе, рус мәктәбенең татар төркемнәре, татар мәктәбе дигән бүленеш урынына дәүләт теле һәм туган тел (база өлеше, тирәнтен өйрәнү өлеше) дигән бүленеш кала. База өлеше (рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы татар балаларына туган телне (татар телен) өйрәтүне үз эченә ала. Тирәнтен өйрәнү өлеше дигәндә, татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга туган телне өйрәтү күздә тотыла.

Дүртенчедән, лексик темалар («Мин», «Тирә-як, көнкүреш», «Туган җирем», «Татар дөньясы») аша укучының иптәшләренә, гаиләсенә, әйләнә тирәгә, Туган иленә, татар дөньясына үз мөнәсәбәтен белдерә алуы, шулар ярдәмендә сөйләмне үстерү, тел байлыгын арттыру, туган телне өйрәтү күз уңында тотыла. [Шәкүрова, Гыйниятуллина, 2018, б. 5].

2 нче таблица

| **БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ** | | |
|---|---|---|
| **ЭЛЕККЕГЕ ВАРИАНТ** | **ЧАГЫШТЫРУ ЛИНИЯСЕ** | **ЯҢАРТЫЛГАН ВАРИАНТ** |
| *ТАТАР ТЕЛЕ* | **УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ИСЕМЕ** | *ТУГАН ТЕЛ*<br>*ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ* |
| *ЛИНГВИСТИК*<br>*КОММУНИКАТИВ*<br>*ЭТНОМӘДӘНИ* | **КОМПЕТЕНЦИЯЛӘР** | *КОММУНИКАТИВ*<br>*ЛИНГВИСТИК*<br>*СОЦИОМӘДӘНИ* |
| *РУС ТӨРКЕМЕ*<br>*ТАТАР ТӨРКЕМЕ*<br>*ТАТАР МӘКТӘБЕ* | **ДӘРӘҖӘ** | *ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ*<br>*БАЗА ӨЛЕШЕ*<br>*ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНҮ* |
| *Рус төркемнәрендә 12–17 лексик тема тәкъдим ителә; татар балалары белән эшләгәндә, лексик темалар күрсәтелми* | **ЛЕКСИК ТЕМАЛАР** | *«МИН»*<br>*«ТИРӘ-ЯК, КӨНКҮРЕШ»*<br>*«ТУГАН ҖИРЕМ»*<br>*«ТАТАР ДӨНЬЯСЫ»* |

«Туган тел»не өйрәнү барышы компетенцияләргә нигезләнә. Компетенция – латинчадан ирешү, тиешенчә ярашу, нигезләү мәгънәсен аңлата. «Туган тел»дән белем бирүнең максаты – Федераль дәүләт белем стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә, лексик темаларга нигезләп, укучыларда коммуникатив (аралашу осталыгы), лингвистик (тел), социомәдәни компетенцияләр булдыру.

Коммуникатив компетенция – укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә караган ныклы күнекмәләр формалаштыруны күздә тота. Мәсәлән, сөйләм эшчәнлегенең (ягъни сөйләмиятнең) төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) аша укылган яки тыңланган текстның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңлау; текстны файдаланып, әңгәмә үткәрү, төрле стильгә һәм жанрга караган текстларны дөрес уку һәм аңлау; тәкъдим ителгән темалар буенча диалогик һәм монологик сөйләм оештыру (парлап эшләү); төрле чыганаклардан мәгълүмат туплау; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалану; сөйләм этикеты нормаларын белү, аларны сөйләмдә дөрес куллану һ.б.

Лингвистик компетенция формалаштыру өчен тел гыйлеменең бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән барлык тармакларыннан (фонетика, графика, орфография, орфоэпия, лексикология, сүз төзелеше һәм ясалышы, морфология, синтаксис, пунктуация, стилистика һәм сөйләм культурасы) төп фәнни мәгълүматлар туплау һәм аларны сөйләмнең нигезенә салу сорала. Бу очракта билгеле бер контекст эчендә авазлар, интонация, сүзләрнең лексик һәм грамматик мәгънәләрен, ясалышын, җөмлә калыпларын, дөрес әйтелеш һәм язылыш кагыйдәләрен, тыныш билгеләрен һәм башкаларны бербөтен итеп системалаштырып бирү күздә тотыла. Димәк, тел гыйлеме бүлекләре, бер-берсе белән тыгыз бәйләнеп, гамәли яктан, ныклы сөйләм күнекмәләрен булдыру максатыннан өйрәтелә. Мәсәлән, әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен караганда, интонациягә, тыныш билгеләренә игътибар ителә, сүзләрнең контекстта чагылыш тапкан лексик мәгънәләре ачыклана, язылышы һәм дөрес әйтелеше искәртелә, кыен әйтелешле авазлар белән дә эшләргә туры килә. Кызганычка каршы, укыту барышында сөйләшү, аралашу, бала тарафыннан теге яки бу вакыйгага мөнәсәбәт белдерү кебек эш төрләре игътибардан читтә калып килде, нәтиҗәдә укучының туган теле белән кызыксынуы кимеде. Дәресләрдә лексик темаларның аз булуы (кагыйдәгә туры китереп, әдәби әсәрләрдән алынган җөмләләр белән эшләү) процессны катлауландырды гына.

Социомәдәни компетенциянең эчтәлеген укучыларның сөйләмен үстерү һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү, сөйләм калыбына нигезләп, язу осталыгын булдыру; телнең орфоэпик һәм интонацион нормаларын саклап, фикерне җиткерү; көндәлек аралашуга бәйле сөйләм этикеты үрнәкләреннән дөрес файдалану (сәүдә үзәкләрендә, күңел ачу паркларында, театрда,

музейда, концертлар залында, транспортта, урамда үзеңне тота белү (сәламләү, хушлаша белү, гафу үтенү, рәхмәт әйтә белү, сорау яки үтенеч белән мөрәҗәгать итү һ.б.); телнең милли мәдәниятне чагылдыру формасы булуын аңлату, тел чаралары, сөйләм репликалары ярдәмендә халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлекләрен өйрәнү һ.б.) тәшкил итә [Гиниятуллина, Шакурова, 2018, б. 370].

Туган телне укытуның сыйфатын күтәрү, һәр сыйныфта аны эзлекле үзләштерү, сөйләмне дөрес төзеп, әдәби тел нормаларына туры китереп, телдән һәм язма рәвештә башкаларга җиткерә белү, туган телне өйрәнүнең нигезенә коммуникатив принципны салу бүгенге көн мәгариф системасы алдында торган мәсьәләләрнең иң мөһиме санала. Шуңа күрә «Туган тел» предметын укытуның эчтәлегенә караган төп яңалыкларның берсен белем бирү барышында коммуникатив компетенция формалаштыру тәшкил итә.

Аның өстенлекле якларыннан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

1) сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен тормышка ашырырга мөмкинлек бирә;

2) укучыларда телгә карата кызыксыну һәм сөйләшергә омтылыш уята;

3) телнең аваз системасы белән эшләргә һәрдаим юл күрсәтә;

4) лексик минимумны төгәл ачыклап, укучының сүз байлыгын арттыруына, яңа сүзләрне сөйләмгә кертүенә юнәлеш бирә [Шәкүрова, 2012, б. 27]

Коммуникатив компетенция, лингвистик һәм социомәдәни компетенцияләр белән тыгыз үрелеп, аларны һәрвакыт тулыландырып тора. Лексик материал фикернең эчтәлегенә бәйле рәвештә грамматик кагыйдәләр һәм сөйләм репликалары белән кертелә.




Югарыда бирелгән диаграммадан күренгәнчә, һәр дәрестә өйрәнелә торган материалның яртысыннан күбесе коммуникатив, калганының дүрттән өч өлеше (¾) лингвистик һәм дүрттән бере (¼) социомәдәни компетенция формалаштыруга юнәлтелгән булырга тиеш. [Шәкүрова, Гыйниятуллина, 2018, б. 9]

Һәр сыйныфта лексик материал үзара бәйләнгән дүрт блокка берләштереп бирелә: «Мин», «Тирә-як, көнкүреш», «Туган җирем», «Татар дөньясы».




Сөйләм телен үстерү максатыннан, беренче блок – «Мин» укучының үз мөнәсәбәтен белдерүгә юнәлтелгән лексик берәмлекләр белән эш итүен күздә тота: минем гаиләм (якын туганнарым), ерак кардәшләрем; туганнарны сәламләү, якын итә белү, алар белән аралаша белү;

туганлык серләрен сакларга өйрәтү; минем шөгылем; яраткан героем, яраткан язучым (шагыйрем), киләчәк көн һөнәрләренә карата минем мөнәсәбәтем һ.б.

Икенче блок – «Тирә-як, көнкүреш» дип атала. Биредә төп игътибар укучыларны кешелекле, иҗади, актив, мөстәкыйль, әйләнә-тирәне күзәтә, табигатьне саклый белә торган шәхес итеп тәрбияләүгә юнәлтелә. Йортҗир, Туган як табигате, Интернет челтәрендә, социаль челтәрләрдә дөрес аралашу, Россия һәм чит ил югары уку йортлары, бүгенге көн модасы бәйле темалар тәкъдим ителә. Әлеге блок сөйләмне үстерүне, тел байлыгын арттыруны күз уңында тота һәм үз эченә һөнәрең белән кешеләрне куандыру, яраткан һөнәр сайлау, аның серләренә төшендерү, һөнәр сайларга өйрәтү кебек шәхси һәм коммуникатив универсаль уку гамәлләрен тормышка ашыруга ярдәм итә торган лексик темаларны ала.

Өченче блок – «Туган ил». Аның кысаларында татар халкы һәм Россия Федерациясе субъектлары халыкларының гореф-гадәтләре, традицияләре аша укучыларда гражданлык, патриотик хисләр, туган илгә карата хөрмәт, мәхәббәт уяту; Россия һәм чиктәш илләр, чит илләр белән мөнәсәбәтләр, Европа һәм Азия илләре, акча берәмлекләре, Туган илнең тарихи һәйкәлләре һәм истәлекле урыннары, чит илләрдә яшәүче татарлар, Туган илем – Россия буйлап сәяхәт итү һ.б. темаларны өйрәнү күздә тотыла.

Дүртенче блок – «Татар дөньясы». Биредә милли менталитет, фәлсәфә, үзаң, әхлак кануннары белән таныштыру, аерым алганда Сөембикә, Казан турында легендалар, татарлар һәм Россиядә яшәүче башка халыкларның милли һөнәрчелеге, татар әхлагы, татар халкының бизәнү әйберләре (беләзек, йөзек, балдак, алкалар һ.б.); татар зыялылары, татар театры тарихы, татар кино сәнгате, Идел буе халыкларының милли бәйрәмнәре («Сабантуй» (татар), «Каравон» (рус), «Гырон-быдтон» (удмурт), «Уяв» (чуваш), «Балтай» (мордва), «Семык» (мари), «Питрау» (керәшен), Татар халык уеннары, Татар кәсебе (кашыклар, чүлмәкләр ясау, итек басу, тегү, чигү, курай, гармун ясау һ.б.) кебек темаларны һәм алар белән бәйле сөйләм репликаларын өйрәнү күз уңында тотыла.

Мисал өчен 1 нче сыйныфта лексик теманың морфология, синтаксис бүлекләре белән үреп бирелеше алдагы слайдта тәкъдим ителә. «Татар дөньясы» блогы кысаларында өйрәнү өчен «Татар халык уеннары», «Җырлы биюле уеннар», «Башка халыкларның милли уеннары» кебек темалар бирергә мөмкин. Морфология һәм синтаксистан ике дәрәҗәгә (база өлешенә һәм тирәнтен өйрәнү өлешенә) аерып бирелгән теоретик материал коммуникатив һәм социомәдәни компетенцияләр җирлегендә формалаштырыла. *Кем? Нәрсә? Нинди? Ничә? Күпме? Кайда? Кая? Нишли?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр, җөмләдә сүз тәртибе, әйтү максаты буенча җөмлә төрләре сөйләмә һәм язма телне камилләштерүдә мөһим роль уйнарга тиеш.

3 таблица

| 1 нче сыйныф | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Тема | *Коммуникатив компетенция формалаштыру* | *Лингвистик компетенция формалаштыру* | | *Социомәдәни компетенция формалаштыру* |
| | | *База өлеше* | *Тирәнтен өйрәтү* | |
| Татар дөньясы | Татар халык уеннары («Буяу сатыш», «Яшерәм яулык», «Без-без, без идек», «Башмакчы», «Йөзек салыш»).<br><br>Җырлы биюле уеннар: «Түбәтәй», «Чума үрдәк, чума каз», «Ак калач».<br><br>Башка халыкларның милли уеннары «Змейка», «Салки» (рус халык уеннары).<br><br>«Бакыр бүкән» (башкорт халык уены). «Йомышчы» (якут халык уены).<br><br>«Чур, все!» (тизәйткечләр белән качышлы уены) (коми халык уены) | *Кем? Нәрсә?* сорауларына җавап бирә торган сүзләрне татар һәм рус телләрендә чагыштыру. *Нинди?* соравына җавап бирә торган сүзләр. *Ничә? Күпме?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. *Кайда? Кая?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. *Нишли?* соравына җавап бирә торган сүзләр. Җөмләдә сүз тәртибе. | *Кем? Нәрсә?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр *Нинди? Кайсы?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. -рак/-рәк кушымчалары ярдәмендә предметларның билгеләрен чагыштыру. *Ничә? Ничәнче? Күпме?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. *Кайчан? Кайда? Кая?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. *Нишли? Нишләгән? Нишләде?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. | Сөйләм этикетының милли үзенчәлекләре: тыйнаклык, итагатьлелек, бер-береңә юл куя белү. Әңгәмәдәшеңә яхшы мөгамәләдә булу. Милли уеннар белән танышу. Уен этикеты. Яраткан уен, уенчыклар турында кыскача мәгълүмат бирергә өйрәтү. |

Туган телне өйрәнү барышында лексик, грамматик материалны кызыклы, тормыштан алынган вакыйгаларга таянып бирү укучыларның телне өйрәнү теләген арттыра гына, аның тормышта кирәклеген төшенергә ярдәм итә. Шуңа күрә дәресләрдә төрле ситуацияләргә корылган, сөйләм репликалары белән баетылган, аларны чишәргә ярдәм итә торган күнегү-биремнәр тәкъдим итү, шуларга нигезләнеп, укучыларның аралашу осталыгын үстерүгә игътибарны арттыру зарур.

Хәзерге көндә тирән мәгълүматлы, югары белемгә ия булу гына җитми, ә бәлки белемне функциональ яктан гамәли эшчәнлектә куллану осталыгына өйрәтә белү кирәк. Сөйләмдә сүз төркемнәрен, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, җөмләләр тезмәсенең төрле калыпларын куллану сөйләмне кыска, ачык, аңлаешлы итеп формалаштыра, кирәкмәгән кабатлаулардан коткара. Белем бирү эчтәлеген яңарту, перспективаларны билгеләү максатында лексик темаларны практикага кертү, ныклы коммуникатив, лингвистик һәм социомәдәни компетенцияләр формалаштыру укыту эшчәнлеген камилләштерергә ярдәм итәргә тиеш.

**Әдәбият**

*Гиниятуллина Л.М., Шакурова М.М.* Роль народной педагогики при развитии разговорной речи учащихся // Тюркский мир и исламская цивилизация: проблемы языка, литературы, истории и религии. Елабуга, 2018. С. 369–371.

*Шәкүрова М.М.* Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр). Казан: Ихлас, 2012. 144 б.

*Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* Башлангыч сыйныфларда «Туган тел» предметын укыту: яңартылган эчтәлек һәм перспективалар. Методик ярдәмлек. Казан, 2018. 40 б.

*Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* 5–9 нчы сыйныфларда «Туган тел» предметын яңача укыту. Методик ярдәмлек. Казан, 2018. 36 б.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Гиниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 745

*Л.Н. Донина*

# ТАТАРЛАРНЫҢ ЧҮКЕП ЯСАЛГАН БИЗӘКЛӘРЕ ТЕХНОЛОГИЯСЕ ҺӘМ ОРНАМЕНТАЦИЯСЕНДӘГЕ МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР ТУРЫНДА

В статье рассмотрены этноспецифические особенности татарской чеканки. Технология и орнамент, знаково-образная система и трактовка мотивов сложились на основе совокупности технических приёмов и эстетических предпочтений, характерных для золотоордынской торевтики. Статья основана на результатах исследования ювелирного искусства казанских татар в технико-технологическом аспекте.

**Ключевые слова:** Золотая Орда, каллиграфический орнамент, мотив птицы, растительный побег, чеканка насечкой.

Зәркән эшләнмәләр үзләренең мәгълүмати киңлеге (техник-технологик параметрлары, формаль-морфологик билгеләре, орнаменталь тамгалары һәм символлары) ягыннан халыкның этномәдәни тарихы белән тыгыз бәйләнешле традицион сәнгать үсеше этапларын билгеләүдә фундаменталь чыганак ролен үтиләр.

2013–2014 елларда «Евразиядәге төрки халыкларның ювелир бизәкләре: уртаклыклары һәм үзенчәлекләре» (РФФИ № 13–06–97056) дигән тикшеренү проекты кысаларында Казан татарларының һәм Евразиянең башка халыкларының Россиянең эре музей фондларында һәм махсус саклау урыннарындагы бизәлеш технологияләре традицияләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә башлады. Татарстан Республикасы Милли музее фондларындагы төрле технологияләр (филигрань, чүкү, граверлау) нигезендә эшләнгән бизәкләр рәсемгә төшерелде, ул XVIII–XIX гасырларда Казан татарларының ювелир эшчәнлеген үстерергә ярдәм иткән коралларның «эзләрен» күрергә, технологияләрнең генезисын һәм милли үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирде [Донина, Суслова, с. 222–236].

Татарларда зәркән эшләнмәләрне чүкеп бизәкләү зур үсеш ала алган. Аеруча тукыма әйберләргә (иңбаш каешы, күкрәкчәләргә) тегеп куя торган тәңкәләрне, шулай ук асма бизәкләрне һәм Коръән тышлыкларын чүкеп эшләгәннәр. Татарларның чүкеп эшләнгән бизәкләре аерым үзенчәлеккә ия. Чүкү коралы эзеннән аның *киртләү* (сырлап ясау) *ысулын* характерларга була. Эшләнмәдә ул рельефны формалаштыра, рәсемнең сызык рәвешендәге тамгаларын хәтерләтә. Еш кына чүкеп бизәкләүне чокып бизәкләү (гравировка) дип тә кабул итәләр, чөнки карап торышка ул аннан әллә ни аерылмый. Аларны гомуми стилистика гына аера: чүкеп

бизәгәндә яссы түбән рельефлы орнамент металл пластинаның шома өслегеен саклаган хәлдә башкарыла. Фон эчкә батып тормый, ә «түгәрәкләнгән» фактура белән тулыландырыла. Чүкеп бизәү өчен төрле диаметрдагы торбачык-чеканнан файдаланалар, ул металл өслегендә ярымтүгәрәк төерләр калдыра. Татарларның зәркәнчелек традицияләре шушы ысулга нигезләнгән.

Өслекне вак кына түгәрәкләр белән тулыландыру VIII–XI гасырлардагы согыдларның металлга бизәк төшерү ысулына хас [Даркевич, 2010, с. 72]. XII гасырдагы византиялеләрнең көмеш касәләре дә шушы алымга нигезләнгән [Даркевич, 1975, с. 102, 180]. XIII–XIV гасырлардагы Алтын Урда нәфис бизәкләре дә шушы юл белән эшләнгән [Федоров-Давыдов, с. 174–175]. XIX гасырда казакъ ювелир сәнгатендә дә чекан белән сырлап бизәү күзәтелә [Маргулан, с. 198–199; Сычева, с. 155], чүкеп бизәү башкортлар өчен дә хас [Шитова, с. 128–131].

Татар осталары, бизәк төшерү өслегенең формасы нинди булуга карамастан, орнаментлар композициясенең билгеле бер принципларын саклаганнар. Өслекнең үзәк өлешенә эпиграфик орнаментлар яки «шәҗәрә» мотивлары төшереп, аны каймасыман (үсемлек сабакларын геометрик формага салып, ике яклап дулкынландырып тоташкан) бизәкләр белән уратып алганнар. Табылган борынгы истәлекләрне анализлау күрсәткәнчә, татарларның чүкеп бизәкләү өлкәсендәге техник-технологик үзенчәлекләре һәм мотивлары Алтын Урта чоры мәдәнияте өчен характерлы булган, күчмә һәм утрак тормыш белән яшәүче халыкларның мәдәни казанышларын үзләштерү һәм аны җирле техник алымнарга, эстетик зәвыкка нигезләп эшкәртү нәтиҗәсендә формалашкан [Сокровища…, 2000].

Казан татарларының зәркән сәнгатендә орнаментлар технологиясе барлыкка килү һәм аның мотивлары закончалыклы күренеш. Идел буе һәм Урал төбәгендә хәзер яшәүче татарларның формалашуы XIII–XV гасырларга барып тоташа, ул – X гасырда ук инде мөселманлыкны кабул иткән төрки телле болгарлар белән күпсанлы угыз-кыпчак кабиләләренең әкренләп аралаша һәм кушыла башлавы нәтиҗәсе. Алтын Урдада бердәм төрки-татар халкының формалашу процессы XIII–XIV гасырларда ук башлана, һәм империядә яңа этнос – төрки-татар халкы барлыкка килә [Усманов, с. 34, 42]. XVI гасырда инде Идел–Урал регионы төрки-татар этносы, нигездә, формалашып җитә, һәм бу күренеш Идел һәм Урал буйларында башкортларның, татарларның аерылып чыгуына китерә [Халиков, с. 92–93]. Шулай итеп, Казан татарларының традицион мәдәнияте төрки, төрки-монгол һәм төрки-мөселман халыклар йогынтысында формалаша.

Шуны истә тоту мөһим, идарә итүчеләр династиясе, шулай ук аксөякләр катлавының билгеле бер өлеше ягыннан гына Җүчи Олысы монголларныкы санала, ә төп халкы буенча ул, яши

башлавыннан бирле, төрки дәүләт булып кала [Усманов, с. 33]. Алтын Урта зәркәнчелек сәнгатенең декоратив бизәкләү стиле механизмын «дала орнаменталызмы» исемен алган урта гасыр башы Евразия стиле контекстыннан башка аңлау мөмкин түгел. VIII гасырдан башлап, Бөек Далада һәм аның чикләреннән тыш та зәркән эшләнмәләрне үсемлек орнаментлары белән бизәү өстенлек иткән. Төрки халыкларның дөньяга карашының һәм аларда декоратив сәнгать үсешенең нигезен төрки кабиләләрдә идеаллаштырылган, мифологик һәм эпик сөйләм традицияләренә әверелгән үсемлекләрне гәүдәләндерү тәшкил итә [Федоров-Давыдов, с. 11, 22, 61].

Татарларның төсле металл тәңкәләрдәге чүкеп бизәлгән орнаментлары, нигездә, каллиграфик текстлардан гыйбарәт була [Донина, с. 64–79]. Ул өслек үзәгенең регистрына урнаштырыла, үсемлек сабаклары белән каймалана. Үзәк өслекнең регистрлары саф металл полосаларына бүленә, яки нәсх стиленә хас булган ирсал алымнары кулланыла.

2014 елда танылган әдәбият белгече һәм рәссам-каллиграф Н.Ф. Исмәгыйлов (тәхәллүсе – Нәҗип Нәккаш) тәңкәләргә гарәп хәрефләре белән язылган 50 ләп текстны тәрҗемә итте. Аларны өйрәнеп тикшерүдән ачыкланганча, түгәрәк тәңкәләргә *Һүә йәгъмәлү* (беренче юлда); *Мөһре шәрифә ирер* (икенче юлда) дип язылган (ТР Милли музее, инв. №№ 10198-86, 10221-218, 10221-247, 10221-227, 10221-281, 10221-293, 10221-36). Түгәрәк тәңкәләр татар милли киемнәре комплексын тәшкил иткән әйберләрнең һәркайсында диярлек кулланылган. Көнкүреш предметлары һәм бизәнү әйберләрен Коръәни тамгалар белән күркәмләндерү Аллаһка якынаюны аңлаткан. Моннан тыш, Коръән сүзләренең тылсымлы көченә ышану да «халык исламы»нда чагылыш тапкан. Каллиграфик текстлар явыз көчләрдән саклаучы бөти функциясен үтәгән. Коръән сүзләре һәртөрле зыяннан саклый, дип ышанганнар һәм аларны савыт-сабага, алкайөзекләргә, беләзекләргә, металл көзгеләргә, махсус металл такталарга язганнар, шулай ук кәгазь кисәкләренә язып, бөти итеп тагып йөргәннәр [Саблуков, с. 66].

*Чәч төбе* дип аталган турыпочмаклы итеп киселгән эре тәңкәләр аерым әһәмияткә ия. Алар сәнгати эшләнешенең сыйфаты белән аерылып торганнар, кемгәдер изге теләкләр юлланган тексттан гыйбарәт буларак, сулф почеркында нәсх элементлары кулланып язылганнар. *Чәч төбе чәчкап*ның (*тезмә*нең) өске өлешенә тегеп куела һәм мөселманнарда бөти (амулет) вазифасын үти. Мондый тәңкәләр урынына, *чәккапка*, еш кына, сихерләү максаты белән кәгазьгә язылган сөйдергеч *бөтиләре* дә тегеп куйганнар. *Чәч төбен* футляр формасында ясап, аңа догалар язылган кәгазьләрне салып, *хәситә* урынына файдаланганнар. Кызлар андый футлярда мәхәббәт сүзләрен истәлек итеп саклый торган булганнар [Воробьев, с. 294].

*Чәч төбе* тәңкәләрен бизәүдә «Мәгарә кешеләре» – *Йәмлиха,*

*Мәслинә, Мәксәлминә, Зәнүш, Мәрнүш, Сазнүш, Кафаштатиуш, Кытмир* дигән исемнәре еш кулланылган [Коран, 18; 9–26] (ТР ММ, инв. №№ 10221–129, 10221–215). Бу исемнәр хатын-кызларның яклаучысы булып саналган, һәм алар төрле материалга язылган. *Сахибегә һәр заманда бәлаләрдин сакласын Хак Тәбарәкә* дигән гыйбарә дә киң таралган (ТР ММ, инв. № 10221-230).

Үзәк композиция «үсемлек үрентеләре» белән каймалана. Бик борынгы үрнәкләрдә мотивның беренчел формалары да очрый. Алар, нигездә, зур күләмле һәйкәлләрдә һәм ислам илләрендәге гамәли сәнгать үрнәкләрендә бар [Веймарн, с. 14], Урта Азия илләрендәге биналарның архитектур бизәлешләрендә [Денике, с. 15], VIII–XIII гасырлар Урта Азиясе көмеш эшләнмәләрендә [Даркевич, 2010] кулланылган. Казан татарлары декоратив-гамәли сәнгатенең барлык төрләрендә (ташны кисеп бизәү, металлны рельефлап бизәкләү (торевтика), күн кисәкләреннән мозаика төзү, алтынлы һәм тамбурлы чигүдә) дә үсемлек үрентеләре (йөзем куагы ботагы) белән бизәкләү киң таралыш алган [Валеев], һәм, әлбәттә инде, алар бирелеше белән берберсеннән аерылып торганнар.

Чүкеп эшләнгән татар тәңкәләрендәге пальма үрентесе төшерелгән иконографик сурәтләрне без Алтын Урда чоры металл эшләнмәләре белән бәйләп карыйбыз. Бу мотивның берничә вариантын ачыклауга ирешә алдык. Вариантлылык гадиләштерүгә нигезләнә: оста, карауга ук мотивның асылына төшенү өчен, берничә юнәлеш сызыгы калдыра. Бу, эшләнмәне озак вакыт дәвамында бер урында җитештерү нәтиҗәсендә, мотивның халык сәнгатенә якынаюы хакында сөйли. Болгар беләзекләре өслегенә арыслан башын гәүдәләндерү дә шуңа охшаш күренешләрдән санала [Калинин].

Гомумән, татарлар тарафыннан чүкеп бизәлгән зәркән эшләнмәләрнең эстетик зәвыгын аңлау, эчтәлекләренең яшерен мәгънәсенә төшенү мөселман сәнгате принциплары контекстыннан башка мөмкин дә түгел. Әйтик, ислам сәнгатендә нәфислек төшенчәсе күләмне өч үлчәмле модельләштерүне күздә тотмый, ә өслекне сәнгати бизәүгә нигезләнә [Стародуб, с. 25]. Мөселман бизәлеше өчен нәфис сәнгатьтә өслекнең шартлы бирелеше форманың ике үлчәмле модельләштерелүеннән гыйбарәт. Бу фактор татар зәркәнчелегендә киң рельефлы итеп чүкеп бизәкләү үсешенә йогынты ясый. Шул ук чорларда Идел буеның Ярославль, Түбән Новгород, Кострома шәһәрләрендә исә төп урынны рельефлап чүкү били [Постникова-Лосева, с. 48].

Аллаһы Тәгаләнең исемнәрен данлау мөселман мәдәниятен формалаштыручы фактор булып санала. Үсемлек мотивлары ислам мәдәниятендә оҗмах метафорасын тәшкил итә [Шамсутов, с. 25] һәм, сүзнең график гәүдәләнеше [Шукуров, с. 46] белән бергә, сәнгати киңлекнең төп идеясен билгели. Коръәндә

күрсәтелгәнчә, хак диндәгеләр көчле үрентегә, сабакка тиңләштерелә [Коран, 48:29]. Мөселман сәнгатенең барлык өлкәләрендә дә чагылыш тапкан дини-эстетик күзаллаулар нәтиҗәсендә иҗат ителгән орнаментларның мотивлары «Җәннәт (оҗмах) бакчасы»ның метафорик образын гәүдәләндерүгә хезмәт иткән.

Татар чүкеп бизәкләү сәнгатендә тагын *канатларын җәеп торган кош* мотивы да киң таралыш алган. Алар түгәрәк тәңкәләргә төшерелгән каллиграфик композициянең өстәге юлының өстенә яки астагы юлының астына урнаштырыла. Эчтәлектән аңлашылганча, ул, төрки традицияләргә нигезләнеп, һавада оя корып, кешеләргә бәхет китерүче мифик Һомай кошы белән дә бәйләнгән [Черемисин]. Борынгы һәм кайбер хәзерге төрки халыклар тылсымлы Һомай кошы, һавадан төшеп, кешеләрне яклый, аларның балаларын саклый дип ышаналар [Король, с. 142].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Идел буендагы Казан татарларының зәркән сәнгатендә чүкеп (кирт-ләп) бизәкләү ысулы үсеш алган. Нигездә тәңкәләрне чүкеп бизәкләгәннәр. Бизәкләүнең төп мотивларын каллиграфик текст, геометрик характерда бирелгән пальма үрентеләре һәм канатларын җәйгән кош тәшкил иткән. Катнаш бизәкләр төшерүнең буыннан буынга күчә баруы һәм зәркәнчелек технологиясе үсеше татарларның милли (этник) тарихы белән бәйле. «Технология-орнамент» комплексы XIII гасырда – XIV гасыр башында Алтын Урда синкретик сәнгате (торевтика) йогынтысында нык-лап формалаша, һәм Дәште Кыпчак шәһәр мәдәнияте өчен яңа булган сыйфатларны чагылдыра.

## Әдәбият


*Валеев Ф.Х.* Татарский народный орнамент. Казань-Чебоксары: РГУП «Чебоксарская типография № 1», 2002. 296 с.

*Веймарн Б.В.* Классическое искусство стран ислама. М.: Искусство, 2002. 496 с.

*Воробьёв Н.И.* Казанские татары [этнографическое исследование материальной культуры дооктябрьского периода]. Казань: Татгосиздат, 1953. 383 с.

*Даркевич В.П.* Светское искусство Византии. Произведения византийского художественного ремесла в Восточной Европе X–XII веков. М.: Искусство, 1975. 352 с.

*Даркевич В.П.* Художественный металл Востока VIII–XIII вв. Произведения восточной торевтики на территории европейской части СССР и Зауралья. М.: Либроком, 2010. 186 с.

*Денике Б.* Архитектурный орнамент Средней Азии. М.; Л.: Изд-во Всесоюзной Академии архитектуры, 1939. 228 с.

*Донина Л.Н.* Отражение мусульманской идентичности татар в ювелирном искусстве: на примере каллиграфического орнамента на чеканных бляхах // Историческая этнология. 2017. Т. 2. № 1. С. 64–79.

*Донина Л.Н., Суслова С.В.* Технико-технологические особенности казанско-татарской филиграни: этно-археологическое исследование // Поволжская археология. 2017. № 4 [22]. С. 222–236.

*Калинин Н.Ф.* Болгарское искусство в металле. Казань, 1946.

Коран / Перевод смыслов и комментарии Валерии Пороховой. М.: Аль-Фуркан, 1997. 800 с.

*Король Г.Г.* Искусство средневековых кочевников Евразии. Очерки. М.; Кемерово: Кузбасвузиздат, 2008. 332 с.

*Маргулан А.Х.* Казахское народное прикладное искусства. Т. 3. Алматы: Өнер, 1994. 248 с.

*Постникова-Лосева М.М.* Русская золотая и серебряная скань. М.: Искусство, 1981. 288 с.

Путешествие Ибн Фадлана: волжский путь от Багдада до Булгара. Каталог выставки. Гос. Эрмитаж. М.: Изд. дом Марджани, 2016. 560 с.

*Ремпель Л.И.* Искусство Среднего Востока. Избранные труды по истории и теории искусств. М.: Советский художник, 1978. 288 с.

*Саблуков Г.С.* Сведения о Коране, законоположительной книге мухаммеданского вероучения. Казань: Комиссия миссионерского противомусульманского сборника при Казанской духовной академии, 1884.

Сокровища Золотой Орды. Каталог выставки. СПб., 2000. 346 с.

*Стародуб Т.Х.* Исламский мир. Художественная культура VI–XVII веков: архитектура, изображение, орнамент, каллиграфия. М.: Восточная литература, 2010. 225 с.

*Сычёва Н.С.* Ювелирные украшения народов Средней Азии и Казахстана XIX–XX веков. Из собрания Государственного музея искусства народов Востока. М.: Советский художник, 1983. 180 с.

*Усманов М.А.* Золотая Орда: истоки и наследие // Сокровища Золотой Орды. Каталог выставки. СПб., 2000. С. 26–53.

*Фёдоров-Давыдов Г.А.* Искусство кочевников и Золотой Орды. Очерки культуры и искусства народов Евразийских степей и золотоордынских городов. М.: Искусство, 1976. 228 с.

*Фонякова [Чувило] Н.А.* Прикладное искусство Хазарии второй половины VIII – начала X вв. по материалам художественной металлообработки. Казань: Институт истории АН РТ, 2010. 168 с.

*Халиков А.Х.* Происхождение татар Поволжья и Приуралья. Казань: Татар. кн. изд-во, 1978. 160 с.

*Черемисин Д.В.* К ирано-тюркским связям в области мифологии: Богиня Умай и мифическая птица // Народы Сибири: история и культура. Новосибирск, 1997.

*Шамсутов Р.И.* Слово и образ в татарском шамаиле от прошлого до настоящего. Казань: Татар. кн. изд-во, 2003. 200 с.

*Шитова С.Н.* Башкирская народная одежда. Уфа: Китап, 1995. 240 с.

*Шукуров Ш.М.* Искусство и тайна. М.: Алетейа, 1999. 247 с.

***Донина Лариса Николаевна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының этнологик тикшеренүләр бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 745

***Ф.Т. Арсланова***

# ИЛАҺИ МОҢ ИЯСЕ

Заслуженная артистка Российской Федерации, народная артистка Республики Башкортостан и Татарстан, обладатель неповторимого голоса, эмоциональной и проникновенной манеры исполнения, Фарида Ягудовна Кудашева пользовалась огромной популярностью и искренней любовью тысяч слушателей. Ее многолетняя творческая деятельность заслужила народное признание, она стала поистине народной певицей. Концертный репертуар Ф. Кудашевой включал сотни эстрадных, башкирских и татарских народных песен. Исполнительница внесла огромный вклад в развитие татаро-башкирского вокального искусства.

**Ключевые слова:** Ф. Кудашева, вокальное искусство, народная песня, репертуар, татарская эстрада.

*«Бөеклекнең тылсым серләре дә*
*Шушы дәртле нәфис җырдадыр».*
*Якуб Колмый*

Уфа «Китап» нәшриятында татар һәм башкорт халкының халык артисты Фәридә Кудашеваның 85 еллык юбилее уңаеннан тирән эчтәлекле һәм матур бизәлешле альбом дөнья күрде. Шулай ук Рәфкат Кантюковның матди ярдәме һәм Роберт Миңнуллин тырышлыгы белән Фәридә Кудашеваның аудио язмалары тупланган биш компакт-диск та әзерләнде. Үткән ел Татарстан китап нәшриятында Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Фәридә Кудашевага багышланган күләмле вә бик тә эчтәлекле китап (төзүчесе Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин) басылып чыкты. Анда бөек җырчының тормышы һәм иҗаты турында мәкаләләр, истәлекләр, әңгәмәләр, хатлар, шигырьләр кертелгән, фотосурәтләр урын алган.

Бик күп язучылар, шагыйрьләр, галимнәр, сәнгать белгечләре, журналистлар, музыка белгечләре үз мәкаләләрендә җырчының башкару осталыгына сокланып, «Ф. Кудашева моңы»ның серен эзлиләр һәм һәрберсе бу сорауны үзләренчә аңлатуга ирешә. Минем үземне дә бала чактан ук Фәридә апа Кудашеваның сихерле моңы озата килде. Аның җырлавын пластинкаларда һәм, соңрак, радиодан тыңлап, үзем дә сәнгать дөньясына кереп киттем. Җырлау – Фәридә апаның яшәү рәвеше булып, аның иң беренче остазы да ҖЫР булган дип әйтер идем... Халык җыры – ул үзе бер консерватория һәм иң көчле остаз!

Фольклорчы, музыка белгече **Мәхмүт Нигъмәтҗанов** болай дип яза: «Фәридә Кудашеваның башкару сәнгате, әлбәттә, башка җырчылар өчен үзенә бер

эталон. Репертуарга таләпчәнлеге дә үзенә генә хас, үзенә генә лаек кабатланмас осталык, стиль, үз йөзе. Милләтебезнең милли моңнарын саклап килүче сәнгать белгечләренә өйрәнер өчен бетмәс-төкәнмәс чыганак».

Татарстанның халык артисты **Рафаэль Ильясов**: «Ф. Кудашеваның җырлавы, аның ягымлы, йөрәкләрне иркәли торган моңлы тавышы һәркемнең – өлкәннәрнең дә, яшьләрнең дә – күңел түрендә, бәгырендә. Халкыбыз көйләрен, композиторларыбыз җырларын үзенә генә хас халыкчан моң белән җырлап, ул һичкемне кабатламый торган мәшһүр башкару остасы булып, бөтен мөселман дөньясына танылды, – ди. Аның йөзләгән җырлардан торган репертуарында халкыбызның Г. Тукай шигырьләренә җырлана торган борынгы озын көйләре «Әллүки», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», тылсымлы моң булып, һәркемнең күңелендә илаһи хисләр уята. Ә «Туган тел» Фәридә Кудашева башкаруында милләтебезнең гасырлардан килгән кайгы-шатлыкларын, өмет-хыялларын чагылдыручы мәңге үлмәс җыр булып яңгырый. Фәридә апаны мин безнең газиз ана телебез сагында торучы фидакяр, көрәшче җырчыбыз дип бәялим», – дип яза.

Фәридә Кудашева кешенең эчке халәтен, кайгы-хәсрәтен, шатлыгын классик югарылыктагы башкаруы һәм моңы белән гәүдәләндерде. Ул тарихка моң чишмәсе булып теркәләчәк. Моңлы кеше – гамьле кеше дибез. Аның моңы – тәрбияче дә, шифалы табиб та, психолог та, якты нур да. Композитор Җ. Фәйзи юкка гына: «Моң ул – күңелгә тәэсир көче зур булган, тирән тойгылар уятучы матур авазларның аһәңдәшлеге», – димәгән. Моңның үзенә буйсындыра алырдай көче бар. Борынгы грек мифларында урын алган Орфейнең моңы нинди тылсымлы көчкә ия булса, Ф. Кудашева моңын да шуңа тиңли алабыз.

Моң ул – серле дә, илаһи да. Моң ул магнит сыман, тыңлаучыны үзенә тарта, буйсындыра, җырлаучы һәм тыңлаучы бер дулкында тибрәлеп, бербөтенгә әверелә.

Фәридә Кудашева моңында күкләрдән иңгән гаҗәеп тирән сер дә бар, диләр җырчы таланты турында журналистлар **В. Гыймазова** белән **Р. Идрисов.** Алар аны табигать могҗизасы, феномен, мәшһүр җырчы, хатын-кыз, ана, сәнгать музасы дип атыйлар. Ф. Кудашева – халкы, заманы, нәселе тудырган бербөтен шәхес. Таланты өстенә табигать аңа шул бербөтенлекне тәэмин итәрлек сыйфатлар да биргән: акылзиһен, намус, саф күңел, рухи ныклык, үз-үзеңә хөрмәт һәм тугрылык, яманнан һәм ялганнан ерак тору... Олы сәнгать юлында Фәридә апа хезмәтне үзәккә куйган, намусны сайлаган, сафлыкны үз иткән. Зур талант ияләренә ниндидер билгесез көчләр яшәргә, яратырга, игелекле гамәлләр кылырга омтылыш уята.

«Моң» төшенчәсен Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты **Идрис Газиев** менә ничек аңлата: «Моң термины татар музыкасы фольклорында халык көйләрен милли

башкаруны характерлауга карый. Эстетик категория буларак, ул күп мәгънәне аңлата һәм сагыш, көйлелекне, җырчанлыкны күздә тота. Татар халык җырларын башкаруның милли үзенчәлекләрен караганда, «моң» термины халык үзләштергән орнаменталь бизәкләрне (бигрәк тә озын көйләрдә) табигый сәнгати нечкәлек, тирән хисләр аша башкару белән бәйләнә, бу аларга эчкерсезлек, моң белән өретелгән җылылык хисләре өсти...»

«Иланы моң иясе» дип язып куйдым да, уйга калдым. Һәр җырчының үз моңы, әмма Раббыбыз моңлы тавышны теләгән кешесенә мул итеп бирә. Фәридә Кудашева Аллаһы Тәгалә бүләк иткән искиткеч матур тавышка ия иДе. Пәйгамбәрләр тарихыннан бер мисал китерәсем килә: Даут пәйгамбәргә Аллаһы Тәгалә могҗизадай искиткеч гүзәл тавыш биргән. Даут пәйгамбәр үзенә иңдерелгән китапны укыганда кошлар очуыннан туктап калган, сулар – агышыннан, җилләр исүдән туктаган, ... бөтен дөнья таң калып аны тыңлаган, аңа кушылып бар дөньяның хуҗасы бер Аллаһны зикер кылган. Фәридә апаның моңы да бәлки пәйгамбәр Даут токымыннан. Ф. Кудашева, зур хезмәте, тырышлыгы белән үзенә бирелгән олуг бүләкне яраткан газиз халкы белән бүлешә... Аллаһы Тәгалә аңа сынауларны да мул яудыра, ләкин ул бирешми, үз язмышына тугры калып, гомере буе туган җиренә, халкына хезмәт итә. Җырчы, халык мәхәббәтенең кадерен белеп, аның уй-хисләре белән яшәп, җырларында шул тойгыларны гәүдәләндерә. Халкыбызның гасырлардан килгән фаҗигале язмышы аның җырларында «татар моңы» булып яңгырый. «Дүртөйле» җырында юкка гына: «Кайгы-хәсрәт бетсә дә, моңнары кала икән...» дип җырламый ул.

Аллаһы Тәгалә аңа табигый сәләт өстенә зиһен дә биргән. Репертуары бай булу – 3 меңләп җырның сүз-көйләрен истә калдыру – мөкаммәл ишетү сәләте, зиһен-зирәклек түгелме? Җырчыны – җыр, җырны – җырчы күтәрә, дибез. Репертуарының эчтәлеген матурлык һәм моңнан яратылган шагыйрьләр Г. Тукай, Х. Туфан, С. Кудаш, Ә. Атнабаев, Ш. Биккол, М. Кәрим, Н. Исәнбәт, Г. Зәйнәшева һ.б.ның сүзләренә композиторлар З. Исмәгыйлев, Х. Әхмәтов, С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, С. Садыйкова, М. Макаров, Р. Мортазин, Ф. Әхмәдиев, Б. Гайсин һ.б. иҗат иткән җырлар тәшкил итә. Ул җырларда шагыйрьнең, көйче һәм җырчының сагышлары гомумкешелек сагышлары белән кушыла.

«Халыкны ике нәрсә яшәтә: дин һәм моң», – ди, халкыбызның горурлыгы булган җырчыбыз **Илһам Шакиров**. Фәридә ханым үзе белән бер әңгәмәсендә: «Авылда бездән ерак түгел мәчет бар иде. Манарадан азан әйткән тавыш миңа ниндидер бер илаһи, сихри моң булып ишетелә иде. Шуңа карата күңелемә бер җыр сеңеп калган: *Иртә тордым, иртә, дип, намаз вакыты җитә, дип; Азан әйтә, мин җылыймын, башым читкә китә, дип*. Бөек **Тукаебызның**

моң турында мондый юллары бар: «Кичке азан! Кичке азан! Моңнар, уйлар кила аннан...»; «Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан» («Кичке азан»).

Фәридәнең җырлау осталыгы белән моң төшенчәсен аерып карап булмый. Һәр кешенең тавышы, беренче чиратта, үзенә генә хас **тембр** яки тавышның бизәге (матурлыгы) белән аерыла. Аһәңле, моңлы, көмештәй чыңлый, металл сыман яңгырый – яхшы тембр шулай характерлана. Ф. Кудашева кабатланмас, үзенә генә хас төсе-бизәге булган, яңгырашы буенча ягымлы, җылы, якты моңлы уникаль тавыш тембрына ия иде. Мондый тембрлы тавыш үзгәртүгә, төзәтүгә бирелми. Ясалма юл белән тавышны көчлерәк, сулышны киңрәк итәргә була, әмма тембрны моңлырак итеп үзгәртеп булмый. Фәридә ханым гомере буенча үзенә бирелгән табигый тавыш тембрын бозмыйча, саклап кына эш итте.

Вокаль осталыкның иң мөһим күрсәткече – дөрес **сулыш алу**, җырлау тынын үзләштерү, аңа ия булу. Ф. Кудашеваның тын алу осталыгы аңа табигатьтән бирелгән дип әйтеп булмый. Ул аңа зур тырышлык, күнегүләр, күпьеллык тәҗрибә аркылы ирешкәндер диярга кирәк. Фәридә ханымның сизелер-сизелмәс кенә алган тыны озын көйләрдә 4 юллы куплетның бер юлына тулысынча җитә, ә кыска көйләрдә бер куплетка җиткәннәре дә бар. Татар һәм башкорт озын көйләренең язмаларында сүз уртасында тын алганын очратмассың. Ул, тыныч һәм сиздермичә генә тын алып, нәзакәтле, җиңел тавыш чыгара. Җырчының сәхнәдә үзен иркен, гади итеп тотышы да тамашачыны гел үзенә җәлеп итеп, аның белән бәйләнешне өзми. Табигыйлек, гадилек, эчкерсезлек... Мондый иҗатның сере нидә соң? Бербөтен гармоник камиллектә, дияр идем. Югары интеллектлы иҗатчы бөтен яклап та гармоник камиллеккә омтыла. Шушы гармонияне без Фәридә ханымның иҗатында да, тормышында да тоеп килдек.

Ф. Кудашева, халыкча җырлау остасы буларак, сулыш алуда күбрәк күкрәк ысулын куллана, шуның белән бергә аның тавышы **обертоннарга** бай. Тавыш тембры обертоннар белән генә түгел, **вибрато** (тавыш җепселләренең җиңелчә тирбәлүе) белән дә билгеләнә. Вибрато – тавышның очучанлыгын – ераккарак ишетелү сәләтен арттырып, җанландыра. Резонаторлар дөрес эшләгәнгә, көчле булмаган тавыш та тамашачы залының иң соңгы рәтләренә хәтле табигый тембрда ишетелә. Табигать тудырган, бәллүрдәй саф, яңгыравыклы, «оча торган» тавышка ия иде Фәридә ханым.

Җырлау рәвешендә халыкча башкару алымнары бик ачык ишетелә. Җанга ятышлы йомшак тембр, сәйләндәй ачык дикция, көйнең тулып аккан елгадай тигез генә агышы, күкрәк түреннән чыккан аһәң – халык җырларының бөтен гүзәллеген тамашачыга җиткерергә ярдәм итә.

Җыр-көй һәм аны башкару – һәр милләт өчен үзенчәлекле күренеш, татарларның җырлау рәвешендә үзенә генә хас йола-

лар, ияләшкән алымнар, манералар бар, ди әдибебез **Нәкый Исәнбәт.** Җырчының осталыгы озын көйләрне җырлый белүендә сынала. Чыннан да безнең халыкка Фәридәнекедәй көчәнүсез, йомшак, тигез яңгырашлы моң хас. Тукайның җырлау рәвешебез турындагы: «Безнең бер көйне татар булмаган бер кешедән җырлатсаң, көемезнең алтынын кояр шикелле тоела... Халык җырлары үзенең мөһмәлияте вә җитешсезлекләре белән бергә, әлбәттә, үземезгә генә сөекле булырга тиеш һәм сөекле дә...» дигән фикере бүгенге көндә дә актуаль.

Ф. Кудашева – халык көйләре җырчысы. Халык көйләрен ул балачактан ук тыңлап, үзенә сеңдереп үскән. Башкортстанның гүзәл табигатендә Урал таулары итәкләре, Дим буйларындагы камышлар, суга башлары иелгән бөдрә таллары белән «серләшеп», башкорт җырчыларын тыңлап үсә Фәридә апа. Морзалар нәселеннән булган музыкаль гаилә мохитендә үсү дә моңа сәбәпче булгандыр.

Ф. Кудашеваның киң диапазонлы, озын сулыш таләп итә торган җырларны югары кимәлдә башкаруы сокландыра һәм аңа ул үзенең иҗади тырышлыгы белән ирешә. Чөнки табигать биргән тавышны оста файдалана белү дә кирәк. Чөнки озын көйләрдә һәр җырның образын ачып бирү мөһим. Җыр сүзләренә дә саклык белән мөрәҗәгать итә Фәридә апа. Озын көйләрне башкарганда артык мелизмнар-бизәкләр белән мавыкмый – халык көйләренең үзенчәлеген тирәннән аңлап, төгәл һәм гади итеп башкара.

Фәридә ханым, башлыча, лирик җырларны үз итә дисәк дөрес булыр, әмма ул аларны төшенке рухта түгел, ә бәлки оптимистик төсмерләрдә бирергә омтыла. Һәр җыры аның үзенчә, беркемне дә кабатламый, һәр җыры – үзенә күрә бер мини-спектакль.

Ф. Кудашева халык җырының классик традицияләрен дәвам итеп, бер үк вакытта концерт эстрадасының башкару сәнгатенә оргиналь яңалыклар да алып керде һәм ул алымнарны уңышлы файдаланды. Чама хисен һич тә онытмады ул, хәрәкәтләре бик табигый, сәхнә культурасы югары, затлы булды.

Милли җыр сәнгатебез йолдызы Фәридә Кудашеваның җырлау культурасы, репертуар байлыгы күп җырчылар өчен үрнәк булырлык, бәрхет тембрлы тавышы, авазларның ачыклыгы, сөйләмнең төгәллеге дә осталык эталоны булып тора. Ф. Кудашева җырның кульминация урынnarында да тавыш көчен чамасыз арттырмыйча, матур тембрын саклап җырлый. Бу бигрәк тә озын һәм салмак җырларда ачык чагыла. Кайбер җырчылар кебек соңгы куплетның ахыргы юлларын 2–3 тапкыр кабатламый, җырларның азагын югары ноталарга менеп тәмамламый. Җырда көйне һәм текстның образын саклый.

Җырчы **колоратур бизәкләрне** дә үзенчә – Фәридәчә ала. Сузык һәм тартык авазларның тигез бәйләнеп, бер-берсенә үрелеп баруы табигый легато барлыкка китерә. Фәридә ханым **глиссандо** алымын да урынлы куллана, аның моңлы авазы ясалма эффектлар кулланмыйча

да тыңлаучыны елатырга мөмкин. Җырчы кирәк-кирәкмәгән урында «ай-һай»ламый. «Шофер җыры»нда, «Яннарыңа барыр идем»дә – ул андый урыннарны саклык белән, серле итеп, «ух»ылдамый гына башкара.

Ф. Кудашева баян, курай, аккордеонга кушылып җырлый, тавышы белән аларның тембрына тоташа. «Дим буе» җырында камыштан ясалган курай тавышы, «Ашказар»да су агышыдай башкорт курае белән кушыла. «Туган тел»нең соңгы юлында синтезатор һәм фортепиано аккомпанементы белән җырчы тавышы галәми аһәңгә әверелеп күккә тоташа сыман...

Аңа хас булган халыкча башкару алымнарының берсе – тартык авазлар янына сузык авазларны өстәп яки кыскартып җырлау. Мәсәлән: бизәкле лә; д(ы)ранча ла; табал(ы)мадым; гом(е)рем; килә(й); уйный шул...; Әри бу(й) на кил...

Аның башкаруында ярдәмче тавышлар, яңгыраш паузалары куллану, кайбер сүзләрне үзе туып үскән җирлек диалектында әйтү (ал булмай, булмай...), «и» һәм кайбер авазларны «ачыграк» һәм «йомыбрак», кайбер урыннарда борын авазы җибәрү..., ягъни, яңгырашка хилафлык китермичә, тавышны үзенчәлекле тембраль буяуларга баету хас. Аһәңне чама белән **филировкалау** да аңа ят түгел. Мондый алымнар җырлауны бизи, аны җанландыра, динамик палитрасын баета, тавышның тәэсир көчен арттыра. Җырларда, бигрәк тә композиторлар әсәрләрендә, ул **вокализлар** кертеп җибәрә, бу алым лирик әсәрне драматик яңгырашка якынайта.

Бик күп халык җырларына ул халыкта элек-электән традицион яңгырашлы булган үзәкне өзәрдәй сүзләр кушып җырлый (мәсәлән: «Кара урман аша», «Аккош» һ.б.).

Фәридә Кудашева да, Зифа Басыйрова, Әлфия Авзалова, Абдулла Солтановлар кебек үк, консерваториядә яки музыка уку йортында белем алмаган. Әмма ул – кабатланмас моңы белән (Фәридә исеме гарәпчәдән бердәнбер, кабатланмас дигәнне аңлата) үзе бер вокаль мәктәп булдырган җырчы. Ф. Кудашева бер әңгәмәсендә: «Мин музыка белемем булмаса да, халыкча җырлауга укыта алыр идем», дигән иде.

Фәриданең җырлау осталыгын баетуда, аңа яңа төсмерләр кертүгә хәләл җефете – оста музыкант, композитор, башкаручы солист, яхшы аккомпаниатор Бәхти Гайсин сәнгате зур роль уйный. Ул Фәридәсе җырлаганда аның тын алышына, авызын ачуына, күз карашына тиклем тоя торган була. Талантлы музыкантның аккордеонда уйнавын беркемнеке белән дә чагыштырып булмый. Аның башкаруында башкорт, татар халык иҗатының борынгы үрнәкләренә нигезләнгән көйләрне тыңлап туймаслык. Бәхти Гайсинның һәр әсәре халыкчан һәм заманча яңгырый.

Ф. Кудашева репертуарына Б. Гайсин тарафыннан яңадан-яңа интонацияләр, ритмик бизәкләр белән баетылган, заманча аранжировкалардан төзелгән җырлар өстәлә тора һәм алар

жырчы иҗатына яңа юнәлеш бирә. Б. Гайсин ансамбле белән Ф. Кудашева башкарган җырлар дискын тыңлагач, музыкантның синтезаторны моң дигән сихри хәзинәгә буйсындырып уйнавына сокланмый мөмкин түгел. Җыр һәм синтезатор яки ионика аһәңнәре сине сихри галәм дөньясына алып китә... «Ике аккош», «Кайтырсың шикелле», «Кермә төшкә», «Су буйлап»... шундыйлардан. Ә инде «Йөрәк сере»ндә (С. Садыйкова, И. Ганиева) Ф. Кудашева йөрәгенең серен – дәрья суыдай ташып аккан сүнмәс рухлы йөрәк авазын җыр аһәңенә – моңга төрә.

Бәхти Гайсин – виртуоз аккордеончы. Башкорт халык көе «Зөлхиҗә»не беркемнең дә аның кебек оста уйнаганы булмады, дип яза Р. Гайнетдинов.

Ф. Кудашева иҗатының башлангыч чорында композитор, баянчы Таһир Кәримов белән хезмәттәшлек итә. Ул шулай ук баянчылар Әлфәрит Солтанов, Рәис Сафиуллин, курайда Азат Аетколов, Бәхти Гайсин җитәкчелегендәге инструменталь ансамбль, фортепианода Александр Ключарев, Радик Хәбибуллин, Рөстәм Яхин аккомпанементлыкларында да җырлады. Ул аларның һәркайсы белән бердәй гармоник дуэт тудыра алды.

Фәридә Яһүд кызы татар җыр сәнгатенең бүгенгесе һәм үткәне турында гаҗәп дәрәҗәдә хәбәрдар була. Бик күп халык көйләренең бүгенге көннәргә кадәр яшәве өчен дә без Фәридә Яһүд кызына бурычлыбыз.

Ф. Кудашеваның табигатьтән куелган тавышын итальян мәктәбенә хас белькантога тиңләп була. Вокаль башкару стиле бельканто – озын көй башкару техникасының төп таләпләренә туры килеп, җырлауның сыгылмалылыгын, талгынлыгын, хәрәкәтчәнлеген, виртуоз алымнарга сәләтлелеген, бертуктаусыз агучы тигез тавышны аңлата. Ә Фәридә ханымның җырлавы – нәкъ әлеге санап киткән төшенчәләргә туры килә дә инде!

Ф. Кудашева репертуарын саклау, аның кабатланмас тавышы белән таныштыру ниятеннән, аның язмаларын радиотелевидениедән ешрак яңгыратасы иде.

Фәридә Кудашева – бүгенге көнге җырчылар өчен бәяләп бетермәслек энциклопедик җырчы – аның моңлы музыкаль мирасын тыңлау, татар-башкорт җыр сәнгатен тирәнтен өйрәнергә, «моң» төшенчәсен киңрәк аңларга, музыкаль фразаларны дөрес төзергә, тын алу культурасына, татар-башкорт мелизмнарын бер-берсеннән аерып, аларны чама белән генә кулланырга, халык җырларын «чүптән» арындырырга ярдәм итәр иде.

***Арсланова Филүсә Тимергали кызы,***
*музыка белгече, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

УДК 792. 9

***А.Р. Салихова***

# «ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ БҮГЕНГЕ ЭТАПТА

В статье рассматриваются спектакли татарского государственного театра кукол «Экият». Раскрываются особенности детского театра, анализируются режиссерские решения. Уделяется внимание актерским работам и музыкальному оформлению.

**Ключевые слова:** театр кукол, спектакль, детская аудитория, репертуар, детский театр, режиссерское решение.

Казандагы мәдәни учреждениеләр арасында «Әкият» татар дәүләт курчак театры үзенчәлекле урын били. Әле яшь, самими, саф күңелле, һәрнәрсәгә ышанучан тамашачының театр сәнгате дөньясына беренче адымнары нәкъ менә шуннан башлана. Башкалабыздагы бүгенге курчак театры гаҗәеп зиннәтле һәм шәһәрнең иң истәлекле урыны саналырлык, шул ук вакытта балаларны үзләрен тылсымлы дөньяда хис иттерердәй бинага урнашкан.

Тик шуны онытырга ярамый, һәр әкиятнең сюжеты чынбарлык нигезенә корылган, ә андагы могҗизалар – әсәр авторларының, сәхнә осталарының иҗади, тынгысыз һәм тырыш хезмәте нәтиҗәсе. «Әкият» курчак театры, барыннан да бигрәк, иҗади коллектив, аның алдында шактый катлаулы иҗади бурычлар тора. Дөрес, һәр театр заман белән атларга, репертуар, режиссура мәсьәләләрен заманча хәл итәргә, яңа алымнар эзләргә тиеш. Ә балалар театрларының, шуларга өстәп, үзләренә генә хас күп төрле мәшәкатьләре дә җитәрлек.

«Әкият» курчак театрында иҗади тормыш гөрләп тора. Зур вакыйгалар дип түбәндәге чараларны билгеләп үтәргә мөмкин: II «Шомбай-фест» курчак театрлары Халыкара фестивале (2016 ел, 26–30 сентябрь), Көньяк Сахалин курчак театры (2017 ел, 4–16 апрель) һәм Тольятти курчак театры (1917 ел, 12–13 май) гастрольләре, Казанда төрки халыкларның XIII «Нәүруз» халыкара театр фестивалендә, шулай ук яшьләр һәм өлкәннәр өчен Оренбургта уздырылган IX «Гостиный двор» курчак театры Халыкара фестивальләрендәге уңышлы чыгышлар. Болар өстенә юбилей тантаналары, премьералар уздыру, дәрәҗәле бүләкләр һәм дипломнарга ия булучыларны котлаулар...

Театрның, тамашачыга тәкъдим ителгән чараларыннан тыш, эчке тормышында да максатлар да күп. Яңа буын иҗади шәхесләр формалаштыру театрның уңышлы киләчәгенә нигез сала, коллектив эшчәнлеген кызыклы итә һәм җанландырып җибәрә.

«Әкият» тарихи вакыйгаларга һәм традицияләргә бай театр.

Биредә инде ничә буын тамашачы башта әти-әниләре, аннан үз балалары һәм оныклары белән булган. Эстетик һәм иҗади программаларның нигезе совет чорында ук формалашкан. Алар хәзер дә үз көчендә. Театрның тәрбияви роленә аеруча зур игътибар бирелә. Людмила Дьяченко һәм Илдус Зиннуров кебек өлкән буын режиссерлар сәхнәләштерелгән постановкаларда балачакка сизгер һәм ягымлы караш, нәниләргә мәхәббәт һәм алар алдында җаваплылык тою хисе көчле. Аларның постановкалары балалар психологиясе үзенчәлекләрен истә тотып сәхнәләштерелә. Әхлакый кыйммәткә ия спектакльләр менә ничә еллар инде сәхнәдән төшми. «Гуси-лебеди», «Муха-цокотуха», «Цветик-семицветик», «Приключения чебурашки» һәм башка әкияти тамашалар балалар театрына хас стильдә сәхнәләштерелгән. Алар төсләргә, хәрәкәтләргә бай, балаларны гаделлеккә, игелеклелеккә, дуслыкка өнди. Казан курчак театрында формалашкан актерлык мәктәбе, курчакларны хәрәкәтләндерүдән тыш, драматик сәнгать үзенчәлекләре, хореографик күнекмәләр, вокал һәм пластика буенча да нигезле белем бирә. Курчак театрының күпьеллык традицияләре яңа тенденцияләр бөреләнүгә хезмәт итүче нигез, база булып тора.

Бүгенге балалар театры юнәлешләренең берсе – тамашачылар аудиториясен киңәйтү, ягъни репертуар исемлеген бер яшьлек балалардан башлап әзерләнгән тамашалар хисабына арттыру. «Әкият» курчак театры «Мендәрле театр» («Театр на подушках») проекты кысаларында тәҗрибә өчен бер-бер артлы ике спектакль (М. Протасова «Идет коза рогатая» һәм П. Геннадьева «Не хочу и не буду») тәкъдим итте. Болар, театр бинасында гына түгел, теләсә кайсы киңлектә куела ала торган җыйнак постановкалар. Әле игътибарларын текстка туплый белмәгән нәниләр, сюжет нигезендә, уен процессына кушылып, кулларын чәбәкләп, тибенеп, җырга кушылып сәхнәдәге геройларга ярдәм итәләр. Мондый тамашачы белән элемтә урнаштыру өчен башкаручының еллар дәвамында формалашкан һөнәри күнекмәләре генә җитми, ә нәниләргә җайлаша белү, импровизация осталыгы, психологик тоемлау сәләтенә ия булу да кирәк. Әйтеп үткән әсәрләрне театрның актерлары Эльвира Гыйлемханова («Идет коза рогатая») белән Айвар Гыймаев («Не хочу и не буду») сәхнәләштерде. Тавык чебиләре турындагы катлаулы булмаган күренешләр балалар яратып карарлык итеп бирелгән. Бу постановкаларны театр сәнгате белән педагогиканың үзенчәлекле синтезы дияргә була. Нәни тамашачыларга күңел ачу күренешләре генә түгел, ә сөйләм телен, фикерләү дәрәҗәсен, игътибарларын үстерү күнегүләре дә тәкъдим ителә. «Идет коза рогатая» спектаклендә фольклор материаллары күп кулланыла (бу бигрәк тә рәссам С. Рябинин тарафыннан эшләнгән киемнәрдә һәм сәхнә бизәлешендә дә чагыла). С. Маршакның режиссер Рафаэль Таһиров тарафыннан сәхнәләштерелгән «Теремок» әкияте

халыкчан стильдә куелган. Аның премьерасы 2017 елның 21 апрелендә узды. Спектакльнең үзенчәлеге шунда – ул балалар өчен генә түгел, зурлар өчен дә кызыклы. Тамашачыга, кечкенәдән таныш җанварлардан тыш, чынбарлыкны фантазия һәм осталык ярдәмендә җанландырып сурәтләүче «театрда театр» тәкъдим ителә. Постановканың гадәти булмаган сәнгатьчә бизәлеше (Мурманскидан махсус чакырып китерелгән С. Шахновская эше) аерым мактауга лаек. Азат Хөсәеновның музыкасы дәртлелеге белән күңелләрне хисләндерә. Ә иң мөһиме – режиссерның оригиналь чишелешләре, актерлардан Наталья Егорова, Сергей Кузнецов, Татьяна Сорокинаның онытылып уйнаулары, ягъни һәр күренешне, көлдергеч җырчы-музыкант ролен, курчаклар хәрәкәтен чынбарлыктагыча гәүдәләндерүләре, шул ук вакытта халкыбызның күп төрле музыка коралларында оста итеп уйнаулары һәр бала күңеленә үтеп керерлек. Гомумән, спектакль бик җанлы, күңелле, мавыктыргыч һәм көтелмәгән чишелешләргә бай. Дидактизм ачыктан-ачык өстенлек итмәсә дә, тамашаның тәрбияви роле бик зур. Ул тамашачыда тормышка уңай мөнәсәбәтне активлаштыра, балаларда күзәтүчәнлек, тапкырлык кебек сыйфатланы үстерә һәм иҗат итүгә омтылыш уята.

Мәгънәсе һәм сәхнәләштерү ягыннан катлаулы һәм күппланлы «Хаврошечка» (Л. Савчук пьесасы буенча) спектаклен театрның зур казанышы дияргә кирәк. (Премьерасы 2017 елның 27 май аенда булды.) Әсәрне сәхнәгә кую өчен Красноярск курчак театрының баш режиссеры, РФ театр эшлеклеләренең «Алтын битлек» («Золотая маска») премиясе номинанты Светлана Дорожко чакырып китерелде. Инде танылып өлгергән, талантлы, тәҗрибәле һәм таләпчән режиссер трагифарс жанрындагы спектакльне тиз арада «Әкият» курчак театры репертуарында аерылып торырлык дәрәҗәдә сәхнәләштерә алды. Әсәрдәге Тетка ролен уйнаган Илсур Минкәев якты, киң масштаблы образ тудырды. Тормышта күңелгә ятышлы яшь кенә егет тамашачы күз алдында хәрәкәтчән карчыкка әйләнде. Актер, шамакайларча киенгән булса да, тамашачыда җитди ассоциация тудыра. Төп геройны Әлфия Рамазанова гәүдәләндерә. Аның Хаврошечкасы изге ниятле, ихлас күңелле, сабыр, үз хисләренә хуҗа була белүче образ. Евгения Кладова (Одноглазка), Гүзәл Гаязетдинова (Двуглазка), Дилүс Хуҗәхмәтов (Трехглазка) та үз персонажларын бөтен нечкәлекләре, психологик үзенчәлекләре белән бирә белделәр. Алар үзләре явыз да түгел, әмма аларның битарафлыгы, дуамаллыгы, үз-үзләре турында гына кайгыртып яшәве Хаврошечкага зур кыенлыклар китерә.

Спектакльдә җанның күчүе кебек мистик күренешләр дә бар. Ул бер-берсенә охшаш ике рольне (Корова белән Хаврошечканың әнисен) уйнаучы актриса Гүзәл Гаязетдинова гамәлләрендә ачык чагыла. Бу юнәлеш постановкага фәлсәфилек мәгънәсе

өсти, шулай ук әсәрне оригиналь эфектлылы чаралар белән дә баета (Дмитрий Пристай белән Айвар Гыймаевның компьютер анимацияләре).

Спектакльнең музыкаль бизәлешен тәэсирле итүгә зур көч куйган композитор Петр Макаров (Мурманск), вокаль режиссура авторы Гильда Казарцева эшләре, шулай ук рәссам-постановщик Ольга Устюгова (Мәскәү), хореограф Гүзәл Маннанова иҗаты да аерым мактауга лаек.

Күптән түгел татар труппасы тарафыннан әзерләнгән тамашаларның да премьералары булды. «Әкият» курчак театрында туган телебездә яңгыраган, милли шигърият рухы белән сугарылган спектакльләр куелу республика өчен үзе зур горурлык.

Ркаил Зәйдуллинның туган җирне ярату, тугрылык һәм дуслык, игелеклелек һәм гаделлек турындагы «Бүре җиләге» дигән әсәре буенча куелган спектакльнең премьерасы 2016 елның 16 декабрендә булган иде. Аның әле дә сәхнәдән төшкәне юк. Театрның баш режиссеры Илдус Зиннуров сәхнәләштергән бу әсәрдә күтәрелгән мәгънәви акцентлар, әхлакый кыйммәтләр яшь тамашачы аңына үтеп керерлек, хәтергә кереп калырлык итеп бирелгән. Гыйбрәтле күренешләрне чынбарлыктагыча һәм сәнгатьчә гәүдәләндерүдә режиссерга Булат Нәсыйхов һәм Фәридә Мөхәммәтшина кебек рәссамнарның, композитор Мәсхудә Шәмсетдинова, хореограф Гүзәл Маннановаларның да ярдәме зур. Спектакльдә Елгыр ролен башкарган Фәнзилә Сабирова Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Курчак театрының иң яхшы артисты» номинациясендә «Тантана» премиясенә лаек булды.

Курчак театры сәхнәсендә Нәфисә Исмәгыйлеваның «Тамчылар» пьесасы буенча бик тә үзенчәлекле эшләнгән спектакль бара (аның премьерасы 2017 елның 2 июлендә булган иде). Аны чын мәгънәсендә эксперименталь тамаша дияргә була. Пьеса үзе дә гадәти түгел. Су тамчыларының метаморфозасы (бер рәвештән икенчегә әверелеше) турында ул. Әлбәттә, аны бала күңеленә җиткерү өчен сәхнә чишелешенең дә үзенчәлекле булуы зарур. Мөгаен, бу очракта әсәрне сәхнәләштерүне авторның үзенә тапшыру урынлы да булгандыр. Кыскасы, бу эшне Нәфисә Исмәгыйлеваның курчак театрында режиссерлык дебюты дияргә кирәк.

Сәхнәдә туктаусыз үзгәреп торучы фантастик дөнья хасил була (рәссамы Екатерина Спиридонова). Очсыз-кырыйсыз зәңгәр күктә, төрле формаларга кереп, туктаусыз болытлар йөзә… Композитор Юрий Чаплинның музыкасы тамашачы күңелен җирдән галәм киңлегенә, хыялый дөньяга алып китә. Анда исә су тамчылары яши, аларның үз мәшәкатьләре. Тормышка киләчәкне алдан фаразлап булмый, чөнки ул гел үзгәреп тора. Бу очракта нәрсә эшләргә? Куркуны һәм шик-шөбһәләрне ничек җиңәргә? Шатлык яки кызыксынучанлыкны ничек кабул итәргә? Нәфисә Исмәгыйлева нәни тамашачыларга шундый сораулар белән мөрәҗәгать итә. Тамчылар

парга әйләнгәндә дә, кар бөртегенә яки бозга әверелгәндә дә үзләре булып калалар. Алар фәкать үз рольләрен генә беләләр, сынаулар узалар, зур серле дөньяны ачалар. Сәхнәдә көтелмәгән тылсымлы күренешләр пәйда була, актерлар үз геройларын ачык һәм хисчән итеп күрсәтәләр. Рузилә Зарипова белән Марс Гайфуллин образларны аеруча җанлы итеп гәүдәләндерәләр. Аларның «тамчылары» тере, дәртле. Бай фантазиягә корылган бу спектакльне, балалар гына түгел, зурлар да кызыксынып карый.

«Әкият» татар дәүләт курчак театры иҗади эзләнүләр процессында яши һәм бүгенге тамашачы белән җанлы элемтә булдыру өчен яңадан-яңа һәм сәнгатьчән алымнар таба.

**Әдәбият**

*Габаши А.* Есть в Казани театр – сказка // Сэхнэ. 2017. № 8. С. 4–7.

*Хабутдинова М.* «Тамчылар», или Веселые приключения с каплей... // http://kalebtatar.ru/article/3440. – Дата обращения: 3.07.2017.

*Яппарова Р.* Чтобы царила доброта // Элита Татарстана, 2018.

***Салихова Айгөл Рөстәм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты театр һәм музыка бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 792

***Ф.С. Гыйниятуллина***

## ТЕАТР БЕЛГЕЧЕ ҺӘНҮЗ МӘХМҮТОВНЫҢ ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

*(Һәнүз Мәхмүтовның тууына 85 ел)*

Статья посвящена 85-летию Хануза Махмутова и его научной деятельности. Он обладал глубокими знаниями по литературе, искусству, языку, истории, философии. Учёный внес большой вклад в изучение творческого наследия Г. Исхаки и театрального искусства.

**Ключевые слова:** наука, театр, драматургия, энциклопедия, журнал «Мирас».

Татар энциклопедиясенең һәр томында фән, әдәбият, мәдәният өлкәсендәге күренекле шәхесләргә багышланган язмалар да зур урын ала. Шундый шәхесләрнең берсе – әдәбият һәм театр белгече, Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләк иясе Һәнүз Мәхмүтов. Тормышта үз юлын, үз урынын тапкан, күпкырлы эшчәнлеге, фәнни хезмәтләре белән танылган олуг белгеч ул. Фәнгә Һ. Мәхмүтов тормыш мәктәбенең авырлыгын үз җилкәсендә татыганнан соң килеп керә. Һәнүз Мәхмүтов 1933 елның 15 июлендә Башкортстанның Яңавыл районы Таш Елга авылында туа. Дүрт яшьтән әтисез, унике яшеннән әнисез кала. Әмма туганнары, авылдашлары аңа ятимлек ачысын татырга юл куймыйлар. Кечкенәдән үк ул бик тырыш була. Мәктәптән соң биш ел колхозда эшли. Аннан өч ел армиядә хезмәт итә. 1954 елда Оренбургның Тоцк лагеры тирәсендә атом бомбасын сынауның шаһите була. Ул башта курсант, аннан сержант, химик-разведчик булып хезмәт итә. Армия хезмәтеннән соң Таҗикстанга китә. Памир таулары арасында урнашкан Шураб шәһәрендә күмер шахтасында эшли. Эштән соң кичке мәктәптә укып, 10 нчы сыйныфны тәмамлый. Балалык елларында ук шигърият, әдәбият белән мавыгуы, шул юнәлештә югары белем алырга омтылуы аны 25 яшендә Казанга кайтып, Казан дәүләт университетының (хәзер КФУ) тарих-филология факультетына укырга керергә этәрә. Югалткан еллар үзен сиздерсә дә, Һ. Мәхмүтов сынатмый. «Татар драматургиясендә трагедия жанры» дигән хезмәте өчен диплом яклау комиссиясенең югары бәясенә лаек була. 1965 елда әлеге эш университетның гыйльми советы тарафыннан матбугатка тәкъдим ителә һәм басылып чыга. Аннан соң Һәнүз Мәхмүтов профессор Хәмит Госманов тәкъдиме белән Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының Хәмит Ярми бүлегенә аспирантурага укырга керә. 1963 елдан алып, башта фольклор, аннан соң комедия жанрын

өйрәнә, Әстерхан, Минзәлә театрлары тарихын, драматурглар Г. Камал, К. Тинчурин, Ш. Камал, М. Гафури, Һ. Такташ, Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, Ю. Әминов, С. Шәкүровларның һәм артистларның иҗатын тикшерә. Шулай итеп, Һ. Мәхмүтов үзе өчен бөтенләй яңа булган театр фәне дөньясына аяк атлый. Бер үк вакытта ул институтта нәшер ителүче «Фәнни адым» исемле газетада алыштыргысыз сәркатип эшен дә алып бара. Һ. Мәхмүтов, татар театры тарихын өйрәнүче, тикшерүче галим булуы белән бергә, татар мәдәнияте һәм әдәбияты тарихларын да тирәннән белә. Театр фәне, башка фәннәрдән аермалы буларак, үзенчәлекле фән. Мәдәният, театр тарихын өйрәнү дә, театрның әдәбият белән бәйләнешенә, драматургиядәге, сәхнәдәге жанрлар төрлелегенә фәнни якын килү дә Һәнүз Мәхмүтовка хас сыйфат. Ул Октябрь вакыйгаларына кадәрге татар театры тарихын ныклап өйрәнә һәм шул чордагы татар сәхнәсе турында библиографик белешмә төзи. Галимнең иң җитди хезмәтләренең берсе – «Октябрьгә кадәрге татар театры» исемле күләмле китабы. Әлеге китап киң җәмәгатьчелек, бигрәк тә театр әһелләре арасында зур кызыксыну тудыра, сәнгать тарихына үзгәртеп кору алып килгән уңай күренешләрнең җитди бер чагылышы итеп карарга мөмкинлек бирә. Бу монографиягә күренекле галимнәр, язучылар, тәнкыйтьчеләр аеруча игътибар итә. Әйтергә кирәк, Һ. Мәхмүтовың дөнья күргән хезмәтләре моның белән генә чикләнеп калмый. Ул «Татар совет театры», «Татар сәхнәсе. Әдәбият күрсәткече (1917–1964)», «Гөлсем Болгарская», рус телендә «Татарский театр: новаторские искания татарского советского театра», «Галиаскар Камал», «Сцена и время», «Искусство Татарстана: пути становления», «Традиции и новаторство в творчестве Карима Тинчурина» һ.б. китапларны матбугатка әзерләгәндә иң күп көч куйган галим булып санала.

Татар энциклопедиясе – халкыбызның һәм Татарстанның тарихын, мәдәниятен, фәнни казанышларын бергә туплаган олы хезмәт. Менә шушы хезмәтне эшләүдә Һәнүз Мәхмүтовның да өлеше зур. Ул Татар энциклопедиясенә татар театрлары буенча исемлек төзүдә дә актив катнаша. Хәзер исә милли театрларыбыз буенча мәгълүматлар аның әлеге хезмәтенә нигезләнеп бирелә.

90 нчы еллар башында бербер артлы яңа газеталар, журналлар чыга башлый. 1991 елдан инде татар халкы өчен күптән зарыгып көтелгән «Мирас» журналы нәшер ителә. «Мирас» журналының чыга башлавы белән галимнәрнең, укытучыларның үзләренең гыйльми тикшеренүләре дәверендә җыелып килгән, әмма совет чорында төрле идеологик, сәяси басымнар аркасында дөнья күрми яткан хезмәтләрен бастырып, халыкка, укучыга җиткерергә җай чыга. Яңа журналны нәшер итүдә башлап йөрүчеләрнең дә берсе – Һәнүз Мәхмүтов була. Галим басмада әдәби мирас, әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшләде. Энциклопедик белемгә ия булган әлеге шәхес үзен бөтен яктан

җитлеккән галим, эшлекле оештыручы-мөхәррир, уйлап эш итүче журналист, һәрбер мәсьәләне мәдәният күзлегеннән чыгып өйрәнүче, фактлар дөреслегенә, даталар төгәллегенә, хроникаль яссылыкның төзеклегенә аеруча игътибар белән караучы тәҗрибәле, журналны югары дәрәҗәдәге сыйфатлы басма итү өчен бөтен сәләтен, тырышлыгын куйган зыялы белгеч итеп күрсәтте. Үзе белән бергә эшләгән шәкертләрендә дә шундый сыйфатлар тәрбияләде, аларның остазы булды. Һәнүз Мәхмүтов гомере буе китапханәләрдә, архивларда утырып, революциягә кадәр басылып чыккан гарәп шрифтларындагы татар газеталарын, басма китапларны укып, өйрәнеп, аларны күчереп алып, зур мирас фонды булдырган галим. Хәбәрдарлык, сүз иреге заманнары килгәч, аның җыйган язмаларына юл ачылды. Күренекле әдибебез Гаяз Исхакый мирасын кайтаруда аның хезмәте зур. Һәнүз Мәхмүтов язучы турында бай архив булдыра һәм «Мирас» журналының һәр санында татар халкын әдипнең иҗаты, әсәрләре белән таныштырып барды. Аның тырышлыгы аркасында журнал битләрендә укучы әле беркайда да басылмаган «Олуг Мөхәммәд» драмасын уку бәхетенә иреште. Кыскасы, аның Г. Исхакый иҗатын кайтарудагы фидакарь эшчәнлеге ихтирамга лаек. Моннан тыш, Һ. Мәхмүтов рецензия, иҗат портретлары, тарихи очерклар бастырды, радио һәм телевидениедә, фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясады. Әмма барлык көчен, белемен җигеп иҗат иткән вакытта гадел, намуслы, фәнни, һәр язмага сак караучы галимебезне миһербансыз үлем 1996 елның декабрендә арабыздан алып китте. Әмма аның мирасы, татар театры үсешендәге фәнни казанышлары, заман таләбенә җавап бирердәй кыю фикерле хезмәтләре, тирән эчтәлекле иҗаты хәзинә булып калды. Бик күп җыелган язмалары, тирән гыйлеме, яза белү сәләте булуга карамастан, тыйнаклыгы аркасында, докторлык дәрәҗәсен дә якларга ашыкмады. Әмма фидакарь галимнең иҗаты буыннан-буынга күчәр, яшь галимнәр тарафыннан аның хезмәтләре тагын да тирәнтен өйрәнелер дигән өмет бар. Быел аңа 85 яшь тулган булыр иде. Һәнүз Котдус улы Мәхмүтовның бөтен максаты да – татар халкын милли рухта тәрбияләүдә, милли үзаңны үстерүдә, телне, милләтне саклауда булды.

**Әдәбият**

Әстерханда татар театры // Мирас. 1994. № 1–3, 7–12.

*Гыймранова Д.* Фәнни төгәллек, шигъри хисчәнлек // Мирас. 1993. № 7. Б. 30–33.

*Мәхмүтов Һ.К.* Татар драматургиясендә трагедия жанры. Казан: Казан. ун-ты нәшр., 1965. 111 б.

Татар совет театры. Казан: Татар. кит. нәшр., 493 б.

Татар энциклопедиясе: 6 томда. Казан, 2014. Т. 4. 632 б.

***Гыйниятуллина Флёра Сөләйман кызы,***
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты Энциклопедистика үзәгенең татар текстларын тәрҗемә итү бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 82-94

*Гаяз Исхакый*

# «ЯПОНЛАРНЫҢ ДА БЕРАЗ ЯРДӘМЕНӘ ЫШАНГАН ИДЕК...»[1]

*(көндәлек дәфтәреннән)*

В публикации представлен отрывок из дневника татарского писателя и общественного деятеля Гаяза Исхаки (1878–1954), составленного в мае-июне 1919 г. В нем описано пребывание писателя в Японии, где он с единомышленниками предполагал получить въездную визу для участия в Версальской мирной конференции. Часть из дневника писателя была уже опубликована. Электронные копии дневников Г. Исхаки хранятся в Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, Г. Терегулов, Ф. Туктаров, Япония, О. Сигэнобу, национальное движение татарского народа.

*1919 ел, 23 нче май.*

Бүген сәгать бишдә безне Японияенең зур бер мөәссәсәсенең *(оешмасының)* шактый зур мәсьүл *(җаваплы)* кешеләре кунакга чакырдылар. Мәҗлесе кечкенә иде. Танышу-аңлашу мәҗлесе иде. Сәгать бишдән, ун ярымга кадәр бергә булдык. Ашадык, эчтек, бөтен әхваль хакында сөйләшдек. Монда килгәндән бирле японлар арасында безнең хәлне бу кадәр яхшы белгән кешеләргә очраганым юк иде. Боларның икесе дә безнең Татарстанда булган. Берсе әле күптән түгел генә Чиләбедән кайткан. Бик күп өмидле сүзләр сөйләнде. Монда безгә шактый зур эшләр эшләргә мөмкинлеге күренде. Тәфсилле язарга муафикъ *(тиешле)* күрмим. Көн шуның берлән тәмам булды. Ләкин үз ноктаи нәзарымдан *(күзлегемнән)* Токиодагы көнләремнең иң тулысы булып үтде.

*24 нче май.*

Бүген һава бик матур. Көн бик күңелле. Уку-йөрүгә башка бер эш дә эшләнелмәде. Фәкать баш назыйр *(министр)* һәм дә хариҗия назыйры берлән күрешү хакында вәгъдә генә алынды. Көне, сәгате әле тәгаен ителмәгән. Мин үзем бу Токиода торудан бик туйдым, быкдым *(гарык булдым)*. Тизрәк ичмасам Йокоһамага күчәсе иде. Акчаның курсы һаман шулай. Милли идарәдән хат-хәбәр юк, Франсадан вә һакәза *(һәм башкалар)*.

*25 нче май.*

Бүген көн якшәмбе, монда бәйрәм итәләр. Японлар да үзләрен Яурупалы дип уйласынлар дип, якшәмбене бәйрәм итәләр. Өйләдән соң японларның зур бер зиярәтләренә бардык. Зиярәт бик пөхтә. Тирәсендә ихата юк, фәкать эче урам-урам итеп бүленгән дә, кечкенә-кечкенә зи-

---

[1] Исхакый Г. Япониядән китеп барышлый // Фәнни Татарстан. 2018. № 1. Б. 141–148.

ярәтчекләргә аерылып, тирәсе тотылган. Һәрбер бүлем эчендә бер гаилә, бер фамилиянең зиярәте. Бик күбесендә зур бер таш куелган. Шуңарга кем үлгәне языла барган. Таш янында һәрбер зиярәтдә ике агач савыт. Болары кардәш-кабилә, йә дустиш килгәндә чәчәк куяр өчен икән. Бер тарафда кечкенә генә баганада, бездәге гәзитә-хат салыр өчен эшләнгән кебек ясалган кечкенә яшчиклар[1]. Аларның бер карточка салырга тишекләре бар. Бусы килгән кешегә карточкасын салыр өчен икән. Бәгъзе (*кайбер*) бер зиярәт йортларында ике яклап таш баганалардан фонарьлар ясаганлар. Гаиләдә үлек булса, йә бер махсус гыйбадәт булса, шулар ягыла икән. Зиярәтләрнең бик күбесе янында яңы[2], тазә *(әле генә өзелгән)* чәчәкләр куелган. Күбесенең өстенә сулар сибелгән. Бу арада чәчәк күтәреп килә торган бик күп хатынлар, ирләр, балаларга очрыймыз. Кабер ташларының искеләренең шәкеле *(тышкы күренеше)* табигый ташлар. Күбесе таудан ничек чыкса, шул көенчә басдырып куелган. Соңгы еллардагы каберләрдә дүрт кырлы, безнең ташлар кебек. Агач бик күп, һәммәсе бик зур кадерләп үстерелгән. Артык ботаклары киселгән, яфраклары тигезләнгән. Сәрви *(кипарис)* кебек, нарат-чыршы кебек, каен кебек зур агачлар юк. Юлларында һичбер чүп-чар юк. Зиярәт ямь-яшел, каберләр өсте чәчәккә баткан. Японлар зиярәтне бик сөяләр булырга кирәк һәм дә бик еш зиярәткә килә булырга кирәк. Шул ук зиярәтдә без японча язылган ташлар өстенә салиб *(тәре)* куелган каберләргә очрыймыз, болар христиан-японлар. Япониядә диндә хөррият булганга, монда зиярәтләр дә аерылмаган икән. Ләкин бу мәнфи *(күңел кайтаргыч),* начар тәэсир калдыра, чөнки милләтләрдә иң нык саклана торган гадәт, йола – үлү-күмү гадәте, йоласы. Бонда милләтләр [...] гадәтләрен, йолаларын саклыйлар, үзләренә чит милләтнең гадәтен, йоласын кертмиләр. Японлар [исә] читләргә тәкълиддә *(иярүдә)* шул кадәр йомшаклар булырга кирәк ки, болар иң мөкаддәс булган зиярәтләрендә [дә] чит гадәтдән мөхафәзә итә алмаганлар *(саклана алмаганнар).* Тагы шуны онытмаска кирәк, япон халкының игътикадынча *(ышануы буенча)* үлү – бетү түгел, фәкать башка рәвешкә керү генә. Шулай була торып да, шул кадәр мөсаһәлә *(җиңел карау)* боларның бик җиңеллек берлән Яурупа мәдәниятенә, Яурупа диненә, Яурупа гадәтенә батачакларын күрсәтәдер. Ләкин монда христианлык тәдриҗи рәвешдә *(акрынлап-акрынлап)* тәрбия берлән бирелә. Мәктәп, матбугат, музыка аша керә. Бер зур зиярәт янына туктыймыз. Аның зур таш артына озын гына такталарга бик күп сүзләр язылып, уелып куелган. Бу бер рәссамә[3] япон хатынының кабере. Ул язган такталарда

[1] Дөресе: ящиклар.

[2] Яңы – яңа.

[3] Рәссамә – хатын-кыз рәссам.

дустлары, сөйгәнләренең биргән адреслары. Уң якда визитный карта өчен яшчик. Мин дә карточкамны алдым да, шул яшчиккә салдым. Без бит икемез дә Олуг Асиянең ахмак балалары. Без бит икемез дә Олуг Асиянең үзенең кадерен үзе белми торган балаларына, үзенең кыйммәтле якларын күрсәтергә тырышучы, үзенең хәятының матурлыкларын күз алдына китереп, асияленең үзенә үзенең[1] ышануын уятырга теләгән җүләрләре. Син инде үлгән, мин әле йөрим, ләкин син бер эз калдыргансың, мин дә бер эз калдырачакмын. Бик ихтимал, синең рәссамлыкда ясаган Асиялек эзенең[2] күзен акайтып, Яурупалы хәят артыннан чаба торган япон гәнҗе *(яшьләре)* таптап киткәндер. Китмәгән булса, китәчәкдер. Минем милли хәятымызда калдырырга теләгән эземне дә, бәлки, руслык кары, русларга тәкълид *(иярү)* басып киткәндер, йә китәчәкдер. Ләкин без үз вазыйфамызда булырга тиеш, син шул вазыйфа кебек, йә син дә инде үлгәнсең, мин шуның артыннан монда килдем. Зиярәт янында ике яклап бик күп кабер ташы һәм кыр чәчәге [кисентеләренә] очрыймыз. Көн кич. Күрше казармада быргы чалып солдатларны өйләренә җыялар. Без дә өйгә китәмез. Хәерле кичләр.

*26 нче май.*

Бүген иртүк автомобиль алып Франса һәм инглиз сәфарәтханәләренә китәмез. Франсадан җавап һаман килмәгән. Англичанлар безнең хакда мәгълүмат алыр өчен Русиядәге инглизләрнең фәүкыльгадә *(гадәттән тыш)* комиссарлары Ыслайтонга телеграф берлән мөрәҗәгать иткәнләр, шундан җавап алмаенча бер эш эшли алмыймыз, диләр. Без үземез Русиядә вакытда шул эшне бетереп килмәгәнмез. Омскида вакытда минем керергә зур ниятем булды, фәкать шундагы куркак кешеләр: «эш бозылмасын-фәлән, Колчак[3] белмәсен», дип тискәрегә димләделәр. Андан соң минга бик күңелсез акча җыю вазыйфасы йөкләтелгәнгә, эллә никадәр гайрәт шуңарга китде. Киңәш итергә кеше булмады. Фуадка[4] шул хакда телеграмма биргән идем, ләкин ул үзенең көчен иң күбесен [Ижескага] бозарга сарыф итәргә өйрәткәнгә, әлбәттә, эшләмәгән. Харбинда Гомәр[5] куркып, башны әйләндереп һаман шул минем планларымны сүтә килде. Андан соң, без монда чыгу ул кадәр авыр булмас дип уйлаган идек. Японларның да бераз ярдәмләренә ышанган идек, боларның берсе дә килеп чыкмады, хәерле булсын инде. Хәзер теләр-теләмәс көтәргә мәҗбүрмез. Өйләдән

---

[1] Дөресе: үз-үзенә.

[2] Текстта шулай язылган. Дөресе «эзеңне» булырга тиеш.

[3] Колчак – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), рус хәрби сәясәт эшлеклесе, галим-океанограф, Гражданнар сугышы вакытында «Ак»лар хәрәкәте җитәкчесе.

[4] Фуадка – Мәхмүт-Фуад Фәсах улы Туктаров (1880–1938), юрист, журналист, Бөтенроссия Учредительный собрание әгъзасы.

[5] Гомәр – Гомәр Хәбибрахман улы Терегулов (1883–1938), юрист, меньшевик, Милли мәҗлес депутаты.

соң Гомәр берлән киңәшләшеп, Харбинга һәм дә Владивостокга китүче татар егете артындан, анда бәгъзе берәр эш эшләргә кушып, озын мәктүпләр язам. Бәлки бер нәрсә чыгар. Нияз әфәндедән һаман мәктүп юк. Бу арада гәзитә дә килми башлады, Милли Идарәдән дә хат юк. Кич берлән японларның иске театрларына барамыз. Аякдан ботинкаларны чыгарып, оекчан көенчә керәмез. Театрның бинасы бик зур. Үзе агачтан эшләтелгән булса да, сөнбеле матур. Ишекдән керүгә диварга сөяп куйган бик күп сонгый *(ясалма)* букетлар каршы ала. Болар артистларга бирелгән бүләкләр. Идәндә җефәк арканлар берлән бәйләгән бүләк сандыклары тезелгән. Эчкә керәмез. Театр дүрт почмаклы итдереп эшләтелгән. Каршы якда сәхнә. Ләкин сәхнә эчкә кереп тормый, бәлки яртыга таба чыгып тора. Яртыга камыш намазлык җәйгәнләр дә, аны ике кеше сыярлык дүрт почмаклы шакмакларга тәбәнәк кенә киртә берлән бүлгәнләр. Ул шакмакларның идәненә кечкенә мендәрләр салганлар. Сәерчеләр шуларга кереп утырган. Зуррак кешеләр икешәр-өчәр, бала-чагалар дүртәр утыралар. Һәрбер шакмак эчендә бер гаилә. Ул үзенең шакмакында мохтар *(ирекле)* түгел, камыш намазлыклы мохтар. Яртысы, иң тугрысы идән сәхнәдән ерагайган саен, өсткә таба күтәреләә барган сәхнәнең сулуң як канатлары тәмам күтәртеп үк эшләтелгән. [...] соң тагы бер кат бар. Андан соң тагы бер кат. Без сәгать җиделәрдә барганга, яхшы урын юк. Алай да безне идәндәге бер шакмакка утырталар, астымызга мендәр салалар, алдымызга кечкенә генә мангал бирәләр. Бер чәйнек берлән япон чәе, кечкенә генә савытларда ике төрле япон татлысы, япон хәлвәсе китерәләр. Театр дәвам итә. Фәкыйрь бер гаиләнең ярлылык фаҗигасе. Әллә нинди сүзләр, бер нәрсә түгел. Уйнаулары һаман бер төсле. Артда чылтыр-чылтыр итеп думбыра суккалыйлар. Әллә нидә бер нечкә, җиңел тавыш берлән бер бала сузып-сузып бер нәрсә сөйли, күренмәенчә әллә кем, әллә нәрсә ерлый. Артистка ролен уйный торган зур иләмсез япон яшел тавыш берлән сөйләп бер туктамаенча егълый. Уенларында осталык-фәләнлек бер дә күренми. Ләкин халык бик ярата булырга кирәк. Хатынлар бер туктамаенча еглап утыралар. Мин күршеләремә карыйм. Бер якда ирле-хатынлы бер гаилә унике-унөчле[1] кызлары, тугыз-унлы угыллары алдына утырган, карап утыралар. Өч-дүрт яшьлек бер балалары атасының итәгенә яткан да, йоклап тора. Хатыны кулына ике чыбык тотып дөгене бер алып каба да, бер сәхнәгә карый. Бер карый да, бер алып каба. Әфәндесе *(ире)* тагы ике чыбык тоткан да, бер дөгедән, бер серкәләгән яшелчәләр капкалап, сәхнәдән күзен алмый. Уң як күршемдә карт кына бер хатын кечкенә генә касә берлән чәй эчә. Ике-өч яшьлек бала үз шакмакларында уйнап йөри. Яшь кенә бер

[1] Дөресе: унике-унөч яшьләрдәге.

хатын әфлисунлар әрчеп-әрчеп ашап утыра. Театрда бала бик күп булса да, тавыш юк, халык тын, һәммәсе тезләнеп, аягын бөкләп, рәхәтләнеп утырганлар. Бик күбесендәге чалбар – анадан туган чалбарлар булганга, ялангач, безнең кебек тезе бөгелүдән һич курыкмыйлар. Ләкин уен вакытында һаман йөреп торалар. Берсе чыга, берсе керә. Бер официант чәй китерә. Бер сатучы мивә *(җиләк-җимеш)* китерә. Бер ашчы дөгеләр-яшелчәләр күтәреп үтеп китә. Менә тәмам. Пәрдә төшде, иң тугрысы, безнең авыл өйләрендәге кебек пәрдә тартылды. Халык бераз хәрәкәткә килде, торды, чыкды, без дә чыкдык. Югарыгы катларны гиздек. Бөтен коридор кеше берлән тулган. Җыен чүп-чар, шарабараны саталар да торалар. Кем ала, ник ала – Алла белсен! Югарыда ике буфет, берсе аяк бөкләп утырырга, берсе урындыкка. Анда ашап-эчеп утыралар. Тар коридорда тыгыла-кысыла хатынлар йөриләр. Менә агач чүкеч берлән агачка сугалар. Бу пәрдә ачылуга галәмәт. (Финляндиянең Сеймында да «Дикъкать» дигән әмерне рәисе агач чүкеч берлән агач сугып белдерә.) Урыныбызга утырамыз. Пәрдә күтәрелә. Дикаратсия[1] бик матур: диңгез, көймәләр, җилкәнләр, дулкынлар бик һәйбәт эшләтелгән. Япониянең катыргасы *(галерасы)*. Ләкин бу юлы да уен бик бер төсле, бер вакыйга бик озын сузыла. Бер мәртәбә еглап бетергәнче, эш өчен ун мәртәбә еглатыла. Яңгы пәрдә ачылды. Монысы иске бер әкият: шайтанлар, пәриләр, самарайлар, гейшалар. Һәммәсе бик күңелле генә, ләкин хатын ролен ирләр уйнаганга, бик чиркен бер хис калдыра. Без китәргә буламыз. Җыенына *(сеансына)* ике кешегә җиде иен алалар. Шактый бәһале *(кыйммәт)*. Һәммә урын бер бәһадән икән, ләкин үзләре өчен бәһале түгел. Бердән, ул иен аларга һаман элгәреге иен. Икенчедән, алар иртәнге сәгать ундан килеп, кичке сәгать унбергә кадәр утыралар икән. Болар бөтен гаиләсе берлән иртәдән үк килеп, шунда ашап, эчеп, шунда көн буе үткәрәләр икән. Иң тугрысы болар айга бер, ике айга бер театр эченә хозурга чыгалар икән. Бәлки бу театрлар тагы тәрәккый итә төшәр. Ләкин бу әле балагандан зур аермалы түгел.

*Текстны басмага әзерләде:*
***Ханнанова Гөлчирә Мәхмүт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

[1] Дөресе: декорация.

## Татар язма әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). I т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык

Мәгълүм булганча, әдәби тел үзенең табигате һәм вазифасы белән катлаулы күренеш тәшкил итә. Аның нигезе язма истәлекләрдә чагылыш тапкан традицияләр, нормалар һәм билгеле бер төбәккә хас булган җанлы сөйләм теле үзенчәлекләре белән тыгыз бәйләнештә формалаша. Шул ук вакытта әдәби телнең табигатендә иҗтимагый тормышта бара торган вакыйгалар, ягъни экстралингвистик факторлар да чагылыш таба. Шуңа бәйле рәвештә ул төрле яклап өйрәнелергә мөмкин. Мәсәлән, бүгенгә кадәр татар әдәби теле тарихы өлкәсендә алып барылган фәнни тикшеренүләрдә төп игътибар билгеле бер чорларга караган язма чыганакларның тел-стиль үзенчәлекләрен, аларда гомумтөрки традицияләрнең һәм җанлы-сөйләмә формаларның ни рәвешле чагылыш табуын ачыклауга юнәлтелде. Ләкин ничек кенә булмасын, әдәби тел, аның табигате һәм тарихы, иң беренче чиратта, гомуми лингвистикада кабул ителгән тәртиптә, ягъни телнең фонетика, морфология һәм лексика тармакларына нигезләнеп тикшерелергә тиеш.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында бер төркем галимнәр тарафыннан эшләнә торган «Татар әдәби теле тарихы» монографиясенең 2015 елда дөнья күргән беренче томы нәкъ менә әлеге юнәлештә язылган. Ул иске татар язма әдәби теленең фонетик һәм график үзенчәлекләрен тарихи планда өйрәнүгә багышлана. Аның авторлары (филология фәннәре докторы И.Б. Бәширова, филология фәннәре докторы, профессор Ф.Ш. Нуриева, филология фәннәре кандидаты, доцент Э.Х. Кадыйрова) бу өлкәдәге традицияләрне, норма һәм норма вариантлылыгын билгеләүне, аларның төрле чорлардагы үсеш-үзгәрешен ачып бирүне максат итеп куйганнар.

Хезмәтнең бай эчтәлекле кереш өлешендә әдәби тел тарихын өйрәнүнең фәнни-теоретик нигезләре яктыртыла. Биредә шунысы игътибарга лаек, ул гомумтел белеменең бер тармагы буларак карала. Алга таба тел һәм тарих берлеге исәпкә алынып, һәм татар тел белемендә кабул ителгән чорлар бүленешенә (Болгар дәүләте чоры Идел буе төрки язма әдәби теле, Алтын Урда чоры Урта Идел буе төрки-татар язма әдәби теле, Казан ханлыгы чоры иске татар язма әдәби теле, XVII–XVIII гасырлар иске татар язма әдәби теле, XIX гасыр – XX гасыр башы иске татар язма әдәби теле) нигезләнеп, иске татар язма әдәби теленең үсеш тарихы яктыртыла һәм әлеге нигездә язма истәлекләрдә чагылыш тапкан фонетик һәм график үзенчәлекләр өйрәнелә, гасырлар дәвамында сакланып килгән борынгы традицияләр, әдәби тел нормалары, аларның вариантлары билгеләнә. Әйтергә кирәк, хезмәтнең авторлары

әлеге катлаулы мәсьәләне югары фәнни дәрәҗәдә хәл итүгә ирешкәннәр.

Биредә берничә моментка игътибар итми мөмкин түгел. Беренчедән, әдәби тел үсешенең халык тарихы белән үзара бәйләнешен истә тоту бүлекләр бүленешенең нигезлелеген күрсәтә. Икенчедән, һәр бүлектә язма традицияләрнең үсүе һәм ныгуы, шул ук вакытта әлеге өлкәдә яңа күренешләрнең дә барлыкка килүе күпсанлы иллюстратив материаллар белән дәлилләнә. Нәтиҗәдә татар әдәби теленең тирән тарихы булганлыгы ачыла һәм раслана. Өченчедән, хезмәт гаять бай фәнни әдәбиятка нигезләнеп язылган. Бу – тикшеренүнең объективлыгын, нәтиҗәләрнең чынбарлыкка туры килүен күрсәтә. Шуның белән бергә, китап татар тел һәм әдәбият белеменең яңа казанышларын фәнни әйләнешкә кертү, аларны киң җәмәгатьчелеккә таныту ягыннан зур әһәмияткә ия. Дүртенчедән, авторларның тикшеренүләренә җентеклелек, билгеле бер системалылык хас һәм ул әлегә кадәр сорау булып кала килгән күренешләрне ачыкларга, аларны яңа күзлектән карап тасвирларга, аңлатырга ярдәм итә.

Китапта беренче мәртәбә татар язма әдәби телен өйрәнүнең торышы турында бай һәм киңкырлы мәгълүмат бирелә, яңа исемнәр, яңа хезмәтләр китерелә. Аерым алганда, куелган мәсьәләләрне хәл итү барышында һәр чорның әдипләре, дин әһелләре, публицистлар, дәүләт эшлеклеләре, аларның эшчәнлеге турында тулы һәм гаять җентекле мәгълүмат бирелә. Бу эш аерым бер дәвер, аңа характеристика, иҗтимагый вакыйгалар һәм процессларга бәя бирү белән бәйләп алып барыла. Нәтиҗәдә тел белән тарихның үзара ныклы бәйләнеше хезмәтнең башыннан ахырына кадәр исбатлана бара. Биредә иң мөһиме – язма әдәбиятка хас булган традициялелекнең ролен һәрдаим яктыртып бару. Шуның аша хезмәттә татар язма әдәби теленең нигез-тамырлары ачыклана, үсеш-үзгәреш этаплары билгеләнә.

Иске татар язма чыганакларының тел үзенчәлекләрен өйрәнү белән бәйле катлаулы мәсьәләләрнең берсе – ул сузык һәм тартык авазларның, аларның калын һәм нечкә вариантларының гарәп графикасына нигезләнгән язуда бирелешен ачыклау, бу өлкәдәге традицияләрне, норма һәм норма вариантларын билгеләү. Аның куелышы һәм чишелеше хезмәткә тулаем хас булган энциклопедик төсмерне тагын да арттыра. Әлеге мәсьәлә китапның төп өлешендә, язма әдәби телнең һәр чорына мөнәсәбәтле рәвештә, күпсанлы язма чыганаклардан тупланган мисалларны җентекле анализлау барышында хәл ителә. Шул нигездә авазларның язуда кулланылыш үзенчәлекләре, бу өлкәдәге традицион закончалыкларның чордан чорга ничек үзгәрә баруы эзлекле рәвештә тикшерелә, әдәби норманың ныгуы күзәтелә һәм шул нигездә иске татар теленең табигатен билгеләгән ике төп үзенчәлек аерып чыгарыла:

1) гарәп-фарсы алынмаларының чыганак телдәгечә бирелеше;

2) төрки-татар сүзләренең төрки телләрнең үз кануннарына нигезләнеп язылышы.

Хезмәттә фактик материалны анализлау төрле ысулалымнар белән башкарыла. Авторлар тарафыннан статистик исәпләүләр дә кулланыла. Алар, үз чиратында, фәнни тикшеренүнең әһәмиятен бермә-бер арттыра, куелган гипотезаларның, ясалган нәтиҗәләрнең объектив икәнен раслый.

Шуның белән бергә, авторларның игътибарын түбәндәге моментларга җәлеп итәсе килә:

1. Китапта фикер сөрешен аңларга кыенлык тудыра торган артык озын җөмләләр очрый. Шул ук вакытта аерым урыннарда иллюстратив материалның күплеге күзгә ташлана.

2. Хезмәтнең анализ өлешендә хәзерге әдәби телгә хас булмаган иске татар теле үзенчәлекләре дә урын ала. Бу бигрәк тә тартымлы төшем килешенең бирелешендә күзәтелә.

3. Алда әйтеп үткәнчә, эш барышында күпсанлы әдипләр, галимнәрнең эшчәнлегенә бәя бирелә, бу шәхесләрнең әсәрләре, хезмәтләре һәм фикерләре анализлана. Китап татар халкы тарихын, мәдәниятен өйрәнүчеләр өчен мөһим белешмәлек ролен үтәячәк. Шуңа күрә аны тиешле күрсәткечләр белән тәэмин итү сорала.

Әлбәттә, югарыда әйтелгәннәр башкарылган эшнең әһәмиятен берничек тә киметмиләр. Йомгаклап әйткәндә, авторлар тарафыннан зур күләмле һәм бай эчтәлекле фәнни хезмәт язылган. Ул татар һәм төрки тел белемендә, һичшиксез, лаеклы урын алачак.

***Рамазанова Дария Бәйрәм кызы,***
*филология фәннәре докторы*

# МӨХӘММӘТШИН ГАРИФҖАН. КАРИЛЕ – КАРА ИЛЕ[1]

Авылда туган һәркем өчен Туган җир төшенчәсе Туган авыл исеме белән тәңгәл килә. 1917 ел Октябрь инкыйлабы һәм ул алып килгән кискен үзгәрешләр милли гореф-гадәтләрне искелек калдыгы дип игълан итте, төп максат итеп коммунизм төзүчеләр тәрбияләүне куйды, кешеләрнең менталитетын тамырдан алыштырды, бер сүз белән әйткәндә, тарихи дәвамлылыкны өзде. Авыл тарихы белән шөгыльләнүчеләр – гаилә, нәсел, авыл дәрәҗәсендә, ягъни иң нечкә, катлаулы өлкәдә шушы тарихи дәвамлылыкны ялгаучылар, тарихи хәтерне торгызучылар, милли горурлыкка нигезләнгән үзаң формалаштыручылар алар. Алар кулында гаять тәэсирле көч бар. Ул – авылдашларының үрнәк булырлык күркәм гамәлләре, уй-хыяллары. Чөнки туганыңның, авылдашыңның шәхси үрнәге – тормыш мисалы, үткән буыннар турында хәтер яңарту – ниндидер купшы сүзләргә караганда ныграк тәэсир итә, еш кына алда торган катлаулы мәсьәләләрне чишү юлларын билгели, күрсәтә.

Күренекле шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, төбәк тарихын йөрәнүче Гарифҗан ага Мөхәммәтшин Татарстанның Балтач районы тарихы һәм анда яшәүчеләр турында ике томлык энциклопедия бастырып олы фәнни батырлык эшләгән иде. Ә туган авылы Арборга багышланган саллы хезмәте авторның Кариле авылы турында язылачак китабына әзерлек булган икән.

«Кариле – Кара иле» китабы авторның «Кереш сүз»е белән ачыла. Текст өч бүлектән тора, алар хронологик яктан 1917 елга кадәрге заманны, Совет чорын, һәм 1992 елдан бүгенгегәчә вакытны үз эченә ала. Төп текстны берничә күләмле кушымта тулыландыра.

Бу хезмәт күп ягы белән гаҗәпкә калдыра, шаккатыра. Беренчедән, күләме белән. Бер авыл турында 100 басма табаклык китап нәшер итү бик сирәк күренеш. Икенчедән, мавыктыргыч әдәби тел белән язылуын махсус әйтми мөмкин түгел. Авторның авыл тормышын белеп, карилеләргә олы хөрмәт белән багып, яратып язылган китапны укый башлагач, аерылып булмый. Тарихны шулай мавыктыргыч итеп сурәтләү авторның язучылык талантын ачык күрсәтә. Өченчедән, туган авыллары тарихын булдыру карилеләрнең берсен дә битараф калдырмаган. Һәрберсе истәлекләре, гаилә фотоальбомындагы ядкарьләр белән, рухи яки матди яктан ярдәм итеп, авыл җәмгыятенең уртак проектына үз өлешен кертергә тырышкан, шул рәвешле китапның гаҗәп кызыклы эчтәлекле һәм сурәтләргә бай булуын тәэмин иткән. Бу хакта басманың титул битендә урнаштырылган «Китап Гөлсем Миңнебаеваның

[1] Мөхәммәтшин Гарифҗан. Кариле – Кара иле. Казан: ПИК «Идел-Пресс», 2017. 856 б.

тырышлыгы белән авылыбыз эшмәкәрләре һәм авыл халкыннан җыелган акча хисабына чыгарылды» дигән җөмлә искәртә.

Хезмәтнең уңышы – авторның авыл тарихына бәйле булган барлык төр чыганакларны да оста куллануында. Үзәк һәм төбәк архивларында саклаучы яки басылган халык санын алу һәм метрикә кенәгәләре, кабер ташлары, шулай ук земство, архивлардагы хакимият органнары кәгазьләреннән бөртекләп җыелган мәгълүматлар, тарихи хезмәтләрдә чагылыш тапкан материаллар авыл җәмгыятенең берничә гасырлык социаль тормышын күзалларга мөмкинлек бирә.

Китапның үзәгендә – мәшһүр шәхесләр, иҗтимагый һәм дәүләт оешмалары. 1917 елгы инкыйлабка кадәрге чорда авылга нигез салыну тарихы, игенче җәмгыяте һәм лашманнарның социаль хәле, мәхәллә, мәчет-мәдрәсә, имам-мөгаллимнәр, сәүдәгәрләр сурәтләнә, авыл тарихында табигать һәм тормыш афәтләре, Пугачев баш күтәрүендә катнашу кебек вакыйгалар яктыртылган. Китаптан күренгәнчә, Кариленең «чәчәк аткан» вакыты XVIII гасырның урталары – XIX йөз урталарына туры килә. Бу еллар – халыкның лашман бурычын үтәгән (1752–1859 еллар), ярминкәләр илнең төп сәүдә үзәкләре булган һәм әле Россия сәнәгатенә техник үзгәртеп-кору кермәгән заман. Карилеләр шушы вакыт арасында йомышлы татарлар кебек (бигрәк тә XVIII гасырның урталарында) төрле төбәкләргә ирекле бару һәм сәүдә итү мөмкинлегеннән оста файдаланганнар. Сәүдә эшенә көзге-кышкы айларда ерак урманнарда агач кискәндә оешкан лашман артельләрендә үзара ярдәмләшү, бару-кайту юлында һәм эш барышында рус телен өйрәнеп шомарган туганнар һәм авылдашларның кооперация-хезмәттәшлеге нык ярдәм иткән, дип уйлыйбыз.

Кариледә бердәм һәм кыю халык яшәгәнен 1742 елда мәчетләрне массакүләм япканда гыйбадәтханәне саклап калу, Пугачев җитәкчелегенә баш күтәрү елларында хакимиятне үз кулларына алып яшәүләре, баш күтәрүчеләр ягында сугыш хәрәкәтләрендә катнашулар раслап тора.

Алар беренче капиталны Оренбург якларындагы меновой дворларда яки Урта Азиягә баручы кәрваннарда йөкчехезмәтче, казакъ даларында йөкче яки ваклап сатучы буларак туплап, яңа яшәү урыннарына туганын чакырып, алыш-бирешне киңәйтеп баеп киткәннәр, дип фаразлыйбыз. Рус телен үзләштерү аларга Казанда да сәүдәгәр дәрәҗәсенә ирешү мөкинлеген биргән. Нәкъ менә шул елларда авылдан чыгып Юнысовлар, Усмановлар Казанда күренекле бай нәселләргә әверелгәннәр. Карилеләр шулай ук Оренбург, Троицк, Семипалатинск, Петропавловск шәһәрләренә туганнарын алдырып сәүдә эшләрен җайга салганнар, болар хакында китапны киләчәктә эзләнүләрне дәвам итәргә өндәүче өзек-өзек мәгълүмат урын алган.

Авылда байлар элегрәк тә булган дип фаразларга нигез бар. Чөнки данлыклы мәдрәсәләр бай

белән гыйлем иясе бердәмлеге нигезендә генә төзелә. Беренчесе матди базаны һәм мөдәрриснең һәм шәкертләрнең яшәү шартларын, ризыкларын кайгыртса, икенчесе сабак биргән. Кариленең әлегә исемнәре билгесез байлары ярдәме белән Уфа губернасыннан килгән Габдессәлам хәзрәт, XVIII гасырның икенче чирегеннән башлап, 60 ел дәвамында мөдәррислек итеп, авыл мәдрәсәсен төбәкара ислам белеме бирү үзәгенә әверелдерә, берничә буын тирән гыйлемле руханилар әзерләүгә зур өлеш кертә. Китапта язылганча, XIX гасыр башыннан Кариледәге уку йорты башка авыллардагы кебек гадәти башлангыч мәктәп булып кала, моның сәбәпләренең берсе – укытуның сәүдә-табыш эшен алгы планга куйган муллалар буыны кулына күчү. Китапта китерелгән земство статистика мәгълүматлары XIX гасыр азагында – XX йөз башында авыл халкының нигездә игенчелек белән шөгыльләнгәнен раслый, шулай ук кибетләр тотучы берничә шәхес булуы элекке традицияләрнең югалмавына ишарәли.

Совет чорына багышлаган бүлекнең уңышы – хезмәтне хуҗалык кенәгәләрен, район газетасы материалларын, өлкән буын вәкилләреннән махсус яздыртылган истәлекләрне уңышлы файдалану һәм авторның, замандаш буларак, үз тормыш тәҗрибәсенә таянып язуында. Текстларда балалар бакчасы, мәктәп, клуб, китапханә, медицина пункты кебек сәламәтлек саклау, уку-укыту һәм мәдәни институтлар, социаль объектлар, почта бүлекчәсе, үзидарә органы булган авыл советы эшчәнлеге, колхоз һәм сәнәгать оешмалары эшчәнлеге, үзешчән сәнгатьтә катнашу, спорт, ял итү һәм күңел ачу чаралары аша совет идеологиясе урнашу, төрле буын вәкилләренең тормыш-көнкүреше яктыртыла, җирле интеллигенциянең халыкның мәдәни тормышында, яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә тоткан урыны билгеләнә.

Ил буенча авылда яшәүчеләр саны кимегән бер вакытта, Кариле үсеш кичерә. XX гасырның соңгы өч дистә елында Кариле төбәкара сәнәгать үзәгенә кагылышлы торак пункты буларак үсә, Тимирязев исемендәге колхоздан тыш чиктәш Нормада ачылган «Сельхозтехника» берләшмәсе бирегә күрше авыллардан күченеп төпләнүчеләрне арттыра. Берничә чакрымдагы район үзәге оешмаларына барып эшләүчеләрне исәпләсәң, авыл кешеләренең социаль йөзе эшчеләр поселыгында көн итүчеләргә туры килә. Республикада андый авыллар күп түгел. Иҗтимагый һөнәр бүленеше ягыннан эшчеләр поселыгы, ә рәсми кәгазьләрдә авыл буларак теркәлгән Кариле мисалында торак пункты тарихын язу тәҗрибәсе махсус өйрәнүгә лаек.

Китапның өченче бүлеге бераз үзгә структурага нигезләнгән. Очерклар авыл тормышының төрле якларын ачу концепциясе кысаларында язылган. Бирелә Кариленең ил мәнфәгате белән яшәп, авыл кешеләренең чирәм җирләрне үзләштерүе, Бөтенсоюз төзелешләрендә катнашулары,

совет армиясендә хезмәт итүләре, күрше өлкә һәм союздаш республикаларда алар ирешкән хезмәт җиңүләре сурәтләнә. Төп идеяне ачарга күп балалы гаиләләр, авылга радио, электр, телефон челтәрләрен сузу, су колонкалары кую, газ кертү, совет кешесенең тормыш дәрәҗәсенең төп маркерлары булган телевизор, мотоцикл, җиңел машина алу, социаль объектлар һәм мәчет төзү, дини йолаларның кайтуы, сабантуйлар турында сюжетлар, җирле топонимия турында язмалар нык ярдәм итә.

Китапта урнаштырылган төрле чорларга караган фотолар хакында махсус искәртү мөһим. Аларның саны бихисап. Фотосурәтләр төрле буын карилеләрнең йөз-кыяфәтләрен, аларның үткән һәм бүгенгесе тормышын чагылдыручы кыйммәтле чыганак булудан тыш, бер авыл мисалында милләтебезнең тарихи дәвамлылыгын гәүдәләндерә.

Автор карилеләрне бик калку итеп күрсәтү мөмкинлеген тапкан. Аларның кайберләре төп текстта Россиядә бертуктаусыз барган һәм бүген дә дәвам итүче реформалар фонында, авылның социаль тормышын сурәтләгәндә күреп-күренеп китә. Ә китапның кушымтасында урнаштырылган биографик белешмәләр, очерклар бу булдыклы шәхесләрне тулырак итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Киңкырлы эшчәнлекләрен исәпкә алып, берничә буын авыл кешеләре хакында материаллар «Кариле йолдызлыгы», «Кариле шәҗәрәләре», «Кариле авылыннан Бөек Ватан сугышына китеп, җиңүне яулап кайтучылар һәм шәһит булганнар», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында батыр хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнгән авылдашлар исемлеге», «2016 елның 28 октябрендә Кариле авылында яшәүчеләрнең исемлеге», «Кариле бизәкләре» (фотолар), «Карилеләр иҗаты» исемле бүлекләрдә бирелгән.

Кушымтада урнаштырылган 1678 елгы җан исәбе алу кенәгәсе һәм 1722, 1744, 1762, 1795, 1812, 1816, 1833, 1850 елгы ревизия материаллары, табылган кадәр метрикалардан һәм ЗАГС язуларыннан күчермәләр (1834, 1835, 1842, 1843, 1845, 1846, 1848, 1850, 1855–1857, 1860, 1864–1889, 1891–1929, 1931–1939, 1942–1952 еллар) урнаштыру кыйммәтле массакүләм тарихи чыганакларны иҗтимагый әйләнешкә кертергә мөмкинлек бирә. Китапта тупланган мәгълүматлар ярдәмендә яңа буын вәкилләре мөстәкыйль рәвештә нәсел шәҗәрәләрен төзи, бабаларының килен алып, кыз биреп күрше авыллар кешеләре белән туганлашу тарихын һәм никахлашучыларның яшьләрен, гаилә әгъзалары санын һәм уртача гомер озынлыгын, кайсы айларда балаларның күбрәк туу вакытын, чит төбәкләрдән килеп төпләнүчеләрне һәм башка кайбер демографик тарих битләрен яза алалар.

Инде килеп китаптагы хаталарга тукталыйк. Алар юк түгел, күбесе беренче бүлеккә карый һәм XVI–XVII гасыр тарихының начар өйрәнелгән булуы, авторның тарихи чыгакларны төгәл анализламавы белән аңлатыла.

Без җитешсезлекләрне берничә төркемгә бүлдек.

*Терминнар.* Билгеле булганча, XVI–XVII гасырларда рус хакимияте тарафыннан уздырылган йорт хисабын алу йорт башыннан салым алу өчен үткәрелгән һәм «писцовый кенәгәләргә» теркәлгән. Петр I дән башлап 1858 елга кадәр игенчеләр һәм мещан җәмгыятьләренә салым бүлү максатында уздырылган халык исәбен алу кәгазьләре «ревизские сказки» дип аталган. Россиядә ревизияләр 10 тапкыр үткәрелә: 1719, 1744 (текстта 1740), 1762, 1782 (текстта 1780), 1795, 1811 (китапта 1812), 1816 (текстта аерым төбәкләрдә генә булган диелә), 1834, 1850, 1858 елларда. XVII гасырда йорт исәбен һәм җан исәбен алу «ревизия» дип аталмаган, 1897 елгы Европа статистика тәртибе нигезендә уздырылган Бөтенроссия халык санын алуны (соңгысы китапта 1895 елгы дип язылган) да өстәү дөреслеккә туры килми (13 б.). Хезмәттә Адмиралтейство хезмәтендәгеләрне XIX гасырда «лашман» дип атый башлаганнар диелә (18 б.). Әмма лашман термины 1762 елгы документларда ук очрый (А. Свечин комиссиясе документлары). «Подушная подать» XVII гасырда түләнмәгән (30 б.). Ул – Петр I тарафыннан беренче ревизия мәгълүматларына нигезләнеп исәпкә алынган һәрбер ир-ат крестьянга һәм мещанга керткән салым.

*Авылны нигезләү вакыты.* 40 нчы биттә Кариле авылы XVII гасыр башында нигезләнгән диелсә, 41 нче биттә 1570–80 елларда диелгән. Кариле авылының нигезләнү вакыты 1570–1580 елларга туры килә дип (9 б.) катгый итеп әйтү сораулар тудыра. Бәлки, ул элегрәк барлыкка килгәндер? Чөнки 1678 елгы халык санын алу буенча яшәүчеләрнең саны кариленекеннән күпкә кимрәк Казан ханлыгы чоры авыллары билгеле. Шул сәбәпле, халык саны буенча, 1678 елда яшәүчеләрнең авылга нигез салучыларның икенче-өченче буыны булуы аңлашыла диюгә нык-лы нигез юк.

*Авылның исеменең килеп чыгышы.* Китапта авылның Кари исеменнән килеп чыкмаганлыгына 1678 елгы документта Кари исеменең очрамавы нигез итеп китерелә (15 б.). Ул заманда киң таралган кеше исеме булган һәм авылга нигез салырга мөмкин булган Каринең элегрәк яшәгән булуы да бик мөмкин.

*Авылга нигез салучылар.* 1678 елда фәкать ясаклы авылларда яшәүчеләр генә исәпкә алынган. Димәк, бу вакытта Кариледә йомышлы татарлар түгел, ә ясаклы татарлар көн күргән. Ә нократ-кариле татарлары статуслары буенча йомышлы татарлар иде. Илдус Габдуллин хезмәтендә телгә алынган документта, нократ-кариле татарларының берничә авылда, шул исәптән Кариледә дә булулары турындагы хәбәр XVIII гасырның беренче яртысына карый. Ә XVIII йөз ревизия кенәгәләрендә Кариледә барлык кеше дә ясаклы крестьяннар, ягъни дәүләт крестьяннары диелгән. Димәк, нократ-кариле татарлары авылда бер мәлне генә яшәп алганнар. Электән ясаклы татарлар сословиясенә караган

Кариле авылы халкының яки аерым бер нәселенең Казан ханлыгы чорындагы аристократия нәселенә ялгана алуы бик шикле.

12 биттә Кара бәк шәҗәрәсенә караган «Кара би – Мөхәммәд би – Ильяс – Мирсәйет – Дүнәш – Җанчура – Җансәйет» нәселе линиясен Кариле авылы ревизия кенәгәләрендә таптык, дип белдерү документларга нигезләнмәгән (әйтик, китапта китерелгән 1678 елгы халык исәбен алу һәм 1722, 1762 ел ревизия материалларыннан алынган мәгълүматлар – «Яким – Янгилде – Үтәк – Мәмәт (1672–?) – Йосыф (1711–?) – Габделваһаб (1733–?)» линиясен төзи. Буыннар арасын 25–30 ел дип исәпләгәндә, Яким якынча 1580 елларда яки иртәрәк туган булырга мөмкин. Дүнәшнең 1548 елгы икәнлеген исәпкә алсак[1], аннан «Яким – Янгилде – Үтәк линиясе» китәргә тиеш булыр иде. Тик китапта 12 биттә күрсәтелгән «Дүнәш – Җанчура – Җансәйет» линиясе белән «Яким – Янгилде – Үтәк» линиясе арасында бернинди дә бәйләнеш күренми. Соңгы линия күпмедер үзгәрешләр белән 431 биттә Карабәк шәҗәрәсе дип исемләнгән шәҗәрәдә күрсәтелгән («Яким (Янка) – Янгилде – Кутнек (Кибәк) – Мәмәт – Йосыф – Габделваһаб (1733–?)» линиясе). Монда Үтәкне ни рәвешле Кутнек (Кибәк)кә әйләндерү аңлашылмый.

Без, тел тарихы белгечләре фикерләренә таянып, Карилеләрнең ерак бабалары ногайлар булган дигән фикердә калабыз.

Әлбәттә, аталган кимчелекләр хезмәтнең фәнни дәрәҗәсен киметми, ә авыл оешу вакытын тагын да җентекләп, яңа чыганаклар табып өйрәнергә кирәклеген кенә искәртә.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***
*тарих фәннәре докторы,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*яңа тарих бүлеге мөдире*

***Фәйзрахманов Илшат Җәүдәт улы,***
*тарих фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

[1] Исхаков Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени (Этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв.). Казань, 1998. С. 34.

**2018 елның 3–5 апрелендә** Казанда II Бөтенроссия татар авыллары һәм төбәкләрдәге татар тарихын өйрәнүчеләр җыены узды. Бөтендөнья татар конгрессы оештырган әлеге җыенда Россиянең 36 төбәгеннән 350 дән артык вәкил катнашты.

Җыенда катнашучылар Россия төбәкләрендәге татар авыллары тарихына һәм Татарстан Республикасы архив эшләренә багышланган китаплар күргәзмәсе белән танышты. «Мәдәни мирасны, татар төбәк тарихын барлауда һәм өйрәнүдә галимнәрнең, тарихчыларның, җәмәгать эшлеклеләренең роле» темасына түгәрәк өстәл, «Татар бистәләрен саклап калу һәм үстерү» дигән темага сессия, «Төбәк тарихын өйрәнү буенча хезмәтләргә фәнни-методик тәкъдимнәр» һәм «Төбәк тарихын өйрәнү буенча хезмәтләр язганда Бердәм архив мәгълүматы системасының фәннибелешмә потенциалыннан файдалану» дип исемләнгән методик семинарлар үткәрелде. Җыенның пленар утырышы 4 апрель көнне узды.

**2018 елның 13–14 апрелендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институтында «Төрки дөнья һәм ислам цивилизациясе: тел, әдәбият, тарих һәм дин проблемалары» IX Халыкара тюркология конференциясе үтте. Конференциянең максаты – төрки халыкларның телен, әдәбиятын, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү практикасы һәм фәнни проблемалары, төрки халыкларның тарихи язмышында ислам диненең роле һәм тоткан урыны турында фикер алышу. Фәнни чарада галимнәр, югары уку йорты мөгаллимнәре, методист-укытучылар, аспирантлар катнашты.

Конференциядә түбәндәге секцияләр эшләде: төрки халыкларның тарихы, мәдәнияте, археологиясе; төрки халыкларның топонимикасы һәм ономастикасы; төрки халыкларның фольклоры һәм әдәбияты; заманча төрки тел белеменең актуаль мәсьәләләре; төрки халыкларда ислам һәм дини күзаллаулар; лингвокультурология, контактология һәм тәрҗемә мәсьәләре; төрки телләрне һәм әдәбиятларны укытуда инновацияләр.

Чарада Төркия, Азәрбайҗан, Әрмәнстан, Кыргызстан, Казакъстан, Һиндстаннан вәкилләр катнашты.

**2018 елның 18 апрелендә** РТ ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Академик томнарны фәнни-текстологик әзерләү һәм бастырып чыгару мәсьәләләре» темасына түгәрәк өстәл оештырылды. Чара кысаларында фикер алышуга түбәндәге мәсьәләләр тәкъдим ителде: академик томлыклар һәм аларны төзү принциплары, текстларны атрибуцияләү, орфографик яктан текстларны бирү мәсьәләсе, аңлатмаларны язу үзенчәлекләре.

Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар әдәбияты классикларының һәм халык иҗаты мирасының академик томлыкларын фәнни-текстологик яктан әзерләп, халыкка җиткерү максатында Г. Исхакыйның 15 томлыгы, Г. Тукайның 6 томлыгы нәшер ителде. Хәзерге вакытта Г. Ибраһимовның 15 томлык академик басмасы, халык авыз иҗаты әсәрләренең 25 томлыгы әзерләнә. Түгәрәк өстәл әлеге юнәлештәге фәнни эшчәнлекне заман таләпләренә туры китерү, камилләштерү максатыннан уздырылды.

**2018 елның 24 апрелендә** Татарстан Республикасының Арча районы Өчиле мәктәбендә татар хал-

кының бөек шагыйре Г. Тукайның персональ энциклопедиясен тәкъдим итү кичәсе үтте. Энциклопедияне тәкъдим итүдә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре И.Г. Гомәров, З.З. Рәмиев, М.И. Ибраһимов, Г.М. Ханнанова, Э.М. Галимҗанова, Ф.Г. Фәйзуллина, «Мәгариф» һәм «Казан утлары» журналларының бүлек мөдирләре Т.Ә. Сабирҗанов, Ф.Ф. Гыйләҗев катнашты.

Галимнәр Г. Тукай энциклопедиясен әзерләү тарихы, төзелү принциплары, андагы төп юнәлешләр турында кызыклы мәгълүматлар белән уртаклаштылар. Кичәдә катнашучы укытучылар, укучылар, кунаклар энциклопедияне төзүдә катнашкан галимнәрдән үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар алды. Г. Тукай энциклопедиясе Арча районының һәр мәктәбенә бүләк ителде.

**2018 елның 26 апрелендә** Муса Җәлил исем. Татар дәүләт опера һәм балет театрында Габдулла Тукайның туган көненә багышланган тантанада 2018 елның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары игълан ителде.

2018 елда Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты исеменә язучы Камил Кәримов («Карурманда кара песи», «Игезәкләр йолдызлыгы» китаплары өчен), рәссам Михаил Кузнецов («Белые холсты. Народы Поволжья» эшләре сериясе өчен), «Таттелеком» акционерлык җәмгыяте иҗат төркеме – Лотфулла Шәфыйгуллин һәм Рөстәм Зәкуанов (Татарстанда яшәүче халыкларның милли байлыкларын һәм тарихи мирасын, мәдәниятен үстерүгә һәм саклап калуга керткән өлешләре өчен) лаек булды.

Лауреатларга дәрәҗәле бүләкләрне Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов тапшырды.

**2018 елның 26 апрелендә** бөек татар шагыйре Г. Тукайның туган көне уңае белән Мәскәү шәһәренең Татар мәдәни үзәгендә үткәрелгән чарада ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият, сәнгать институты эшчәнлеге тәкъдим ителде, Г. Тукай Энциклопедиясе презентацияләнде. Чарада ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА мөхбир әгъзасы К.М. Миңнуллин, директор урынбасары, филология фәннәре кандидаты О.Р. Хисамов, Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире, филология фәннәре кандидаты И.Г. Гомәров, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы К.Р. Галиуллин катнашты. Чара Г. Тукайның һәйкәленә чәчәкләр салу белән тәмамланды.

**2018 елның 26–28 апрелендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исем. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты базасында «Дөнья тюркологиясе һәм Казан университеты» дип аталган фәнни-гамәли конференция булып узды. Чара күренекле тюркологлар һәм Казан тюркология мәктәбе вәкилләре – Г.Х. Алпаров, М.Х. Корбангалиев, М.А. Фазлуллин, Х.У. Усманов, Н.К. Дмитриев, М.З. Зәкиев, И.З. Нуруллин, С.М. Ибраһимов, Ф.С. Сафиуллина, А.Х. Нуриева, М.Х. Бакиров, Р.А. Йосыпов, Т.Н. Галиуллин һ.б. галимнәрнең юбилей даталарына багышланды.

Конференция төрле илләрдә, Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә яшәүче һәм төрки тел белеме өлкәсендә эшләүче тюркологлар арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек булдыру, төрки дөнья галимнәрен берләштерү, төрки халыклар арасындагы багланышларны ныгыту

максаты белән үткәрелде. Конференциядә Азәрбәйҗан, Төркия, Казакъстаннан, Башкортстан, Чувашия, Якутия (Саха), Кырым, Татарстан республикаларыннан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Төмән, Казан шәһәрләреннән галимнәр катнашты.

**2018 елның 26–27 апрелендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исем. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Төрки халыкларның сәнгате, тарихы һәм фольклоры» темасына X Халыкара конгресс уздырылды. Чара кысаларында төрки халыклар сәнгате буенча күргәзмә эшләде.

Конгресста Төркия, Азәрбайҗаннан, Төмән өлкәсе, Хакассия, Чувашия, Башкортстан, Татарстан республикаларыннан галимнәр катнашты, төрки халыкларның традицион мәдәнияте, мәдәниятара багланышлар, төрки халыклар тарихы, археологиясе, әдәбиятына, фольклорына кагылышлы мәсьәләләр буенча чыгышлар тыңланды, фикер алышу оештырылды.

**2018 елның 15 май аенда** Казакъстан Республикасының Л.Н. Гумилев исем. Евразия милли университетында «Иҗтимагый аңны үстерүдә казакъ әдәбияты һәм әдәбият белеменең тоткан урыны һәм әһәмияте» дип исемләнгән халыкара фәнни-нәзари конференция булып үтте. Әлеге конференция әдәбият белеме өлкәсендәге күренекле галим, теоретик, Казакъстан Республикасының Милли Фәннәр академиясе академигы Зәки Әхмәтовның тууына 90 ел тулуга багышланды.

Конференциядә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор К.М. Миңнуллин катнашты. Пленар утырышта ул «Милли аңны үстерүдә әдәбиятлар тарихының роле (Татар әдәбияты тарихының 8 томлыгын төзү мисалында)» темасына доклад белән чыгыш ясады.

**2018 елның 15–18 май аенда** Казанда «Заманча мәдәни киңлекләрдә театр музее» исемле V Бөтенроссия семинары үткәрелде. Ул А.А. Бахрушин исемендәге Дәүләт Үзәк Театр музее тарафыннан, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы ярдәмендә оештырылды. Чара театр каршында эшләп килүче музейлар эшчәнлегенә багышланды.

Семинар кысаларында «Музей һәм театр: тере хәтер» исемле фәнни-гамәли конференция уздыру, Казан һәм башка төбәкләрдәге театр музейларын «Россиянең театр музейлары» порталына кертү, Казан Кремле музейларында, Татарстан Республикасы Милли музеенда фәнни-гамәли дәресләр үткәрү, башкалада урнашкан театр музейларына бару, Татарстан Мәдәният министрлыгы хезмәткәрләре белән очрашу, «түгәрәк өстәл» утырышлары, китаплар тәкъдим итү чаралары, Казанның әйдәп баручы музей хезмәткәрләреннән мастер-класслар үткәрелде, шәхси консультацияләр оештырылды.

Чара кысаларында Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире Р.Р. Солтанованың татар театрының 110 еллыгына багышланган, татар, рус һәм инглиз телләрендә нәшер ителгән «Татар театры тарихы плакат сәнгатендә» дигән яңа китап-альбомы тәкъдим ителде.

**2018 елның 23 май аенда** ТР ФАдә Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты,

педагогика фәннәре докторы, профессор, академик, Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Әлфис Суфиян улы Гаязовның «Бәхет дагасы» дигән яңа чыккан шигырьләр китабы тәкъдим ителде.

Татарстан Фәннәр академиясе президенты М.Х. Сәлахов сәламләү сүзендә Әлфис Гаязов эшчәнлегенең киңкырлы булуын, аның бүгенге көндә дәүләт эшлеклесе, галим, шагыйрь, драматург буларак күренекле урын тотуын билгеләп узды, Татарстан һәм Башкортстан Фәннәр академияләре арасында нәтиҗәле һәм күпьеллык хезмәттәшлекнең ныгуын искәртеп китте.

Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хезмәткәрләре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре катнашты. Күренекле язучылар һәм шагыйрьләр Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Мөхәммәт Мирза, Шәмсия Җиһангирова һ.б.лар чыгыш ясады.

Очрашуга килгән кунаклар Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан яңа китаплар белән таныша алды.

**2018 елның 28 май – 3 июнь көннәрендә** Казанда V «Нәүрүз» Халыкара театраль-белем бирү форумы узды. Форумда Берлин, Мәскәү, Санкт-Петербург, Новосибирск һәм Казан шәһәрләре педагоглары семинар һәм мастер-класслар үткәрде. Форумда Башкортстан, Мари Эл, Татарстан, Удмуртия, Чувашия республикалары, Пермь крае, Самара һәм Чиләбе өлкәләре, шулай ук Дагстан һәм Казакъстаннан 300 ләп белгеч катнашты.

Форумның белем бирү программасы 5 иҗат лабораториясенә бүленеп төзелгән иде: «Актерлык осталыгы, практик режиссура һәм композиторлык сәнгате», «Режиссура, сценография һәм музыкаль сәнгать теориясе һәм практикасы», «Театр сәнгате өлкәсендә законнар, менеджмент һәм маркетинг-технологияләр», «Курчак театрында актер һәм режиссер сәнгате», «Театраль тәнкыйть һәм театрда әдәби бүлек эшчәнлеге».

Форумда катнашучыларга режиссер Александро Гонсалес Пуче сәхнәләштергән Колумбия театр студиясенең «Чернобыльский идиот» спектакле һәм Камал театрының премьералары (А. Гыйләҗев «Әтәч менгән читәнгә», С. Гаффарова «Килмешәк», Г. Исхакый «Тормышмы бу» һәм Н. Исәнбәт «Миркәй белән Айсылу» спектакльләре) күрсәтелде.

**2018 елның 1 июнендә** Халыкара балаларны яклау көне уңаеннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Татар балалар әдәбияты: традицияләр һәм заманчалык» темасына фәнни-гамәли конференция үтте. Чара танылган балалар язучылары Дәрҗия Аппакованың (1898–1948) тууына 120 ел, Абдулла Алишның (1908–1944) тууына 110 ел, халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исем. Дәүләт премиясе лауреаты Шәүкәт Галиевнең (1928–2011) тууына 90 ел, халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исем. Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Миңнуллинның (1948) тууына 70 яшь тулуга багышланды.

Конференция кысаларында фикер алышуга балалар әдәбиятының төп үсеш тенденцияләре, балаларны китап укуга тарту юллары, вакытлы матбугат һәм театр аша матур әдәбиятка карата кызыксыну уяту һ.б. мәсьәләләр чыгарылды.

Конференциядә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан (Идел буе) федераль

университеты галимнәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, язучылар һәм шагыйрьләр, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан китап нәшрияты, яшьләр оешмалары, телевидение, вакытлы матбугат басмалары вәкилләре, мәктәп укытучылары, китапханә хезмәткәрләре катнашты.

**2018 елның 4–15 июнендә** Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Киров өлкәсе, **16–28 июнендә** Иркутск өлкәсенең татар авылларында комплекслы экспедицияләр оештырылды. Экспедицияләр вакытында тел, тарих, фольклор, гамәли-декоратив сәнгать, археография, музыка буенча материаллар тупланды.

## ***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары

– мәкалә исеме

– аннотация (рус телендә)

– төп сүзләр (рус телендә)

– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*